# **БАЛЫКЛЫ**
# АВЫЛЫ ТАРИХЫ ЭЗЛӘРЕННӘН…

Самара өлкәсе, Камышлы районы,
Балыклы авылы

# *Кереш сүз*

Бу язмалар, Балыклы авылы тарихы эзләреннән бару дип әйтүне, дөресрәк таптым. Чөнки, авылыбызның кайчан, кемнәр тарафыннан нигезләнгәнен төгәл генә ачыклау һәм бүгенге чоргача үзенең яшәешендә нинди этаплар кичергәнен елдан-елга ялгап, тулы тарихын тасвирлау мөмкин түгел. Андый мәгълүматлар, елъязмалар юк. Бәлки алар аз булса да булгандыр, тик сакланмаган.

Соңгы елларда авылдашларда үзебезнең тарихыбыз белән кызыксыну тоела башлагач, авыл советы рәисе Вагазов Халик Миневәли улы, совет сәркатибе Вахитов Раил Вәли улы 1999 елнда безне: Нигъмәтуллин Хәбиб Гайзулла улын, Хәмзин Рәфкать Минәхмәт улын, Абсаттарова Таухидә Нәзах кызын һәм мине, Билалов Рәшит Кыям улын чакырып, киңәшмә уздырдылар, авылыбыз тарихына кагылган мәгълүматлар: язма чыганаклар, төрле архивларда сакланган документлар, риваятьләр, ишеткән-белгәннәребезне җыйнап, бер җыентыкка туплап язуыбызны соралдылар һәм йөкләделәр.

Авыл тарихы белән кызыксыну, аның турында олы яшьтәге авылдашлардан буыннан-буынга күчеп килгән хатирәләрне, риваятьләрне ишетеп барлау, башка кайбер мәгълүматлар белән танышу бик тә мавыктыргыч, һаман ерактанрак, тагын да тирәнрәктән эзләнергә өнди торган шөгыль икән. Һәрхәлдә, мин үзем шундый тойгылар йогынтысы кичереп, шушы эшкә тотындым.

Иң элек, бу язмаларга тотынганчы, Бөек Ватан сугышы вакытында “Идел-Урал” легионерларының псевдоним астында язган шигъри юлларына игътибар иттем һәм аңа берничә сүз кушуга ул нәкъ безнең авыл турында язылган кебеклеге күзгә бәрелеп тора. Бәлки, Ватан сугышына киткән безнең авылдашлар анда, Алманиядә, әсирлектә булганнардыр. Менә ул юллар:

*Әнә (вона), күрәсезме,*
*Кинәле белән Сокның арасында, водоразделда,*
*Заря тавы итәгендә тора тармакланып бер авыл,*
*Күмелсә дә тирән карга кыш көннәрне,*
*Җәй җиткәчтен ямьле була ул.*
*Тирә-ягы яшел урман*
*Әдекәе, чокыр бүләк, каршы урманы.*
*Хуш ис чәчәк белән тула җәй көне,*
*Чылтыр-чылтыр ага җиде чишмәсе дә*

*Инеш булып, Шарламадан Тиләгәзгә.*
*Җәй башыннан күке, сандугачлар сайрый көне-төне*
*Менә шунда инде ул безнең авыл.*
*Без тарихын эзләп маташкан*
*Шарламабаш-Давыдкино-Балыклы!*

Менә шунда инде, табигатьнең матур җирендә, без, Балыклы авылы мишәрләре, Ходайдан кемгә күпме гомер насыйп булганга риза булып, тормыш буйлап барабыз. Илдәге нинди системада яшәсәк тә, (әлегәчә "дөрес яшәмәгәнбез" кебек килеп чыкса да), бик үкенеп тормыйбыз, салмак кына, авылыбыз белән, һәр кеше үз хезмәте белән яшибез. СССР-Советлар союзы таралды, бетте. Һаман ил белән катлаулы, буталчык вакыт-бер системадан (социализмнан), икенче сисмтемага (кыргый рынок-капитализмга) күчеш чоры кичерәбез. Базар бәяләре генә түгел, Балыклы авылы халкының да мөнәсәбәте үзгәрә, язмышыбызны, гомумән, яшәү рәвешебезне бәяләү алмашына, үзгәрә. Безнең бүгенге тормыш авылыбыз тарихында кыска бер мизгел генә булып калачак. Ә бит тарихны, гомумән, шул мизгелләр тәшкил итә дә. Бүгенге фикерләү күзлегенннән чорыбызны анализлап язганнар, киләчәк мизгелләргә ярап бетәрме? Анысына күрәзәлек итеп булмый. Авылыбыз тарихы эзләрен без төрле яшьтәге авылдашлардан ишеткәннәрне, төрле җирдән табылган мәгълүматларны туплап, шушы язмабызга теркәп барабыз. Шактый гына туктап та тордык. Чөнки, каян тотынырга?,-дигән сорау туды, ә авыл турында язма бер генә чыганак та юк. Бәлки, азмы-күпме алар булгандыр, бигрәк тә мәчетләрдә, тик авыл үз дәверендә урамы-урамы белән өч тапкыр көчле янгын кичергән һәм мәчетләр шулай ук, ичмаса, туучылар һәм үлүчеләр турында теркәлгән кенәгәләре белән янганнар.

Безнең мишәр-татар авылы өлкәбез башкаласы Самарадан 180 чакырым ераклыкта, Клявлино станцасыннан 35 чакрым, Похвистневодан - 45, Богырысланнан - 60 чакрым ераклыкта урнашкан. Район үзәгебез Камышлыга -15, Бөгелмәгә - 100, автомагистраль М-5 Мәскәү - Чиләбегә - 9 чакрым арабыз.

Центральный Государственный Архив Древних Актов (ЦГАДА) СССР үзенең фондларына нигезләнеп (ф-558 опись 2, Д-295, ф.1355 оп.1, Д-1876, ф-350 оп.1, Д-440, ф-350 оп.2, Д-3792 оп.103) биргән рәсми белешмәсендә Балыклы -1650-1660, Камышлы - 1581, Татар Байтуганы-1533, Иске Ярмәк 1732 (1737) нче елларда нигезләнгән диелгән. Балыклы авылының тарихы,

үткән юлы бик катлаулы да, кызыклы да дип әйтә алабыз. Бу төбәктә бердәнбер мишәрләр авылы-үзебез мөселманнар, динебез-ислам.

Хәзергесе көндә авылда 597 кеше яши, хисапта тора. 283 йорт, шулардан 71 йорт ябык. Тирә-якта, районыбызда гына түгел өлкәбездә дә колхозлар калмады, ә бездә елаш, каргыш, раскулачиваниеләр белән төзелгән колхозыбыз әлегә эшләп тора, таралып бетмәде. Дөрес, яшь эшчеләр колхозда азайды, урта белем бирүче мәктәбебез 9 сыйныфлы гына булып калды. Балалар бакчасы, социаль хезмәт күрсәтү үзәге, фельдшер-акушер пункты, Мәдәният йорты, китапханә, администрация-эшләп торалар.

Безнең төп һәм иң мөһим бурычыбыз: борынгы мишәр ата-бабаларыбыз кайчан, каян, нинди сәбәпләр аркасында бу якларга килеп төпләнгәннәрен ачыклау. Шуны максат итеп куеп, инә белән кое казуга охшаш эшкә тотындык. Хәерле сәгатьтә булсын иде.

Хөрмәтле авылдашларым! Тирә-ягыбыздагы матур урманнар, хуш исле чәчәкле, җиләкле аланлыклар, ямьле җәйләрдә бала-чагаларның шунда черкелдәшеп уйнап йөргәннәренә сокланып хозурланган минутларда, урманның серле шаулавында борынгы бабаларыбызның: “Балакайлар, заманында биредә яшәгән, авылга нигез салган, Шарламабаш-Давыдкино-Балыклы мишәрләрен онытмадыгызмы?”, дигән өннәре, тавышлары кайчакта колагыма кагылып киткәндәй була. Шулай булгач, мин язучы да, тарихчы да булмаган килеш, борынгы тамырларыбызны барлап, алар бөтенләй онытылмасыннар өчен, авылыбызның тарихи эзләрен, бүгенгә билгеле күләмдә язып калдырырга батырчылык итеп, өстемә алдым.

Бу язмаларны кулына алган бүгенге чордаш һәм киләчәк буын авылдашларым! Сезгә зур үтенечем: авылыбызның үткәне сезне кызыксындырмаса, аның тарихына һәм киләчәгенә битараф караштa булсагыз, вакытыгызны әрәм итеп укып тормагыз, тик кәефсезләнеп ертмагыз, чүплеккә ташламагыз, берәр аулак урынга җыеп куегыз. Бәлки, үз вакыты белән, кызыксынучы кешеләр тагын яңа мәгълүмати документлар табарлар, үзләре белгәннәрне, фикерләрен өстәп язарлар, тулыландырырлар. Шулай итеп, безнең туган җиребезнең, кендегебез береккән гүзәл Балыклыбызның тарихы дәвамланыр дигән өметтә калам.

**Тирән ихтирам белән авылдашыгыз,**
**чи Балыклы мишәре Кыям улы Рәшит Билалов.**

# Балыклы авылы тарихы турында бүгенгә билгеле мәгълүматлар



Балыклы авылы турында беренче язма мәгълүмат, безнең авыл кешесе, Самара авыл хуҗалыгы Академиясе доценты, М.Мөхетдиновның “Камышлы хәбәрләре”- гәҗитенең 1997 нче елгы 17 нче июнендәге санында басылган мәкаләсендә мәгълүм булды. Ул анда, күптәнге вакыйгаларны ачыклаучы, язма рәвештә сакланган чыганаклар бүгенгә бик аз диеп икърар итә, тик рус язмаларыннан (күрәсең ул аларны эзләгән, тикшергән), борынгы бабаларыбызны: кыпчак, болгар, нугай, татар исемнәре белән телгә алынган очракларда аз-маз белә алабыз, дигән.

Аның язуынча, безнең авыл иң элек “Шарламабаш” исемле була. Ырымбур шәһәре Гос-Архивының 98 номерлы фондында авылыбыз шулай ук “Балыклы-Шерлама” дип телгә алына. Мөхетдинов фикеренчә, 1553 елда явыз Иван гаскәрләре Казанны яулагач, исән калган хәллерәк татар гаиләләре Ангалышевлар (Енгалышевлар) һәм аларга ияреп Ягудиннар, Низамаевлар, Галләмовлар, Муллабаевлар, Гыйматдиновлар шушы якка күченеп киләләр. Әмма ул 1553 елны дәлилләп исбатлаучы чыганаклар турында язмаган. Без дә әлегә бу датага карата читләтеп булса да ымлаучы, раслаучы дәлилләр очратмадык. Авылдашыбыз Әбделхәй Әбделбар улы Ангалышевның дәү бабасы Гобәйдиннур язып калдырган дәфтәрендә шул хәбәр ителгән: 17 нче гасырда Пенза губернасында (Пензада) кенәз Ангалышев яшәгән. Ике улының берсе православие динен, үзе теләп, кабул итә. Бу хәлне икенче туганы, Ангалышев (Енгалышев) Морза Абдулмән кичерә алмый һәм 1699 нчы елда, үз гаиләсе һәм кайбер туганнарын ияртеп, үз телләрен, гореф-гадәтләрен, диннәрен саклар өчен, туган җирләрен, Пензаларын калдырып, чыгып китәләр. *(Бәлки алар, үз тарафларына карата төрле кысрыклаулар кичергәннәрдер һәм шулар түзмәслек дәрәҗәгә җитеп, илләрен ташлап китәргә этәргеч булгандыр. Автор.)*

Озын-озак юлда, илләр буенча күчә торып, элек руслар “Дикое поле” дип йөрткән җирләрне, Жигули тауларын үтеп, Идел-Волга елгасын кичеп бара торгач, ниһаять юлларында яхшы, төрле агачлардан торган урманнар, маллар көтәр өчен яз иртә ачыла торган, төрле үләннәргә бай таулар-көтүлекләр, иген игәр өчен уңдырышлы туфраклы кырлар, тормыш өчен мул сулы инешләр, яхшы, тәмле сулы чишмәләргә бай булган Кинәле, Сок елгалары арасындагы су бүлгечтәге төбәкне очратып һәм ошатып, бәлки, бу тирәдә элегрәктән яшәүче халыклар (Даутлар?) белән уртак тел табып, шушы матур Шарламабашта нигезләнергә ниятлиләр. Ул чорда Шарламабашта 5 йорт булуы искә алына, ә аларда нинди милләт халкы яшәгәнлеге билгесез.

Моңа кадәр бу җирләрдә вакытлыча латышлар да яшәгән, хәзер аларның зиратлары-каберләре авылдан шактый читтә һәм Карамалда да бар. Элегрәк Ярмәк урамы латышлар очы дип йөртелгән, ә авыл Давыдкино исемендә була. Бу уңайдан 1970 нче еллар башында булган бер вакыйганы искә алсам, урынлы булыр дип уйлыйм. Колхоз дуңгыз фермасы салырга нигез казытканда җир астыннан кеше сөякләре килеп чыга. Бу хәлне ишеткәч мин анда бардым. Ике кеше сөякләре чыккан. Берсе зур кешенеке, икенчесе кечерәк. Минем буем 177 см, зурысының бот сөяген үземнеке белән чагыштырып үлчәп карадым, минекеннән ким түгел иде. Димәк, шактый эре гәүдәле кешеләр яшәгән була. Шунда ук, кызгылт сарырак төстә, өске ягында сырлы бизәкле, зур авызлы чүлмәк һәм нык черегән, беләзеккә ошаган әйбер дә бар иде. Чүлмәкне колхоз идарәсенә кайтарып куйган идем, кызганычка, сакланмады, югалды. Бераз вакыттан, Куйбышевка баргач, краеведческий музейга кердем. Карасам бер витринада безнең ферма янында чыккан чүлмәк (копиясе) тора. Музей хезмәткәреннән сорадым:

-Бу чүлмәк кемнеке, кайсы милләтнеке?-дип. Миңа, бу элеккеге фин-угор халыклары-мордваныкы, диделәр. Димәк бу, безнең якта кайчандыр мукшы-эрзялар яшәгәнлекне раслый. Бер-ике ел соңырак, Камышлы ягына асфальт юл өчен дамба күтәргәндә, авыл халкы “Зур Мар” дип йөртә торган урында шөлек куаклары үскән курганчыкны бульдозерчы трактор белән эттергән. Аннан да кеше сөякләре килеп чыга. Сөякләр саны буенча, чама белән ике-өч кеше күмелгән булган. Каен агачының тузы һәм тимер әйбер булганлыгы да билгеле.

Ә кабер бары 30-40 см. казылган (астарак җир ташлы ахрысы), ә өстенә берәр метр булыр, курганчык өелгән иде. Хәзер инде ул урын тракторлар белән тигезләнеп бетте. Аннан ерак та түгел сотовый (кәрәзле элемтә) телефон өчен вышка төзеп куйдылар.

А.И. Поповның 1973 нче елны Ленинградта нәшер ителгән “Названия народов СССР” китабында мар сүзе мукшы телендә “үлгән кешене” аңлата, диелгән. (103 бит.) Бу ике зират та безнең авыл төбәгендә элегрәк мукшы-эрзялар яшәгәнлеккә өстәмә дәлилләр. Тик алар ни сәбәптән ике җирдә урнашканлыгы сәер, беренчесе су буенда, икенчесе-тау башында ук. Һәрхәлдә, алар икесе төрле дәвердә барлыкка килгән, дип уйларга була. Кайбер мәгълүматлар буенча мукшылар мәетне авылдан читтәрәк, ераккарак күмүләре билгеле. Димәк, бу курганчыклысы соңрак, яшәүче халык ишлерәк чорда тәшкил булган, чөнки андый курганны бер-ике кеше генә тиз арада өя алмый. Аларның кайсы чорда яшәп, кая китүләре билгесез.

Инде, янә үзебезгә, татар-мишәрләргә әйләнеп кайтыйк. Рәсәй патшасының Указы буенча “Ново-Закамская укрепленная линияне” Идел-Кама, Сок, Ык елгалары буйлап, Башкорт җирләрен яулап алуны күздә тотып, яңа гарнизоннар, фортлар төзү өчен 1652-1656 нчы елларда төп Рәсәй һәм яңа яулап алынган территорияләрдән халыкны күчерү оештырыла. Бик ихтимал, күп кенә татарлар, мишәрләр шул дәвердә үк бу якларга килеп утыра башлаганнардыр. Петербургта яшәгән, Фәннәр Академиясенең беренче мөхбир әгъзасы, сәяхәтче, этнограф, тарихчы, Ырымбур төбәген тикшереп өйрәнүче П.И.Рычков үзенең көндәлек язмаларында шундый хәбәр теркәгән: Алтын Урдадан чыккан Дауд (Давид) Минкан Морза Касап улы Тиләгәзе буена килеп, Давыдкино авылын нигезли.

1694-1695 нче елларда Кодрык Морза Ишай улы Мамин патшага яхшы хезмәте өчен бүләк рәвешендә 282 десятинә җир һәм 33 сум акча ала һәм Богырыслан уезды, Давыдкино (Балыклы) да урнаша. (Башкортостан республикасы, ЦДТА фонд 1, оп.1, Д-1343, 115 нче бит.) Шул ук Башкортостан республикасы архивында ул Маминнарның 100 елдан соң, 1796 нчы елда дворянлыкларын кабат раслап алганнары искәртелә. (Башкортостан Республ. ЦДТА ф.1, 1 тәсвир, 1343 нче саклагыч берәмлеге 38. 145нче бит, 138 фонд, 2 тасв, 35 сакл. Берәмл., 619 нчы бит.)

Маминнарны Камышлыда да яшәгән диләр. Бу фамилиядән сәяхәтче, язучы Мамин-Сибиряк Дмитрий Наркизович.

Ангалышев Гобәйдиннур язмасында Пенза ягыннан бер төркем татарлар бу якка күченеп урнашуларын 1699 нчы ел белән даталаган. Ә архив чыганакларыннан Давыдкино (Балыклы) 1650-1660 нчы елларда нигезләнүе билгеле. Анда 5 йорт булганлыгы әйтелгән. Ә күпме һәм нинди милләт кешеләре яшәгәнлеге билгесез. Күченеп килгән халык калдырып киткән ил-җирләре, якташлары, туганнары белән элемтәне өзмәгәннәр, ул дәвердәге мөмкинлекләр белән хәбәрләшеп торганнар. Шуңадыр, җирләргә, урман-чишмәләргә, күлләргә бай булган төбәккә 2-3 ел эчендә Пензадан һәм губернасыннан күчеп килүчеләрнең саны бик нык арткан, 227 хуҗалык тәшкил булган. Соңрак Ык буеннан, Казан якларыннан татарлар күпләп күчә башлыйлар. Араларында вак һөнәрчеләр: тегүче, мич салучылар, тимерче, балта осталары һәм башка һөнәр ияләре булган. 20 нче гасыр башына 500 йортлы мишәр авылы Балыклы игенчелек, терлекчелек белән яши бирә.


Балыклы авылы халкы күп сугышлар, афәтләр күргән, һәлак булучылар да күп булган. Әсир калып яшәгән илләрдән абыйларыбыз, кире кайтканда төрек кызларын, немка апаларны иптәш итеп, алып кайталар. Алар турында алдарак сүз булыр. 30 еллар чамасы авылда староста вазыйфасын үтәп килгән Шәмсетдинов Садершәет бабай әсирлектән немец-алман телен бик яхшы өйрәнеп кайткан булган, иркен итеп шул телдә сөйли иде. Хәрби хезмәттән авыл яшьләре калдырылмаган. Культуралы, горур, эшкә уңган, туры әйтүчән, байлыкны яратучан, тапкыр, җор сүзле булу яклары белән авылдашларыбыз тирә-якта танылган һәм ул сыйфатлар бүген дә сакланган. Зур түрәләр, руханилар белән ныклы элемтәдә торганнар. Билгеле, ашлык кибәксез дә булмаган. Татар дөньясында киң билгеле булган Шәкүр карак һөнәре буенча оста профессиональ-һөнәрмәннәр барлыкка килгән. Караклар, качкыннар (беглыйлар) безнең Талкыш белән Кисенде урманнары арасы Кысындыда, Стюха янындагы урман чокырында качып яшәгәннәр һәм юлаучыларны талаганнар. Тагын да Самар-Мансур-Мүкле күл-Байтуган-Сок-Карамалы-Бөгелмә-аерым “воровская дорога” булган. Ст.Выселкага килеп утырган украиннар Мүкле күл тирәсендәге урманны кисеп

төпләгәч, күл суы саега һәм аннан бик күп кеше сөякләре килеп чыга. Караклар күп юлчыларны саклап торып әйберләрен талаганнар, атларын алып, үзләрен үтереп күлгә ыргыта торган булганнар. Балыклының үзендә дә судсыз җәзәлау, самосуд очраклары булгалаган. Мәсәлән, Котдус бабайны, караклыкта гаепләп, урамда тәртә белән кыйнап үтергәннәр. Ул: "Җәмәгать, ялгышасыз, мин монда бер кешенең дә әйберенә тигәнем юк", ди. Тик чыгырдан чыккан коткычылар аны тыңламыйлар, үтерәләр. Соңыннан эш ачыклана, Котдус бабай гаепле булмый, тик эш узган була.

Хәзерге вакытта Балыклыда Ангалышевлар токымыннан 5-6 буын яшәп килә. А.М.Орлов "Мещера, Мещеряки, Мишари" дигән китабында (Казан, 1992 нче ел) безнең авылдашыбыз, ягъни Ангалышевларның бабалары турында болай дип яза: На Мещере были владения древних княжских родов Енгалышевых, Ишаевых, Кулаевых, Барашевых, Танишевых, Еникеевых и многих других. Стр.39. Күрәсең, 1698 нче елны, Ангалышев И.Д. ирекледән, үзе теләп чукынып, православиягә күчеп, русларга стольник булып хезмәт итә башлагач (стр.87) браты Абдулмән, бер елдан соң иптәшләре белән Балыклыга күченеп китә. Ихтимал, шушы өлкән И.Д.Енгалышев, подпоручик, Самараның гвардия полкында хезмәт итеп, анда үлүче Юсуф Енгалышевның әтисе булгандыр. Хәер, безне, татарны үз динебездән, Ходаебыз, Аллаһы Тәгаләгә инанудан яздырып, ислам диненнән православиягә әйләндерү юлларын, төрле ысулларын куллану Рәсәй хөкүмәтенең һәм чиркәү руханиларының төп, рәсми сәясәте, максаты була. Бер мисал: 1619 нчы елда патриах Филарет, илдә тынычсызлыктан, Лжедмитрий ягында сугышканнары өчен, Мещера казакларын (гади генә әйткәндә, безнең бабаларыбыз-мишәрләрне) Донга күчерергә боерык бирә. Аларны урыс телле халыклар белән аралаштыралар, чукындыралар. Мөгаен, безнең чор язучысы М.Шолоховның "Тихий Дон" китабындагы хутор юктан гына "Татарский" булмагандыр. Мелеховлар-Малик безнең исем түгелме?! Хәзер алар барысы да рус телендә сөйләшә, без элек Мещера мишәрләре идек димиләрдер. Шулай да бер уртак сүзебез-мәйдан сакланган, бар икән.

Бу күченеп килү дулкыннары тиз һәм бер генә елда булмаган. Мәсәлән, Рәфкать Хамзин Ырымбур шәһәре госархивыннан

фотога төшереп алып кайтты: фонд № 98, оп.2.Д1. 129-131. Анда 1795 нче елда күчеп килүчеләр арасында Шерлама, Давыдкино, Балыклы исемнәре бар. 1796 нчы елда Пенза губернасыннан тагын 12 гаилә килү әйтелә. Аларны теркәү (регистрация) документы язылуы белән дә, бәлки искергәнлектән дә бик начар, укырга авыр. Минем ул иске язуларны аңларга бәлки белемем дә җитеп бетми торгандыр. Шуңа үзем таный алмаган җирләргә күп нокталар куйдым:



*Оренбург архивында 1796 елда Давыдкино-Балыклы-Шерламага килүчеләрнең регистратурасы.*

Регистръ причисленным поопрезд...литы 1796 года августа 1 го чина ... Балыклы Шерлама... сишмьиъ татарам Пензенской губернии ... апури ... 1797 года

О имянно
Деревни Урл. Е...Бимовой

Юмашъ Сулейманов сын Енгалычев - 54г.
У него жена Зебен Анилова - 43г.
Салим - 15

Ремия - 14
Абкрезинъ - 9
Дочь Фатма - 5
У Салима жена Сахиба Муртазина - 15
Абинай Сошибашаловъ ... Енгалычев - 62
У него жена Зибен Рибушева - 52
У них дети наименные
Ахиди - 34
Юмаш - 24
(Збейжа Р.Б) - 8
Расима - 4
Сафира - 2
У Юмая жена Зюбан Мусалова - 19
У них дочь Асылбая - 2
У Асана мать Асылбит - 54
Сестра Сабарь - 20
Жена Амина Умаева - 20
Деревни исимшашан большое поле
Албин Масуров - 30
У него жена Хамида Юмашина - 25
Бибиханбеков
У него сыновья
Юмай
Сюмшан
Ачиа
Хилбулов
У него сыновья
Мавлют
Биен
Игрмашин Усмановъ
У него сыновья
Юмай
Юлдаш
Ремизов Измаилъ
У него сыновья
Илинай
Шафек



*Яңа җирдә дога*

Түбәндәрәк 1747 нче ел, Балыклыда 295 кеше прихожан мәчеткә йөри, дип язылган. Шарлама (Шерлама) дигән елгачык-инеш бүген дә агып тора. "Идел" журналында язылганча Шарлы-Чуваш, Болгар телендә сазлы, күрән, камышлар үсә торган җир. Әле бүген дә, елганың, чокырның, урамның икенче ягын ар як, аргы як диябез. Заманында моннан көнбатышка киткән Венгр-Мадъярлар телендә ар-елга, Башкорт телендә дә ар-кипкән елга, дип яза Казан Дәүләт университетының профессоры Гомәр Саттаров. ("Идел" журн.№10, 1991 ел, 106б)

Мин авылыбызга якында яшәүче чувашлардан сорадым: "Сезнең телдә Шерлама нәрсә аңлата",-дип. Алар: "Русча болото", диделәр. Шарлы ул безнең телдә, татарча Сазлы була инде. Ә ул шулай да. Тик безнең авыл Шарламабаш булып, (яисә берәр очы, ягы, чаты) күпме йөргәндер? Күрәсең, Алтын Урдадан чыккан Морза Минкан Касап улының баласы Дауд-Давид бу якка килеп урнашып яши башлагач, авылыбыз Давыдкинога әйләнгәндер. Ә, бәлки, Шарламабаш очы, урамы үзенә аерым яшәгәндер.

Алдарак язылганча, рус хөкүмәте бу якта үз йогынтысын ныгыта бара.1733 нче елны Генеральное межевание ясыйлар. Нәтиҗәдә инде ясаклы һәм хезмәт итүче (йомышлы-служилые-пашенные солдаты-казаклар) турында сүз бара. Алар яңа төзелүче форпостларга, хәрби гарнизоннардагы солдатларга икмәк үстерәләр. Шушы 1733 нче елгы межевание вакытындагы материаллар буенча Давыдкинода ясачный һәм служилый татарлар (Арча уезды, Балыклы авылыннан) бишенче ревизия буенча була. Давыдкино (Балыклы) авылында 5 йорт служилый (йомышлы) татарлар исәпләнә. Шулардан 23 ир-ат, 19 хатын-кыз, ә күпме ясаклы татарлар булуы билгесез. Хөкүмәтне, күрәсең, служилый халык кына кызыксындыра, чөнки алар яңа төзелүче Сок елгасы буендагы гарнизоннарны икмәк белән тәэмин итәргә тиеш булалар. 1733 нче елда уздырылган Генеральное межевание материалларында служилый (йомышлы) татарлар турында искәртелә. "Основателем деревни Давыдкино (Балыкла) в 1733 году согласно Генерального и специального межевания по Самарской губернии были ясачные и служилые татары, переселившиеся из деревни Балыклы, Арского уезда, Казанской губернии". ЦГАД, ф-1334, оп.-1, Д-86-п-1).

Башкорт республикасының архив материалларында Балыклы авылында служилый татарлар-Чыпчык (Воробейлар), Казан ягыннан Никифор һәм Иван Чепчиговлар яшәгәнлеге дә билгеле. Алар үзләрен шулай ук Морзадан санаганнар.

Чукынган татар Гавриил Давыдов (1727-1774) атасыннан мирас булып калган җиргә-Балыклыга, (Богырыслан уезды), Казан губернасы, Свияжск (Зәй) уездыннан килеп урнаша. Ул Богырыслан бистәсе-слободасында комендант булып эшли. Аны 1767 нче елда Екатерина икенчегә (әби патша) Указы белән ясалган “Уложенная комиссия” депутаты итеп, ясаклы татарлар исеменнән, Бөгелмә ведомостеннан сайлыйлар. Депутат шәхси иминлеккә лаек кеше була. Ул комиссиянең составында 189 кеше-дворяннар, шәһәрләр вәкилләре-210 кеше, казаклар-45 кеше, барча категория крестьяннардан-24 кеше, рус түгелләрдән-34 кеше һәм хөкүмәтнең үзәк учреждениеләреннән-28 кеше була. Крепостной крестьяннар сайлана да, сайлый да алмаганнар. Менә шул сайланган элита арасында безнең авылдаш Давыдов та була. Бу орган бүгенге Дәүләт Думасына тиң ич! Ышанып әйтергә мөмкин, бу Гавриил Давыдовның әтисе Дауд-Давидтан безнең авыл Давыдкино дип, аның исемен йөртә башлаган. Татар Байтуганы авылында яшәүче Әбүзәр Хаҗи улы Бәдретдинов туплаган бай тарих материаллары арасында П.И.Рычковның язмаларында шундый хәбәр бар: ...Даутов-Давыдов - депутат Думы Российского государства... Он из рода основателей деревни, диелгән.

Гавриил Давыдов-отставкадагы офицер, яхшы белемле, русча җиңел, яхшы сөйләшүче, бик кыю кеше була. Ул Балыклыдагы җирен халыкка арендага бирә, чөнки татарларда крепостной крестьяннар булмый. Күрәсең, үзе җир сукалап, игенчелек белән шөгыллльләнмәгән. Депутат буларак, ул халык турында кайгыртучанлык күрсәткән. Бер мисал: Яңа помещик Степан Кротков Ганькино чувашларының җирләрен ала. Алар депутат Давыдовка мөрәҗәгать итәләр. Давыдов Еактерина икенчегә хат яза. Ләкин аннан бер җавап та, карар да килми. Әби патшаның, әлбәттә, вакыты җитми. Давыдовның авылдашы, Балыклы кешесе, Юсуф Ангалышев (Енгалышев) (1719-1774) исә җир эшкәрткән, икмәк үстергән, әмма аның күп җирен Степан Кротков ала. Юсуфка эшләргә җир җитми башлый һәм ул калган җирен сатып, Бөгелмә ведомостенә китә.

Кем соң ул, Юсуф Ангалышев? Юсуф Богырыслан уезды, Балыклы авылында үзенең туганнарында тәрбияләнә. Аның әтисе гвардейский подпоручик, морзалардан, чукынган татар кешесе булган. Үзе Алтын Урдадан Бикә Морзаның малае яисә оныгы булган. Самарада гвардия полкында хезмәт иткән. Юсуфка 1.5 яшь чагында әтисе үлеп киткән. Бу ятим малайны Балыклыга, туганнарына кайтарып, тәрбиягә тапшыралар. Вакыт узып, Юсуф балигъ булуга, Емельян Пугачевның фетнәсе кузгала. Г.Давыдов Ырымбурга барып (1773 нче елда) Пугачевка кушыла. Пугачев аны атаман итеп билгели. Г.Давыдов үзенең иптәше, авылдашы Юсуф Ангалышев белән бергә Богырыслан уездында Әет Уразметов, Султангул Иманкаев, Иван Черняев һәм Попов, бергәләп, төрле чыганаклардан 500-800-1000 кешедән артык Пугачев яклы көрәшчеләр җыелып, бик актив рәвештә яңа патша, Петр өченче-Е. Пугачев исеменнән "тәртип урнаштыра" башлыйлар. Бу турыда язучы Вахит Имамов "Сәет Батыр" исемле китабында яхшы тасвирлап яза. (Наб.Челны.Камаз.1994 нче ел. 159, 223-225 бит.)

Г.Давыдов Богырыслан бистәсен үз кулында тота. 8нче февраль көнне ул полковник Хорват җитәкчелегендәге башкисәр-карательләр отрядына каршы сугыша һәм җиңелүгә очрый. Апрель аенда ул инде генерал Голицын гаскәренә каршы сугыша, тик яңадан җиңелүгә дучар ителә, чөнки аларда корал начар була. Г.Давыдов хыянәтче башкорт старшинасы Кодрач Муллакаев кулына әсирлеккә кала һәм Казанга, төрмәгә озатыла. Патшабикә тарафыннан 1767 нче елда "кагылгысыз кеше" дип игълан ителгән депутат Г.Давыдовны, Казанга Пугачев отрядлары кергәч, төрмә сакчылары 12 нче июль көнне камерада кадап үтерәләр. Әби патшаның: "Депутатны үтермәгез!", дип язган хаты килеп җитми.

Морзалар нәселеннән булган Юсуп (Осип, Иосиф) Енгалычев отряды көрәш юлын Бөгелмә шәһәрендә башлый. Укымышлы Енгалычев -һәр авылда крестьяннарга рус һәм татар телендә "Падишаһ" указларын игълан итә. Аның гаделлеге турында ишетеп, крестьяннар Енгалычевка үзләрен изгән алпавыт һәм руханиларны хәкемгә алып китәләр. Биляр-Озеро, Девлезеркино, Сиделькинода (Челно-Вершин районы), сотник

Енгалычев “Падишах” һәм халык исеменнән каты карарлар чыгара. Фәрит Зәйнуллинның “Камышлы хәбәрләре” гәҗитенең 2014 нче елның 25 нче апрель санында басылган “Ямьледер “Суык су” буйлары” исемле мәкаләсеннән бер өзек:

“Зыяратлы Чагыл” атамасы атаман Пугачев сугышлары белән бәйле. Аның гаскәрләре-Алтын Тау, Кылыч тау юнәлешендә булалар. Ныклы сугыш бәрелешләре Зыяратлы Чагыл артында була. Шул канлы сугышларда патша гаскәрләре җиңелеп, төньякка чигенәләр. Бу җиңүләр нәтиҗәсендә яңа атамалар туа. Чагыл артында каберләр барлыкка килү сәбәпле-Зыяратлы Чагыл, яулап алынган чокырлар-Яулы Күл, Сөенечле Күл атамалары кереп кала. Бик ихтимал, авылдашыбыз Юсуп Ангалышевның сотнялары да шунда сугышулары. Юсуп Ангалышев отряды Резяпкино (Кләүле районы) авылы янында секунд-майор Шишкинның Бөгелмәгә баручы 40 олаулы икмәк һәм корал төягән обозны тар-мар итәләр. Олау озатучы офицерны Маклауштa (Кләүле районы) асалар.

1774 нче елның 20 нче гыйнварында Г. Давыдовның калган отрядлары Әет Уразмәтев, Юсуп Ангалышев һәм Попов берләшәләр дә, Биләр-Озеродагы генерал Миллер карательный отряды белән сугышалар. Тик яхшы өйрәнгән солдатлар, туплар белән коралланган генерал Миллер боларны тар-мар итә. Юсуплар әсирлеккә төшә. Генерал Миллер 1774 нче елның 13 нче февралендә Биләр-Озеро крепостендә Юсуп Ангалышевны астыра. Менә шулай, безнең авылның каһарманнары үткән юлларын, героик һәм фаҗигале язмышларын 240 елдан соң яңадан бер мәртәбә күз алдыннан уздырыйк. Анда бит, бершиксез, ул Давыдов һәм Ангалышев отрядларында башка авылдашлар да булырга тиеш.

Фәрит Зәйнуллин язган “Туң каен”, “Зыяратлы Чагыл”ларда Камышлы, Ярмәк, Байтуган авыллары кешеләре дә булырга мөмкин. Тик аларны әлегә белмибез. Әсирлеккә төшкән фетнәчеләрдән сорау алу беркетмә-протоколлары безнең карамакта юк, бәлки алар бардыр да.

Башкорт халкының каһарман батыр улы Салават Юлаев русларга әсирлеккә эләккәч, 175 тапкыр камчы белән суктырыла, Балтыйк диңгезе буена каторгага озатыла һәм шунда һәлак була.

Башта бу якларда җир күп була, кем күпме тели, шулкадәр алган, эшкәрткән. Тора-бара җирне җан башына (душаларга), гаиләдәге кеше башына бүлә башлыйлар. Чәчү әйләнеше (севооборот) - өч кырлы була (трехполка):

1. кыр-уҗым (арыш) кыры;
2. кыр-яровойлар (бодай, борай, арпа, солы һ.б.)
3. кыр-пар.

Җир шобага тотып бүленә. Беренче шобага-0,4 га, икенче шобага-0,4 га. Шулай кишәрлекләрне 6 урыннан бүлгәннәр. Хөкүмәт башта һәр кешедән 9 сум салым алган. Ул 9 сумны түләр өчен 90 пот (бер пот-16 кг) ашлык сатарга кирәк була. Ә икмәкне алучы булмый, аны Казанга кадәр илтеп сатарга мәҗбүр булалар. Бер пот икмәкнең хакы 10 тиен була. Авыллардагы халыкның 40% ты җирен ташлап, яңа килгән алпавытларга (Рычковка, Шуваловка, Саловка, Пилюгинга, Неклюдовка, Осоргинга), һәм башкаларга гаиләләре белән барып, эшкә ялланганнар. Шул байларга ялланып эшләгәндә 19 нчы гасыр азагында эш хакы уртача тәшкил булган:

Арыш уру (чабу) - көненә 20 тиеннән 60 тиенгә кадәр, бодай уру-55 тиен, печән чабу-60 тиен. Бераздан, дөрес, халык канәгатьсезлектән фетнәләр кузгата башлагач, хөкүмәт салымны 9 сумнан 1 сумга калдыра.

1886 нчы елны һәр кешегә (ир-атка да, хатын-кызга да, на одного едока) йәисә һәр тамакка җир күләме тиеш була (төрле авылда төрлечә):

Байтуган-2,7 десятнә;
Яңа Усман-2,4;
Неклюдово-1,7;
Семенкино-2,8;
Иске Усман-3,2;
Балыклы-3,5;
Никиткино-3,1;
Камышлы-4,8;
Яңа Ярмәк-6,1;
Иске Ярмәк-6,5.

Метрик үлчәүләр системасына әйләндергәндә уртача уңыш һәр десятнәдән җыеп алынган:

Уҗым арышы-7,5ц/га,
Бодай-4,5 ц/га.

Игенчелектән башка эшләрдә көнкүрүчеләр авылларда:
Татар Байтуганы-6 кеше;
Чуваш Байтуганы-17 кеше;
Рус Байтуганы-26 кеше;
Иске Усман-43 кеше;
Яңа Усман-59 кеше;
Балыклы-43 кеше. (күрәсең, чыпта җитештерү)
Мал бәясе уртача түбәндәгечә була:
Ат-40 сум,
сыер-25 сум,
үгез-20 сум,
сарык-3 сум,
кәҗә-2,5 сум.

19 нчы гасырда Балыклыга Пенза, Сембер губерналарыннан янә күченеп килүче халык булган. Мәсәлән, Вагазов Миневәли Әдһәм улының анасы мишәр-татар кызы Емабикә Балыклыга килә. Алар белән бергә туганнары Калюк, Миннук, Зәйнук һәм Галимнәр күченеп киләләр. Хәзер аларның күбесе Калимуллин, Миннибаев, Зәйников, Галимов фамилияләрендә йөриләр. Мәсәлән, Вагазов Миневали Әдһәмовичның балалары: Вагазов Әхмәтгали, Әхәт, Хәмит, Мөкатдимә, Хәниф, Мөхтәрәмә, Халик, Фәнүзә, Равил, Рәшит, Фәрит Вагазовлар.

Зәйниковлардан, мин белгәннәре: Галимулла, аның балалары-Зәкиулла, Зөбәрҗәт, Зөһрә, балалары Венера, Илшат.

Галимовлардан: Садыркай, Сәләй, Мәдинә, Бибинур, Малик, Зөбәйдә, Нажия, Әкътәс, Фәрит, Сания, Разыя.

Миннибаев-Әксән, балалары-Динар, Солтания, Фидания.

Авылдан ерак түгел, Кисенде дигән урман елгасының авыл ягы, Вагазов Миневәли бабайның әтисе Әдһәм бабай урманы булган. Без, мишәрләр, әле хәзер дә аны Әдекәй генә дип йөртәбез. Ә балалары "бабай урманы" дияләр иде.

Тагын да Казан губернасыннан (Арча ягыннан) Дауд бабайлар да Балыклыга киләләр. Ул үзенә йортны "Кысырык" урамда сала. Аның таш келәте урам уртасында иде. Сөйләүләр буенча, ул келәттә ачлык елны күмәк ашханә ясап, Америка биргән кукуруздан аш пешереп, ач халыкны ашатканнар.

Шарламадагы чишмәне Дауд чишмәсе, елга аша биек субайлы, агач күперне дә Дауд күпере дип йөртәләр. Аны Алтын Урдадан килгән Морза Давидныкы дисәк, күпер алай ук озакка

чыдамый. Ни булса да, халык телендә калган сөйләмнәр буенча, Дауд авыл халкына бик игелекле, аларның кайгыларын да, шатлыкларын да уртаклашырга әзер торган, халык язмышы турында борчылучы, гаделлек, дөреслек өчен көрәшче, замандашлары арасында сәләтле, үткен акыллы, дини белемле һәм намуслы, юмарт, башкалардан нык аерылып торган шәхес булган.

Гражданнар сугышы вакытында шушы Дауд бабайның Олы урамда, мәчет янында торучы малаенда, Багаутдин бабайда, кызыллар отряды бераз ял итәләр, ә киткән вакытта отряд башлыгы  Багаутдин бабайга нindидер язу бирә, мә җыеп куй, бәлки кирәгер, дип. Дауд бабайның башка малаен, Кәшафны, гаиләсе белән, “раскулачивать” итеп, Иркутскига җибәрәләр, ә Багаутдин бабайга тимиләр, гәрчә ул Кәшәфыннан берни белән дә аерылып тормаса да. Ахрысы, теге язу ярдәм иткән диләр.

Бу Даутларның токымыннан-Багаутдин кызлары Зәрига, Нәбирә, малае - Гаяз (Карамалда), аның малае-Минаҗетдин.

Багаутдинның оныклары: Шарапов Гомәр, Әхәт, Хәмит Вагазовлар. (Динә, Дилә, Дания, Сафия, Әлфия, Лилия, Руслан, Равил, Рәшит, Фәрит).

Иркутскига сөрелгән Кәшафның кызы Асма-Ганиев Минегалим (Каракай) абзый хатыны. Балалары: Әксән, Нурсәхи, Фәния, Рәфкать, Рәзгать, Минәхтәм.

Татарстаннан Балыклыга яшь егетләр, тегүчеләр киләләр, үзләренең тегү машиналары белән. Маннапов Хаҗи һәм Давлетшин Мөбәрәк Таллы урамга урнашалар. Алар Балыклының матур мишәр кызларына өйләнәләр, үзләренә гаилә коралар, балалар үстерәләр. Ә халыкка эшкәртелгән сарык тиресеннән тун, толыплар, сукнодан-бишмәтләр теккәннәр һәм тегәләр иде. Ә хатын-кызларның күлмәкләрен Миннеруй апа Галимова тегә иде.

Валиахметов Саныйәхмәт бабай үз туганнары белән Мансур авылы аша Балыклыга килә һәм Ахметова Мәймүнә апага өйләнә. Ул авылда агач эшкәртү-столярлык эшен оештыра. Матур шкафлар, өстәл, караватлар, урындыклар, сөян (юкә) агачыннан кырып коштабаклар, кәндиләр ясый иде. Балалары: Нәбиулла, Зәкия, Нәҗип.

Тагын Фатхутдинов Минаҗ бабай, Гильманов Фатих дигән кеше столярлык һөнәре белән шөгыльләнгәннәр, Багаутдинов

Гаяз, Саяров Фәхретдин тәгәрмәч ясау осталары булганнар. Шулай ук арба, чана һәм башка кирәк сбруй ясаучылар булган.

Соңырак, 20 гасыр башларында Балыклыда МТС барлыкка килгәч, Яңа Ярмәктән Шәймәрданов Гата, Сагиров Әхмәтгали, Иске Ярмәктән Рәхмәтуллин Саяр, Зәйнәгетдинов Зөфәр, Ситдиков Әнәс, Мусин Нафик, Абзалов Бәдертдин, Галиев Нигъмәт, Михайловка, Хмелевкадан-Андрющенко, Громов, Родионов бездә яшәделәр.

Авылдашыбыз Ганиев Зиннур бабайның әтисеме, әллә берәр туганымы хәрби хезмәттән бер поляк кызын алып кайта. Шуннан ары аларның токымына “поляклар”, дияләр иде. Шуны инәйдән, исән чагында, сорашып белешә алмадым, кызганычка.

Каюмов Абделхак абый сөйләвенчә, Каюмовларга, Сафиннарга “кыргыз” дигәннәр. Янәсе, бер бабалары кайчандыр кыргыз кызын үзенә хатынлыкка алган булган. Хәер, үзләре хәзер дә кара кучкыл йөзле булсалар да, кыргызларга охшамаганнар, бәлки күптән булгандыр.

Ә төрек кызы Фәридә әби Фарукшина турында аерым сүз?

# Авылның төзелеше һәм үткән тормышы



*Балыклы сугыштан соң*

Безнең авылның, Балыклыбызның төзелеше, салам башлы тәбәнәк өйләре, җылынырга теләгәндәй бер-берсенә сыенышып утырган булалар. Бала-чага бер өй, абзар башыннан күрше өйнең түшәменә сикереп күчеп йөри алганнар. Хәзерге авыл территориясендә бүгенге белән чагыштырганда ике мәртәбә күбрәк диярлек йорт урнашкан булган. Мин белгәндә дә әле Ситдык Фатыймасының өе Безводовканың очында, әзрәк читтәрәк утыра иде. Шуңа күрә дә, ул өй минем күземә күшеккән бәбкә кебек күренә иде.

Сөйләүләр буенча, элек, агачтан өй салганчы, җир йортта, землянка казып та яшәгәннәр. Хәтта читән өйләр дә булган. Әле шундый такмак та бар иде: “Фәләневнең читән өе ишелә дә башлаган, нәчәлниккә керү белән фатир эзли башлаган”.

Бездә бураннар, кыш көннәрендә, ышык урыннарны гына түгел, бөтен урамнарны да кар көртләре белән тутыра иде, күп өйләр түбәсеннән үк карга чума иде. Балалар үзләренә “тауга” санап, өй өстенә үрмәли башлыйлар иде. Без дә, сугыш аркасында этисез, ятим калган балалар, утыннар арасыннан сайлап алып

(ул вакытта утын кыш киселә иде) өрәнге агачыннан, үтәр-үтмәс балта белән ясаган чаңгыларда Мирәй, Зәрә тауларына шуарга бара идек. Хәзер бала чакта шуганда биек булып күренгән таулар түбәнәйгән, бәләкәйләнгән төсле. Алай да яннарыннан узган чакта, яшь чакны искә төшереп, кызыгып, шул тауларга карап, бар иде бит шундый чаклар, дип, барган юлымны дәвамлыйм. Дөрес, инде өлкәнрәк яшькә җиткәч тә, өйләнеп авылда эшләп йөргән чакларда, мин җәмәгатем Мөкатдимә белән, Хәбибулла абый Әминә апа белән, Әбделхәй абый Гамбәр апа белән, Әхәт абый Венера белән чаңгыларда да, болай да, бөтен кирәк әйберләрне алып (ашау-эчү өчен), Чокыр Бүләкләргә бергәләп бара идек. Төрлесе булды, чаңгыларда шудык, уенкөлке белән ял итә идек.

Бу минем үткәннәрне искә төшереп, хисләргә бирелеп, гамьләнүем бугай. Менә алдарак әйтелгән, тыгыз утырган салам башлы өйләр, Балыклы авылы, Октябрь Революциясенә кадәр дә, бер тапкыр бөтенләе белән диярлек, янып беткән дияләр иде. Минем дәү бабам Вахитның карчыгы Фаһизә (Файза), минем дәү әбием, инәйнең әбисе, шул янгын вакытында өйдә булып, өй әйберләрен урамга, кое янына ташый-ташый, янып үлә. Әби тумышы белән Камышлы кызы була.

Тагын, 1927 нче елны бугай, ниндидер Идрис дигән кеше өй башларында яшеренеп тәмәке тарткан, саксызлыгыннан ут чыгып, авылны яндырган. Ике йөздән артык йорт янды, дияләр иде. Хәер, хәзер тәмәке түгел, башкасын да яшермибез. Олырак кешеләр сөйләве буенча, Багаутдин бабайлар янындагы мәчетнең манарасы янгын вакытында янып, гөрселдәп ава. Янгыннар гадәттә җәй вакытында чыккан, җәй көне билгеле эшче авыл халкы күпчелек кырда булганнар, ир-ат печән, ашлык чапкан, хатын-кыз урак урган, көлтә бәйләгән. Хәзергәчә алар урамда эскәмиягә утырып көннәр буе көнбагыш чиртеп утыра алмаган, инде күптән сүнгән дәртләрен уятырга сериаллар карарга телевизор да булмаган. Пожарлар соңрак та еш кына булгаладылар. Янгын вакытында пожарный насосны кул көче белән эшләтәләр иде. Ул күп вакытта төзек булмыйча, яхшы эшләмәде, йә пожарный атының мичкәсендә суы җитәрлек булмый иде. Тап-таза ирләр янгын сүндерү урынына, төрле сүзләр белән бәхәсләшә-бәхәсләшә насос төзәтә иделәр, тишек шлангы-рукавларны алдан әзерләнгән чүпрәкләр белән томалый

иделәр. Аннан бер вакыт мотопомпалар чыкты. Яшен сугып янгын чыкса, кара сыер сөтен эзләп сибәләр. Ләкин бер кара сыер сөте генә салам башлы өйне, абзарны сүндерә ди, көтеп тор! 1950 нче елның җәендә безнең өйгә дә яшен суккан иде. Салам япкан өй башыннан, такта түшәм арасыннан кереп, яшен тәрәзә кырыен уеп чыгып киткән төсле иде. Кәфия әби ул вакытта ятып тора булган, ә инәй алдагы өйдә була.

Аның әйтүенчә: Чәчләрем үрә торды, ни булса да, бу бездә булды дип, тышка чыксам, салам түбәдән пыскып кына төтен чыгып маташа. Йорттан гына чиләкләр белән су алып, чөнки яңгыр бик нык яуган була, сибәләр, ут сүнә. Ә Кәфия әби байтак кына чирләп йөреде.

Ут-күз, янгыннар чыгу адәм баласына һәрвакыт бик зур бәла-каза китергән. Авыл кешесенең йорт-җире янып китү гаиләне зур бәхетсезлеккә китерә. Кешеләр яңадан ныгып китә алмаслык фәкыйрь-фокарәгә әйләнә. Әмма шунысын әйтергә кирәк, безнең Балыклы халкы андый бәлага төшкән гаиләләргә төрлечә ярдәм итә, йә өмәләрдә катнашып, йәисә матди яктан ярдәм итәргә тырышалар. Үзебезнең абзарлар да 1970 нче елны, балалар яз көне уйнап, ут чыгып янгач, авыл халкы өмәләрдә нык катнашып, абзарларны торгызырга ярдәм итте, рәхмәт.

Балыклыда артель оештырып, юкә агачының кабыгын кубарып алып, суга батырып тотып, мунчаласыннан кап (мунчала капчык) сукканнар, чыпталар (ат япкычлары) үргәннәр. Тугым бөгеп, тәгәрмәчләр, чана табаннары ясаганнар, талны кайнатып, дугалар бөгү бар иде. Авылда үзенә кирәкле хуҗалык сбруйларны һәммәсен ясаганнар, колхоз чакта да ясадылар.

Кыш көннәрендә Балыклы мужигы утынны Богырыслан базарына илтеп сата торган булган. Кыш көне киселгән чи агачны искертер өчен, кара мунчада төтенгә тотып, “коры утын” итеп сатканнар, дип сөйлиләр иде. Заманы өчен, тормыш өчен, бар да шулай кирәк булгандыр инде.

Ә үзебез күпме утын, ташкүмер яктык. Утынны үгез җигеп тә, бәләкәй кул арбасы “темпы” белән дә, ат, трактор, автомашина белән дә ташыдык. Ваклап та, буе белән тракторлар белән дә сөйрәттек. Ягулык мәсьәләсе иркен иде. Аш-су хәзерләү күпчелек мичтә, казанда башкарыла иде. Тора-бара примуслар, керогазлар, электр плитәләре кулланылды.

Газүткәргеч торба аша газны Камышлы Г.Р.Сыннан 1993 нче елны гына авылга уздырдылар. Аңарчы, бер ун-унбиш еллар баллонлы сыегайтылган газ белән плитәләрне эшләттек. Тик тулы баллоннар кайтарган көнне чират зур була иде. Киндераш, җитен үстереп, аны суда батырып һәм киптереп, талкып һәм тәрәшләп, сүсен эрләп, хатын-кызлар кыш буена киндер тукый булганнар (киндер ыштан, киндер күлмәк). Мин кечкенә чакта безнең өйдә дә әби туку станогында нидер сугып маташты-келәмме, паласмы, исемен белмим. Кыш көннәрендә сарык йоныннан тула сугу өмәләре бар иде. Алар әле сугыш елларында да булды. Мин үзем бер ара чабата белән тула оек киеп йөредем. Яз көннәрендәге су-сүл вакытында чабата астына агачтан (сөяннән булса яхшырак) күтәртмә ясап куялар иде. Түбәндәге иске мәктәптә укыганда, күтәртмәле чабаталы малайлар, араларында мин дә бар, коридорда шаколт-шокылт тик чабышып, тузан туздырып йөри идек. Дежур укытучы ачулана иде. Безнең, татарның, чабатасы җиңел үрелгән була, ә "мукшы" чабатасы зур башлы, ничектер тупасрак төсле була иде. Чабата "галош" та үрүчеләр бар иде, бугай.



# Күршеләр

Без Кләүле районына кергән вакытта андагы “Знамя Родины” гәҗитендә бер Никитин дигән кешенең мәкаләсе басылып чыккан иде. Анда безнең авылга бәйләнешле шундый мәгълүмат китерелгән: 1859 год. По реке Телегаз построена казенная деревня Давыдкино (Балыкла), состоявшая из 143 дворов с 437 душами мужского пола и 501 душой женского. В деревне работает одна магометанская церковь, по берегам этой же речушки, притулилась казенная деревушка Чекмаловка и помещичья деревенька Ст.Седяково, имевшие, соответственно 13 и 20 дворов, с проживающими в них 211 и 333 душами и далее...

Шундый ук мәгълүматны Казан архивы да раслап бирде. Димәк, Балыклыда бер йортта 6,5 кеше, ә Чекмаловкада, Седяковада 16 шар кеше яшәгән кебек килеп чыга. Чекмаловкада фәкать бер урам иде. Седяковосы тормыш өчен, әлбәттә, яхшырак урынга урнашкан иде. Бәләкәй генә өч урам иде мин анда эшләп йөрегәндә (1950ел), әмма андый зур йорт-өй-16 кеше сыеп, яхшылап яшәрдәйне берне дә күрмәдем, андый йорт юк иде.

*Богырыслан архивыннан алынган мәгълүматлар*

**Сведения о полной площади будущего 1919г. по Байтуганской волости.**

| | Посеяно десятин 1918г. под озим. | Приблизительная площадь под яровые 1919г. | Сколько подготовлено осенью 1918г. под яровые |
|---|---|---|---|
| Балыкла | 1045 | 1045 | 600 |
| Ст. Выселки | 283 | 283 | 200 |

| | домов | едоков | дойных коров | лошадей | | | овцы | козы | общ. посеяно яровых посевов | 1920г. | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | мерин | матка | жеребят | | | | озимые | яровые |
| Балыкла<br>Выселки<br>Др. села | 442<br>95 | 2600<br>685 | 282<br>107 | 299<br>80 | 300<br>90 | 220<br>50 | 1149<br>50 | 124<br>- | 841 | 320 | 380 |

Анализ ысулым дөрес булса, XX гасыр башында, ягъни 1920 нче елда, безнең Балыклыда бер йортта 6 кеше яшәгән, ә Ст.Выселкада-7 кеше булган. Бездә савым сыерлары 9 кешегә бер баш мал-сыер туры килә, димәк халыкның 63% ты гына

сыерлы булган, 160 йортта сыер булмаган, ә Ст.Выселкада-сыерлар 6 кешегә бер баш, ягъни-112%, анда сыерсыз йорт булмаган.

Атлар Балыклыда һәр йортта 1.3 ат, йәисә уртача тик 157 хуҗалыкта гына ике ат булган-35 процентында. Ст.Выселкада бер йортта 1.8 ат, якынча икешәр ат йорт саен туры килә. Балыклыда 1918 нче елны яз көне йорт исәбенә 2.3 десятнә, ә Ст.Выселкада-3 әр десятнә ашлык чәчкәннәр.

Шушы гади генә цифрлардан күрше авыл украиннарның Балыклы халкына караганда яхшырак яшгәгәннәре күренә.

Ә авыл безнең 1859 нчы елдан 1918 елга кадәр, 61 ел эчендә, 299 йортка һәм 1662 кешегә арткан. Ел саен уртача 5 йорт һәм 27 кешегә артып торган. Биредә, әлбәттә, күчеп килүчеләр исәбеннән генә бу ишәю булмагандыр, күрәсең табигый балалар күп туу да сәбәпчедер.

Ә чәчү мәйданнары 1918 нче ел белән чагыштырганда, күпкә кимегән. Чөнки, ике ел революция, аннары гражданнар сугышы...

Алпавыт-помещиклар бу якларга 1761 нче елдан килеп утыра башлаганнар. Неклюдов, Дурасов, Осоргин, Сидяков һәм Степан Кротков. Алар үзләре Сембер губернасында яшәгән, ә менә Степан Кротковның алган җирләрен аңа кадәр Ганькино чувашлары һәм Давыдкино-Балыклы халкы үзләренә межалап биләгәннәр һәм эшкәрткәннәр. Тик Степан Кротков үз кешеләрен Безводовка авылыннан алып килеп, шул җирләргә урнаштыра. Ганькино чувашлары депутат Гавриил Давыдовка зарланалар. Ул Әби патшага-Екатерина икенчегә хат язып, запрос бирә, тик Әби патша бернинди дә җавап бирми, аның мондый "вак-төяккә" вакыты юк. Кротков бернигезсез үзенә алган җирләрдә Балыклы кешесе Юсуп Ангалышевның җирләре дә була. Ул, монда җире әзәю сәбәпле, калган җирен сатып, Бөгелмә ягына китә.

Отставкадагы капитан Степан Кротков чувашларның Анлы елгасындагы 5 тегермәнен вата, малларын тота. Шул чорда

Е.Пугачев кузгаткан фетнә башлана. Гавриил Давыдов, Юсуп Ангалышев меңләгән кеше җыеп Пугачев ягында "тәртип урнаштыра" башлыйлар. "Тәртип урнаштыручылар" Бөгелмә-Богырыслан-Бозаулык-Кләүле якларында йөриләр. Камышлының "Туң каен" урманнары ягында да шуларның отрядлары йөрегәне бик мөмкин.

Ә Степан Кротковның, 1774 нче елны, Пугачев отрядлары җиңелгәч, бер төркеме, обоз белән кыйммәтле товар: келәмнәр, көмеш әйберләр, тукымаларны төягән олауларны шул Кротковның кушуы белән талыйлар. Степан Кротков болардан капитал ясый һәм 6 сукно җитештерү фабрикасы кора. Анда Стеапановка кешеләреннән башка, Конновка авылыннан да килеп эшлиләр. Кротков Степановкага тагын 50 ләп хатын-кызлар китерә. Монда инде хатыннар ирләрдән күбәя. Безнең авыл халкы Степановкага Марҗа (Мария) авылы гына дип йөриләр.

Монда Степан Кротковның Шувалов дигән приказчигы эшли. Ул бик усал кеше була. Степановкада әле хәзер дә Полотнянщиков фамилияле кешеләр бар иде. Степан Кротков хәзерге Похвистнево районында Кротково авылын төзи. Малае Дмитрий атасыннан да усалрак була. 1839 нчы елны Шигонда (Самарская Лука) зур янгын чыга. Дмитрий: “Нигә минем йортны сүндермисез?!”, дип, крепостной крестьяннарын кыйный башлый, ә тегеләр моны тотып алып, яна торган өенә ыргыталар...

Монда килеп зур военно-полевой суд ясыйлар. Жандарм 11 мужикны аттыра, 10 кешене кыйната, аларның 4 се лазаретта үләләр, 6 кешене каторгага, 47 кешене Себергә сөргенгә озаталар. Степан Кротковка күбрәк тукталдым, чөнки алар бит безнең якын күршеләр, 8 генә чакрым арабыз. Истәлеккә Балыклыда авыл башына таба елга-чокырны Кроткау чокыры дип йөрибез. Бәлки, Гавриил Давыдов һәм Юсуп Ангалышевның да җирләре, Кротков монда килгәнче, шул якта булгандыр.

Бу материалларны Байтуган кешесе Ә.Х.Бәдретдиновтан алдым. Анда Энциклопедический словарь Брокгауза и Эфрона.М.1890. Кротковы.

# Кем соң без, татар-мишәрләр?



Тюрк-Болгар-Татар этносының эволюциясе турында Ф.К.Ширияздановның "Волжская цивилизация на Волге" дигән китабыннан берничә өзек укып карыйк. ...Кытайлар тарафыннан әкрен, но план буенча чит җирләрне "Ефәк кортлары кебек кимереп алу, аларны бу җирләреннән куу була". Шулай итеп, кытайлар янәшәсендә яшәгән хунн (гунн) халкы яртылаш утрак, бер урында яшәгән һәм, вакыты белән, күчмә тормыш та иткән (җәй көне). Алар ипи, ит ашаган, матур киенгән, мунчада юынган. Кытайлар зур йөремәгән, дөге ашаган, хатыны бала үстергән. Хунн-Гуннар Дуло төбеннән. Аның нәселеннән Атилла (375-452 ел). Ул гений, бөек полководец, хәтта Римга барып җитә. Атилланың үлгәндә 184 малае кала. Тик үзе үлгәч, дүрт елдан, Атилланың төзегән импрериясе таркала.

Төрек общинасы берләшә башлый Гуннар чорыннан. Алар Үзәк Азиядә тимер эшкәртә башлыйлар, армияләрен яңадан коралландыралар. Башта Тюрк каганаты төзелә. Ләкин аларны кытайлар җиңә. Аннан соң-Хәзәр каганаты, Бөек Булгария. Якынча Дуло төбеннән булган Кубрат хан (632-642) Бөек Булгариядә "Болгарларга болгар канын коярга ярамый",-дип үз халкына әмер бирә. Болгарларны бергә җыя. Кубрат хан үзе картайгач балаларын җыеп себерке бирә. Мәгез, шуны

сындырыгыз, ди. Тегеләр себеркене сындыра алмый. Хан аны сүтә дә, менә хәзер сындырыгыз, ди. Малайлары чыбыкларны берәм-берәм сындыралар. Менә шулай бергә булсагыз, сез Бөек Булгарияне сакларсыз, ди, Кубрат хан. Ләкин малайлары һәрберсе үзенә аерым яшисе килә. Бер улы Аспарух Дунай буена китә, анда славянлаша, тик Болгар исемен саклый. Бер малае Баян (Батбаян) Кавказда урнаша, икесе, ахыры Паннония (Венгриягә) китәләр. Ә берсе, Котрог дигәне бугай, Кара диңгез буенда, шул ук түгелме икән Идел-Волга буенда урнаша. Биредә фин-угор халыклары белән тюрк телле халыклар да яши була. Аннан соң монгол-татарлар-Чыңгыз хан һөҗүм итә башлый. Бераздан Монгол империясе дә (исторически) таркала. Көнбатышта, Дәште Кыпчакта, Жучи Олысы-Алтын Урда оеша. Тора-бара, тарихта билгеле булганча, Идел-Урал буйларында "эз" калдырып яңа ханлыклар Алтын Урда да таркала. Ул Алтын Урдада төрле халыклар яшәсә дә, төп халык төрки телле кыпчаклар була. Шиһабетдин Мәрҗәни "Кыпчаклар ул болгарларга тугандаш, ләкин алардан аерым", ди. (Ш.Мәрҗәни, "Казан вә Болгар". Казан, 1989 ел, 21 бит). Мәрҗәни фикеренчә, хәзәрләр һәм болгарлар ул вакытта башта бер дәүләт составына керәләр, соңыннан ике кисәккә бүленеп, көньяк өлеше-Хәзәр исеме, ә төньяк өлеше-Болгар исеме белән таныла. Болгарлар һәм кыпчаклар арасында, нигездә, зур этник аерма күренми. Шул ук вакытта татар этносы составына фин-угор (мушы-мадьяр) компоненты керүен теркәп китә.

Башка тарихчы, Равил Фәхретдинов "Казан утлары" журналында басылган "Татар улы татармын" дигән мәкаләсендә болай яза: Татар халкы зур этнографик төркемнән тора: казан татарлары, мишәр татарлары (Бу ике төркем үзләре Урта Идел һәм Урал буе татарлары) дигән зур бер этник-мәдәни төркем тәшкил итәләр. Шулай ук Себер, Әчтерхан һәм Кырым татарлары ханлыкларының төп халыклары булып саналалар һәм барысы да, халык буларак, бер чорда, XY гасырның ахыры, XY1 гасырның беренче яртысында формалашалар. Монда мишәр татарлары гына бераз аерылып тора, чөнки аларның ул вакытта өздереп кенә әйтерлек үз милли дәүләтләре булмаган. Ләкин мишәрләрнең халык буларак оешуы Казан һәм Касыйм ханлыклары белән

янәшәдә, аларның төп халкы белән бергә бик тә тыгыз этник һәм мәдәни мөнәсәбәттә барган. Хәер, кайбер чыганаклар мишәрләрне Казан ханлыгында итеп күрсәтәләр, җитмәсә аларның нигез бабалары кыпчаклар булган, диләр.

Зур бер дәүләт Алтын Урданың үзәк җирләрен төп төрки халык тәшкил иткән. (Литва, Польша, Румын татарлары дип йөртелгән татарлар шул ук 15-16 нчы йөзләрдә, татар дәүләтеннән бер читтәрәк формалашалар).

Татарларның бабалары-кыпчаклар (Русча Иделнең уң ягы-половцы) булган, үзләре инде 15-16-нчы йөзләрдә үк "татар" исемен йөрткәннәр... Аларның теле хәзерге татар теленә, беренче чиратта Көнбатыш диалектына якын. Кыпчаклар хәзерге Пенза өлкәсенә һәм аның тирә-ягына 14-15 нче йөзләрдә үк күченеп утырган булалар. Алар анда Урда кнәзләре, мәсәлән, Сикиз би, Тагай, Бикан атлы биләр җитәкчелегендә киләләр. Ул җирләрдә зур гына татар олысы оеша, аның сәяси үзәге Наручад (Мукшы) шәһәрендә була. Шунда ук акча да сугыла. Бу хакта урыс елъязмалары да, нумизматика материаллары да ачык сөйлиләр. Мордва АССР да табылган татар шәҗәрәләре буенча Сәетәхмәтевләр, Адашевлар, Кудашевлар, Янгалышевлар дип аталган татар-тархан, кнәзләре билгеле. Бу турыда безнең авылдашыбыз Р.Т.Мәрданов "Ср. Елюзань" исемле китабында да яза. (36 бит).

Татар теленең мишәр диалектында кыпчак нигезе булуын Казан галимнәренең соңгы үткәргән тикшеренүләре дә раслый. Тел галиме М.Зәкиев мишәр этногинезында кыпчаклардан тыш, борынгы халыкларның да катнашын әйтә. Шулар астында гарәп-фарси географиясе һәм Византия чыганаклары буенча билгеле булган Сөн кабиләләре берлегенә кергән акацирлар (агач урман кешеләре) һәм соңырак-маҗарлар. Маҗарлар турындагы фикерне куәтләп, мин мишәрләрнең этник телендә беркадәр болгарлар да катнашкан дип уйлыйм... (Ә рус теленең катнашы тагын да күбрәк. Р.Б.) Мишәрләрдә болгар компоненты булса да, зур түгел. Казан ханлыгында Ногай татарлары да катнаша, ә керәшен татарларының телендә фин-угор элементы күбрәк, дип яза Равил Фәхретдинов.

Безнең татар халкының бабалары кем булганлыгы хакында өч төп караш бар, дип яза Равил Фәхретдинов.

*Беренче татарлар-монголларның токымы*

12-13 йөзләрдәге чыңгызлы монголлар белән уртаклык юк, чөнки алар антропологик-европеидлар.

Татарлардагы өлешчә монгollыкны антропологлар нигездә кыпчаклар (половцы) белән бәйле, дип әйтәләр. Ул Себер, Әчтерхан татарларында күбрәк тә. Эш шунда ки, 12-13 йөздәге монголлар, татар-монголлар, хәтта татарлар дип тә аталганнар. Кем соң алар, борынгы татарлар?

Ү1-ҮШ гасырларда Көньяк Себер һәм Урта Азия җирләрен биләгән Көнчыгыш Төрки каганлыгының халкы арасында “татар” исемле төрки кабиләләр дә булган. Шунда “Отуз татар” (Утыз татар), тагын Токуз татар (Тугыз татар) кабиләләре булган. Борынгы татарлар 1Х-Х йөзләрнең Кытай чыганакларында да искә алыналар. Кытайлар аларны “да-да”, “та-тань” дип атаганнар. Х1 гасырда яшәгән атаклы уйгур филологы Мәхмүт Кашгари

Төрки кабиләләре арасында татарларны да атый. Алар Көньяк Себер, Урта Азия-монголлар белән күрше яшәгәннәр. Чжао-Хун татарларны (анынча монголларны) өч ыругка бүлә:

Кара татарлар (Хэй да-да), Ак татарлар (бай да-да) һәм Кыргый татарлар (шу да-да). Кытай әдәбиятында ак татарлар дип, гадәттә, Онуглар аталалар. Алар чыгышлары белән төрки телле кабиләләр булганнар. Бу хакта Рәшитетдин һәм И.И.Кафаров (Палладий) да шул фикедә торалар.

Ак татарлар дип аталучы татарларның буй-сыннары нәзек, үзләре әдәпле һәм ата-аналарын ихтирам итәләр диелә. Мэнде-бәй-лу да.

Кара татарлар һәм кыргый татарлар исә җәйпәк йөзле, киң яңаклылар, күзләренең өске керфекләре юк.

Ак татарлар Буир Нур һәм Колын Нур күлләре тирәсендә яшәгәннәр. Тимучин (Чынгыз хан) татарларга гомере буе үч тота, чөнки татарлар аның атасын үтергән булалар.

(Буир Нур ул Манчжурия-Халхин Гол тирәсе түгел микән?Р.Б.)

Сугышта Чыңгыз хан, каршы як гаскәрләренә һөҗүм иткәндә, татарларны алдан, беренче итеп җибәрә булган.

Шуңа, бөтен җирдә, һөҗүмгә дучар булучылар: татарлар килә!, дип, кычкырганнар.

Чыңгыз хан үзенең төп халкын-монголларны саклаган, чөнки

сугышта беренче, алдарак баручы күбрәк үлә төшә. Күп кенә татарлар көнбатышка китә. Алар барысы да кыпчакларга охшап калалар, дип яза тарихчы Равил Фәхретдинов.

Мин Әбүзәр Бәдретдинов туплаган тарихи материаллар арасыннан Саниәхмәтов Кузиәхмәт кульязмаларыннан шундый мәгълүматлар игътибарга лаек дип язып алдым:

-Татарский язык относится к кыпчако-булгарской подгруппе, кыпчакской группы тюркских народов;

-Башкирский язык принадлежит к кыпчако-булгарской подгруппе, западно-хунской ветви тюркских народов;

-Чувашский язык относится к тюркской языковой семье.

Без, хәзерге татарлар, башкортлар белән үзара җиңел, толмачсыз сөйләшә алабыз. Бик күп сүзләр безнең телдә дә, башкорт телендә дә охшашлар, йәисә бик аз аерылалар.

Еш ишеткән бар: татарча салкын, суык су, башкортча һуык һу дияләр, Уфа каласы-Өфе калаһы, әтәй-атай, инәй-әсәй. Безнең Балыклы мишәрләре сөйләвендә "чокать", "цокать" итү юк, ә Ярмәклеләр сөйләвендә "ч" һәм "ц" авазлары кулланыла, ә алар үзләрен мишәргә санамыйлар. Без, Балыклы халкы аерымрак җирдән килгәнбез, күрәсең. Чөнки кайсебер сүзләр бары тик

Балыклы мишәрләре телендә яшиләр. Мәсәлән: Бума-буа, рашкы ява-боз ява, вана-әнә, бүлбе-бәрәңге, аркан-бау, еп һ.б. Хәер инде хәзерге мәдәният-цивилизация йогынтысы, информатик чаралар-радио, телевидение, мәгърифәт ярдәмендә безнең мишәр, Һади Такташ телебез, көн саен салмаклап, әдәби телгә, Тукай теленә якынлаша.

Шулай, безнең татарларның тарихы Хунн-Гунн кабиләләренең "Бөек күчем"е чорыннан алына. Алтай киңлекләреннән, Кырым, Казан, Әчтерхан далаларына кадәр татар халкының оештырылган, оешкан ареалы. Шунда безнең милләт гасырлар агымында, үз телен, мәдәниятен, үз икътисадын оештыра. Ә Тюрк каганаты, Манчжурияләре, Кара диңгез буйлары, Енисейдан Амур елгасының югары яклары тарих картасыннан югалмаган. Сахалин утравы белән материк арасындагы бугаз-пролив "Татарский" дип атала, күп кенә үсемлекләр "татарник", "татарский" дип йөртелә.

Тюркләрнең төп шөгыле-мал асрау, үрчетү булган. Алар сарык, ат, дөя үрчеткәннәр, аучылык белән шөгыльләнгәннәр. Монда инде аларга хас булган акыл да, кыюлык та, бердәмлек тә кирәккән.

Бик еш сугыш бәрелешләре булу сәбәпле ир-атлар һәлак була. Гаиләдә ир-ат үлсә, аның хатыны, балалары ятим калдырылмаган, аларны туганнары үзләренә алган. Ирдәге хатынны көчләү булса, көчләүчене үлем көтә. Әгәр кем кызларны котыртып аздырса, ул аңа өйләнергә тиеш була.

Тюркләрнең дине Тәңре-Зәңгәр мәңгелек һавага табынганнар. Дөрес, кайбер чыганакларда параллель рәвештә шаманнар булуы искәртелә.

Соңыннан Тәңрегә-перс-фарси сүзе Ходай керә, тагы да соңрак гарәп сүзе-Аллаһы Тәгалә. Әле бит хәзер дә мөрәҗәгать итәбез: "И Ходаем, Тәңрем! Аллаһу Тәгаләм, үзеңә генә ышанам, Үзеңә тапшырам!" - диябез ич.

Мин, Рәшит Билалов, бу язмаларны төрле чыганаклар, борынгы һәм замандаш авторларның хезмәтләрен кулланып, аз гына үземнән өстәп, гомумән татарның һәм авылыбыз мишәрләренең тарихына кагылышлы мәгълүматларны, кулымнан килгән кадәр ачыклап, шушы җыентыкка теркәп калдыру максатыннан тырышуым. Өметем шул, бәлки киләчәктә бу язмаларны укып, авылыбыз тарихына битараф булмаган, илгәсәк шәхестә кызыксыну уяныр, ул тагын да тирәнрәктән эзләнеп, башка билгесез материаллар табып, өстәмәләр кертер, минем ихтыярсыз җибәргән хаталарымны төзәтеп, тарихыбызны тулыландырыр, иншаалла.

## Сходство и различие Балыклинских, Старо- и Новоермаковских татар-мишарей

Р.Т.Марданов.

...В формировании населения трех сел: Ст.Ермаково, Нового Ермаково и Балыклы наряду с ясачными татарами, татарами типтярами и башкирами активное участие приняли служилые татары-мишари, выходцы с правобережья Волги.

Нужно отметить, что мишарский компанент в формировании этих сел оказался подавляющим, что сказалось на языке, культурно-бытовых особенностях жителей этих сел.

Остановимся подробнее на этой группе татар Поволжья.

Происхождение татар-мишарей до сих пор является вопросом спорным. Одни считают за отатарившихся финнов, другие приписывают им тюркское происхождение. В исследованиях последних десятилетий мишари-это подвергшиеся тюркизации

в конце 12 го и начало 14 го веков финно-угорское население правобережья Ср.Волги. (Подробно этот вопрос решается в книге Р.Г.Мухаметова “Татары-мишари”. М. 1972г.)

Мишарский язык считается одним из диалектов татарского народа. По культуре мишари почти не отличаются от татар. Территорией формирования татар-мишарей является лесостепная полоса правобережной части Поволжья в бассейне рек Цны и Мокша - правых притоков Оки, а также в верхнем течении реки Суры и ее левых притоков (современная территория Пензенской, Тамбовской областей, Мордовской АССР).

В начале XX го века исследователем мишарей выступил профессор Казанского университета Г.М.Ахмеров. Он отмечал, что Казанские татары отзываются о мишарях, что они говорят жестоким и грубым языком. Мишари говорят громко и жестко, в разговоре мешают русские слова с татарскими. Язык мишарей, преимущественно татарский, но в нем сильно влияние русского языка. Мишари сами себя называют татарами, а название “мишар” считают оскорбительным. На вопрос “мишар?” -отвечают бранными словами. В то время как башкиры, киргизы, когда им говорят о своей национальности, бьют в грудь в знак гордости. (Г.М.Амирханов. О языке и народности мишарей. Журнал “Известия общества археологии, истории, этнографии при Казанском университете”. К IX выпуск 2 Казань 1903г.)

Проживая первоначально в правобережье Волги, мишари были ближе к русским землям, чем к казанским татарам. Отсюда и русское влияние на мишарей в языке и культуре. В этой книге Г.М.Ахмеров писал, что мишари участвовали в походе в Казань и во взятии Казани в 1552 году. Оставались в большинстве своем верными царскому правительству во время бунтов и волнений. Служилые татары-мишари участвовали в усмирении башкир, за что были жалованы льготами и землей. Ахмеров далее продолжил, что, мишари, более благорасположены к другим, чем казанские татары. Многие занимаются торговлей, лучше знают язык. В губерниях Симбирской, Самарской, Казанской, Оренбургской мишари занимались конокрадством. Иногда поголовно деревни занимаются этим постыдным промыслом, у казанских татар такое явление редчайшее.

Мишари имеют старинные татарские имена, а у казанских татар они заменены арабскими, влияние ислама. В фамилиях мишарей слышатся монголо-татарских ханов, полководцев, Узбек (Узбеков, Узбяков), Ногай (Ногаев), Мамай (Мамаев). Фамилии мишарей старинны и восходят от казакского корня (Акчурин, Ямашев).

Фамилии казанских татар образуются по отцу. Ахметзян-Ахметзянов. Мишари не проводят "Сабан туй", "Джиен" (Летний увеселительный праздник) существовавший у Казанских татар до конца 20 тых годов XX века. Такие различия находил Г.Н. Ахмеров между мишарями и казанскими татарами, применительно к концу X1X го началу XX го века.

Применительно к нашему району эти различия естественно почти стерлись, хотя некоторые различия все-таки остаются. Особенно это чувствуется в говоре мишарей и казанских татар. По говору жители Балыклы, Ст.Ермаково и Ново Ермаково относятся к татарам и мишарям. Однако в научной литературе мишарей по языку делят на "чокающие" и "цокающие". И это явление служит одним из основных признаков принадлежности к мишарям и разделения мишарей на две основные группы, темниковскую и артачскую группу. Проще говоря, мишари должны или "цокать" или "чокать".

Если староермаковцы и новоермаковцы "Чокают" в произношении слов, то представители третьего села из неказанских татар Балыклы "не цокают" и "не чокают". Получается, однако, интересная картина. Жители сел казанских татар на вопрос о мишарях в первую очередь называют балыклинцев, а уже потом, как бы невзначай, жителей Ст.Ермаково и Ново Ермаково, "Ах, да, они ведь тоже мишари".

В первую очередь мишарями казанские татары считают балыклинцев, видимо потому что язык балыклинцев жестче, чем у ермаковцев. Это отмечается и в материалах этнографической экспедиции 1979 года.

Встает вопрос, почему у балыклинцев нет характерного, как это считает автор книги "Татары-мишари" Р.Г.Мухаметов "цоканья" или "чоканья" в произношении слов? По-видимому, жители сел Балыкла и Новое Ермаково в большинстве своем были служилыми татарами-мишарями из разных мест правобережья Волги, что и наложило отпечаток на языке этих сел.

# Уеннар һәм төрле фигыльләр, тормыш ич

Элегерәк елларда, сугыштан соң, ХХ нче гасырның урталарында кызлар, егетләр, аулак өйләрдә (ата-аналар каяда киткәндә) төрле матур уеннар уйныйлар, җыелышып урынаш кыралар. Безне, бәләкәйрәк малайларны бик кертмиләр, кызлар зурырак, җиткәнерәк егетләрне сайлыйлар иде, бәлки егетләр аларны алданырак сайлагандыр. Ә бераздан без дә сыя башладык. Язгы Нәүрүз бәйрәмен аерым уздырылганын белмим, хәтерләмим.

Ә менә язгы бәйрәмнәрнең берсе, тугайда, кардан иртәрәк ачылган чирәмгә чыгып, кичке уеннар уздыру бар иде. Анда күмәк уеннар, әйлән-бәйләннәр, тальян гармун, атаклы Гали гармунына кушылып такмаклар, такмазалар, милли җырлар башкарып, яшьләр дә, хәтта урта яшьтәгеләр дә катнашып, бик күңелле, җанлы итеп ял итәләр иде. Болар өстенә кышкы, язгы күренешләргә бәйле бер кызыклы йолага да игътибар итми булмый, ул- кышны озату. Бозлар кузгалган көнне, Ташпулаттан шарлап ташу акканда, икенче бригад йортыннан салам, читән частокол чыбыклары җыеп, боз өстенә учак ягып, шул боз белән кышны озату чарасы уздырыла иде. Бу уеннар кичен, төн куера башлаганда була иде. Ә бала-чага, мәктәп яшендәгерәкләр шул ташу вакытында ярдан бозга, аккан боздан ярга сикерешеп уйныйлар иде. Ялгышмасам, Экажев Шәрип абзыйның бер малае, Микаэль боздан читкә тайпылып суга егыла, ташкын үзен агызып, купмаган бозлар астына тартып кертә, шунда һәләк була.

Тагын “Лапта”, “Гузна”, “Городки”, акча чиеш кебек һәм башка төрле уеннар уйнала иде. Бала-чага, яшь-үсмерләр, кыз-егетләр авыл тулы була иде, бар да клубка гына йөрмиләр.

Сабан Туена әзерлек зур җаваплылык таләп итә. Иң элек Сабан Туе булачак урынны- мәйданны әзерләү. Оештыру эшләрен авыл советы рәисе, секретаре, партоешма секретаре, колхоз җитәкчеләре башкаралар. Сабан Туе бездә, гадәттә, Каршы урманда уздырылды. Яшь егетләр атларга атланып, сөлге-яулыклар, ә ияреп йөрүче бала-чага йомырка җыялар. Колхоз тәкәне, башка бүләкләрне хәстәрли. Сабан Туен ачып җибәрү тантанасында хезмәт алдынгылары ирешкән уңышларын

билгеләп, җылы рәхмәт сүзләре әйтәләр, бүләкләр тапшыралар, аларга багышланган җырлар башкаралар. Шуннан соң Сабан Туеның иң кызык чаралары, төрле ярышлар, бәйгеләр башлана. Көрәш, атлар чабыштыру, кузла өстендә капчык белән сугышу, сикерү, аякларга капчык киеп, йомырка салган кашыкны авызга кабып узышу, сулы чиләкләрне көянтә белән иңбашка салып йөгерешү, биек тә, шома да баганага менү, кырын багана буйлап бару, гөр, штанга күтәрү, аркан белән күмәк тартышу (звенолап, бригадалап) кул көчен сынау һ.б. Махсус корылган сәхнәдә җыр, биюләр, төрле мәзәкләр башкарыла. Татарның борынгыдан калган иң мавыктыргыч, Сабан Туеның үзәк вакыйгасы-билбау белән көрәш. Төп мәйданда көрәшне яшь-җилкенчәк башлап җибәрә. Көрәшчеләрне, яшьләре һәм буйлары бер чамада булганнарны билгеләнгән судьялар (өлкән яшьтәге, заманында тәҗрибәле көрәшчеләрдән) очраштыралар. Аннан, үз чираты белән егетләрне, урта һәм олырак яшьтәге теләүче ирләрне очраштыралар. Бил алышуда һәр категория җиңүчеләренә чиккән сөлгеләр, кыйммәтле бүләкләр, призлар тапшырыла. Инде, сайланып финалга чыккан ике иң көчле, иң оста көрәшче батырга-батыр көрәшеп, бил алышалар, җиңүчегә әлбәттә, төп баш приз-тәкә һәм өстәмә бүләкләр, я келәм, телевизор, суыткыч, оештыручыларның матди мөмкинлекләреннән чыгып. Батыр калган пәһлеван тәкәне җилкәсенә алып, мәйданны урап әйләнеп чыга. Ә Сабан Туеның башка ярышлары бүтән мәйданчыкларда дәвам итә, шулай итеп яз һәм хезмәт бәйрәме кичкә чаклы күңелле итеп уза. Электән дә һәм хәзер дә авылда төп шөгыль ул-кырчылык, шул авылның терәге, авыл йөрәгенең тибешен, сулышын куәтләүче шәхесләр. Авылыбыз тарихында безнең яшәешебезнең тарихы. Чөнки без бу дөньяда "кунакта" гына. Ни дисәң дә, тарих тәгәрмәчеирегә әйләнми. Безнең Сабан Туе уздырыла торган урман буйлары, хәтфә үләнле, төрле гүзәл чәчәкле аланлыклар кебек үк матур урыннар тирә-якта юктыр да кебек. Балыклының көнъягында язгы көннәрдә, күгелҗемләнеп торган урманнар ягыннан, иртәнге тынлыкта көртлекләр уйнаганы, басулар ягында сабан тургайлары сайравы, күкеләр кычкырганы, сандугачлар сайравы, кич-кырын сазлык-әрәмәләрдә тартарлар, буаларда-кыр үрдәкләре, торналар табигатькә алыштыргысыз, кабатланмас ямь өстиләр. Ә миңа, бигрәк тә башта трактор бригадасында учетчы, аннары, агроном

буларак, алар белән еш очрашырга, сокланып күзәтергә туры килде, чөнки алтмышынчы елларда күбрәк җәяүләп, ат җигеп я атланып кыр-басуларны карап йөрелә иде. Балыклының төнъяк-көнчыгышында бик биек булмаса да, яз көннәрендә сап-сары умырзая чәчәкләре ата торган, арткы аякларына басып, сызгырып бер-беренә сәламме, сигналмы биреп, сыркалар колониясе яши торган, артыннан алсу таңнар ата торган, Заря тавыбыз бар. Авылның урамнарын бишбармак рәвешендә бүлгәләп урнаштырган Шарлама, Ташпулат, Җәмилә, Балыклы-Су "Балыклинка", барысы бергә кушылып, инеш булып Тиләгәзгә ага, ә Тиләгәзебез суларын Сок елгасына коя. Авылыбыз бик континенталь климатлы урында урнашкан. Еш кына кышкы зәһәр салкыннар битләрне чеметә, сулыш алганда тамакны кытыклый, тынны кыса. 1978-1979 нчы Яңа елда тыштагы температура-50 градуска җитте. Соңгы елларда кышлар җылырак булу белән, элек тә шулай булган дип булмый. Сугыш башланган елларда урманнарда бик күпләп имән агачлары туңалар һәм корыйлар, без аларны соңыннан утынга кистек. Тагын бер эпизод. Сугыш соңындагы елларда Мусин Саяр бабай үз йомышы белән Степ-Выселкага җәяүләп барган (билгеле инде ат юк, ара 7-8 чакырым). Күтендә бер кат ыштан, аягында әлбәттә чабата булган. Кире кайтканда каршы бик салкын җил чыга. Бабайның суыктан "нәзек җирләре" җенси әгъзәләре туңа. Карчыгы Пәрвәз әби, күрше тирә-яктан каз майлары табып алып, шуны канат белән тегенең туңган җирләренә сөртеп тора-тора, Саяр бабайны үлемнән коткарып калды, дип сөйлиләр иде, тирә күрше хатыннар, астыртын гына елмая- елмая. Өермәле карлы-бураннар да бездә еш кына булгалый. Хәтта тирәдәге авылларга караганда да, бездә кар күбрәк ява. Ә көзге яңгырлар бер ява башласа, тәүлеге белән талгын гына шыбырдый бирә, вакыты белән шәбәеп куя, шуңадыр аны "үтереп" ява, я "эченнән алды", диярләр. Кайчан гына ямь-яшел киемдәге, шаулап утырган урманнар, шәрә килеш тирән уйга калган кебек, тып-тын утыралар. Тик кулдан утырткан нарат, әз генә чыршы (аларны күп чакта пошыйлар ашамасын өчен утырталар) агачлары яшькелт төс биреп торалар.

Балыклыдан читтәрәк инде дә, Степ-Выселкадан Неклюдово ягына барганда уң яклап урман ягалый 1970 нче елның язында лесничий Баскаков Виктор Матвеевич (инициатор) мин-агроном,

Божко Спиридон Андронович - лесник, бергәләп киңәшеп Ст.Выселка хатыннары белән колхозның урман кырыендагы бер гектар чирәменә башта зур түгәрәк боҗра, аның эченә йолдыз һәм Ленин, 1870-1970, дип, тамгалап, билгеләп чыктык (разметка), соңыннан хатыннар кул белән вак, яшь наратлар утырттылар һәм ел саен аларны карап, тәрбия күрсәтеп тордылар. Мин берничә ел араларыннан печән дә чапкаладым. Хәзер инде анда 45 яшьлек мәхәбәт наратлар үсеп утыралар. Лесостроительләр аэрофотосьемка ярдәмендә эшләнгән фотосүрәттә бик тә матур күренәләр иде. Еллар узып, гасыр урталарында, инде өлгергән агачларны кискәч, төпләреннән укырлар әле, бу "Кремлевский мечтательгә" һәйкәл икән, дип. Безнең халык ул җирне "Звездочка" дип йөртәләр.

Климатыбыз турында дәвам итик. Кышларда бездә кар күп ява диелде бит, ә җәен, тирә-якта яңгырлар яугаласа да, Балыклыда еш кына корылыклар була. Безнең авыл бит субүлгеч (водоразделда) биеклектәрәк урнашкан, мөгаен шуңадыр да яңгырлар аз ява. Авыл халкы карчык-корчык бигрәк тә, күктә берәр болыт кабарса, шуңа карап догалар укып, теләкләр теләп йөриләр иде. Аннары, җыелышып "яңгыраш" йоласы уздыралар иде. Алдан әлеге карчык-корчык, бабайлар, ә аларга ияреп без, малай-шалай йөри идек. Яңгыраш бәйрәме, гадәттә, Әсәкәй тавы итәгендә, Изгеләр чишмәсе янында аш-су әзерләп үткәрү бар иде. Берсен мин малай булсам да хәтерлим әле. Сугыштан соң 1947 нче ел иде бугай, аш-су әзерләп, идин (единоличник) "Яврәй" Шәйхетдин бабайның аты белән бардылар һәм үткәрделәр. Намазлар, догалар укыдылар. Без җәяү ияреп йөредек. Ә аннан кайтканда кем очыраса шуны, коедан чиләккә су алып коендыралар һәм такмаклыйлар: "Яңгыр яу-яу, иләкләп тә чиләкләп, илгә ачлык килмәсен, ачтан халык үлмәсен, иписез интекмәсен!". Тик безнең ул тырышып ялваруга карамастан, көткән яңгыр гына таммады да бугай. Күрәмсең, яңгыраш көнен дөресрәк чамалар өчен барометр булмаган. Корылыклар элегерәк тә, соңгы елларда да булгалады. Мәсәлән 1975 елны, ә барыннан да корырак җәй 2010 елда булды. Мин язганмын: 2010 ел, 17 январь-атмосфера басымы-779мм, температуры төнге-минус 31 градус; 2010 ел, 16 апрель-төньяктан күк күкери. Май аенда Тиләгәздә су кипте, 5-6 май-температура+31 градус, май, июнь, июль, август-64 көн-температура+30 градустан югары

булды. Яңгыр 21 августка кадәр таммады да, ә шулардан 15 көне температура+40-43 градуска җитте. Хәтәр корылык. Яровой ашлыклар кипте, бик начар булды терлек азыгы, малларга корма аз. Балыклының авыл суы Сыңар каеннан түбән акмады, авыл тирәсендәге байтак чишмәләре кипте. 2011 елны җәе дә көзе дә бик яңгырлы булса да, Тиләгəздә су булмады. 2012 елның кышында атмосфера басымы-783 мм, аяз, кар бик аз. Ә җәй, “яз булмыйча” килде. 2009 елда 31 март-1 апрельдә ташу ките. 2014 ел, җәй-Тиләгəздә су юк. Болар-кәгазгә теркәлгәннәре.

Ноябрь башларында җир туңу белән беренче кар яугач, көзге каз-үрдәк өмәләре уздырыла башлый. Каз суючы ирләр янында кызлар шаяртып суючыны көлдереп торалар, янәсе, йоны җиңел йолкынсын, ите тәмле булсын. Йолкынгач казларны, үрдәкләрне кызлар көянтәләргә тагып, төзелешеп су буена, казларны юарга чишмәләргә китәләр (чишмә суы кышны инеш суыннан җылырак диләр). Ә кичен каз ите салып пешергән аш, каз мае белән майланган каз коймагы, ашарга җыелалар. Табын уен-көлке белән бик матур итеп уза. Каз өмәләре казлы йортларда чиратлашып, йорттан-йортка күчеп тора иде һәм хәзер дә шулай, күпчелеге аракысыз уза. Дөрес, элегерәк кайчакта ачыбал, я Сеньковка-Майкадан, М.Ганькиннан табып китерелгән көмешкә-самогон белән кәефләнеп уза иде.

Безнең кушылган колхозда комсомолецлар сиксән кешедән артык иде. Мин алар арасында комсомол комитеты секретаре идем. Өстәвенә комсомол булмаган яшьләр дә байтак иде. Араларында бик актив, дәртле, сәләтле кыз-егетләр күп булды. Шулар белән үзешчән төркем оештырып, кыш көннәрендә трактор чанасына утырышып Карамал, Мәзгүт поселкаларына, Камышлы, Байтуган авылларына барып, төннәр буе концертлар, пьессалар куеп йөрүләр байтак булды. Музыкант, гармунчы булмаган очракта укытучы Мөкатдимә Вагазова дирижерлап та, матур, моңлы тавышы белән такмаклап та, җырлап та йөри иде. Пьессалар куйганда ул күбесенчә баш рольләр булган Галиябануны, Асыл-ярны, “Зәңгәр шәлдәге” Мәйсәрәне үзе уйнап, яхшы, матур, сәләтле итеп башкарды. Без инде икенче пландагы рольләрдә катнаштык. Ул чордагы яшьләр хезмәт алдынгылары иделәр. Матур ял итүләр, җыелышларда үзләренең проблемаларын күтәреп, киңәшеп, аларны хәл итү юлларын билгеләп, тормышка ашырып, җанлы, актив тормыш кичерәләр иде.




ПОСЕЛЕНИЕ БАЛЫКЛА
М.Р. КАМЫШЛИНСКИЙ






















Maxwell
Maxwell








АКСИОН





Сиксәненче елларда мин инде партоешма секретаре идем. Авыл Мәдәният йорты (СДК) директоры Фәния Ибраһим кызы Ганниева, урта мәктәп директоры Фәнүзә Исхак кызы Манжукова белән киңәшеп, урам-урам белән ярыштырып, бәйге концертлар чиратлап үткәрергә ниятләдек, һәм берничә ел дәвамында ул концертларны Фәния белән Фәнүзә югары сыйфатта оештырып, уздырып тордылар. Бик популярлашып киткәч, ул турыда район һәм өлкә гәҗитләрендә яза башладылар. Балыклыда мин хәтерләгән чорда больница (элгәре Урта кырда, аннары МТС конторасы булган бинада, хәтта бераз стационарда), сельпо, лесничество, почта бүлеге, радио һәм телефон үзәге, ветпункт, заготскот, тегермәннәр, пилорама, урта мәктәп, балалар бакчасы, мәдәният йорты, библиотека, пункт бытового обслуживания, колхоз, авыл советы һәм МТС эшләделәр. Сөйләүләр буенча, элегерәк авылда суны буып, аны җыебрак, су тегермәне дә ясап, эшләткәннәр. Бу турыда архив документларында да әйтелә. Кустарь-артель ачып, мунчаладан капта сукканнар. Авыл уртасында атлар көче белән эшли торган яргыч булган. Аның чокыры, нигезе әле хәзер дә исән. Тегермәнгә халык күбесенчә Поляйга, Камышлыга, Байтуганга йөределәр. Чиратыңны көтеп, Поляй тегермәнчесенең өендә зур мич башында ятарга да туры кильде, мич башы кызу, ә өе салкын. Бер период Похвистнево, Богырысланга сейка, он ясарга вальцовый тегермәнгә автомашина белән дә халык йөреде. Аннан, Х.Г.Нигъмәтуллин колхоз рәисе булгач, районда беренче булып Балыклыда вальцовый тегермән төзетте. Безнең авылда фәкыйрь, ялкау, я бәлки гаиләсе зур булып аты, башка маллары зыянлап, янгыннан йортсыз калып, бөлгенлеккә төшкән бахырлар булган. Алар әләм-сәләм киемнән, чикмәннән, чабатадан, капчык тагып, өй борынча хәер сорашып йөриләр иде, сугышка кадәр, сугыш вакытында һәм аннан соң да булгаладылар. Элек Пилюгино ягына барып (Богырысланнан ары) үзебездә ашлык өлгергәнче кайберәүләр боярга урак урганнар, күрәсең боярдан эш өчен Алдан алып ашаганнар. Дөрес, “бай” саналган Баһаветдин бабай Дәүтовның атлары, сыерлары, сарыклары күп булган. Әмма ишеткәннәрем буенча күп эшләп, эт кебек арып, вакыты белән аякларындагы чабаталарын да салмыйча, егылып йоклый булган. Аның каравы тамагы тук, өсте бөтен була. Шулай шул, хуҗалыкны алып

бару, көн-төн эшләүне таләп итә, күпчелек эш авылда кул көче белән башкарыла. Әле ул бүген дә "аягы" тупылдаса, авызың шапылдар!ң-диләр бит. Бездә таш келәтләр байтак иде. Күбесен гадәттә янгыннардан сакланып калыр өчен салганнар, тик аларның байтагы инде ишелеп бетте, цементсыз, балчык измәсе белән генә салынганнар. Безнең Балыклының ташы да тиз уалучан, бәлки шуңадыр ел саен өстеннән балчык белән сылап торсалар да, озакка чыдамадылар. Алда әйтелгәнчә, җылынырга теләгән кебек еш утырган салам башлы тораклар күбесе дүрт почмаклы, ишек аллы өйләр иде. Түрдә сәке, югарыда киштә, я сәндерә, такта өстәл, агач эскәмияләр. Сирәк кенә өйләрдә, бүкәннәргә чуен ватыклар каккан яргыч, ураза вакытларында талканлык бодай, борай (полба) бөртекләреннән шулардан ярма ясаганнар. Өстәлдә ялтырап торган җиз самовар, өстендәге чәйнеге белән. Кайберәүләрендә стенада көзге. Өстәлдә агачтан кырып ясаган зур коштабак, агач кәндиләр, агач кашыклар, тирәсендә берничә табуреткалар. Баеракларда янгында зыянланмаганнарда идәндә йон-киез палас иде. Сирәк кенә такта белән бүлгән бүлмә, караватлар янында читсы чаршау, югарыда тар түр чаршавы, стенада кызлар чиккән сөлге-дорожкалар тагылып тора. Пятистенный өйләр сирәгерәк иде. Өй башы калын итеп салам белән япкан була иде. Сирәк кенә, гадәттә урам саен, бер йортта сепарат булды, сөт аертырга. Анда хатын-кыз иртә дә кич тә, чират белән сөт аерталар, гөбедә май язалар. Сепарат хуҗасына гәрнич түләнә эш өчен. Өйдә аерым учаклы казан белән, татар миче утыра, почмак (кухня) диелгән урында. Ә пятистенный өйләрдә тагын "голландка" мич була иде. Андый өйдән татарда ике мөрҗә түбәдән тышка чыга иде, ә русларда голландкадан төтен труба белән рус миченә китереп тоташтырыла иде, бугай. Салкын кышларда читән абзарларда суык булганга, сыер бозаулагач, бозауны, бәрәннәрне мич арасына кертү бар иде. Өшеп, күшеккән тавыкларны да кертеп караватастына ябалар иде. Кунаклар дәшкән вакытта өстәлләр, урындыклар җитми булгандыр инде, түгәрәкләп идәнгә утырып ашау иде, билгеле инде аска палас булса да җәеп, ризыкларны-ашъяулык өстенә куеп. Әлегерәк төзелгән пятистенный өйләр, пристройкалары белән булса да, яңача проектлар белән төзелгән өйләрдән нык артта калдылар, бигерәк тә сугыштан соң төзелгән өйләр төрле яктан нык искерәләр, болай күләмнәре

зур булса да. Күп йортларның урам ягы элек киртә белән тотылган иде, багана я кушказык белән, күпчелегендә җил капка булды. Сирәк кенә урыс капкасы очырый иде, ике скатлы кыеклы. Йорттагы корылмалар: читәннән зур мал-кормы абзары, агач бурадан сарай, агач я таштан келәт, кар базы, кайберләрендә эчтән таш белән әйләндергән агач мунча. Ашарга, эчәргә суны чишмәләрдән алалар, ә малга я инештән, я кое суы бирелә. Ярты авылга 1976-1977 елларда Заря тавындагы артезиан скважинадан асбо-цемент трубалардан водопровод үткәрелде, дөрес хәзер асбоцемент трубаны бракка чыгаралар. Ә Кизләү чишмәсеннән самотечный сүүткәргеч 2005 елда эшләнде. Ипине күбесенчә арыш ипие, мичтә салдылар. Күмәч калаенда да, болай, себереп, мич төбендә дә. Аш безнең татарның күбесенчә токмачлы аш. Коры аш та, итле аш та була, ул инде хатын-кызның булдыклыгыннан, ә ир-атның пешерер өчен нинди чимал хәстәрләгәненннән дә килә. Тары боткасы уртасында аз гына чокыр ясап, май салып, кашык белән ботканы майга тидереп ашыйсың, я ялгышып майны үз ягыңа ерасың. Ашаганда катык та, әйрән дә кулланалар. Бәлеш, пәрәмәч, өчпочмак, кабартма, кайчакта аның өстенә бәрәңге ягып кыздыралар, кыстыбый, пилмәннәр, коймаклар, каклаган ит, казылыклар һ.б. безнең милли ризыклар авылыбызда кулланыла. Иркен яшәүчеләр дә, ә күберәк кысылыбырак яшәүчеләр дә авылда булган. Йорт саен сорашып, ашарга эзләп тә йөрегәннәр. Иң күпчелеге, майда суган кыздырып, умачлы я “браты”- чумарлы ашына катык катып ашаган. Төрле бәйрәмнәрдә кунакларга бавырсак пешерәләр. Бездә бакчалар гадәттә 0,30га. Анда бүлбе (бәрәңге) утыртыла, анысы җирне тиресләсәң, чүп үләнен яхшы утасаң, уңыш бирә. Бүлбене төрлечә пешерәләр, боткасын да ясыйлар, кыздыралар да, бәлешкә, пирогка салалар, пәрәмәч өстенә сылыйлар һ.б. Әмма, ул “алып баруын барырмын, тик алып кайтырга ышандыра алмыйм”-дигән ди. Су чыганаклары йортлардан, өйләрдән ерак булу сәбәпле, Балыклыда элегерәк яшелчә үстерү аз булган, бигерәк тә кәбестәне. Ә хәзер үстерәләр.

# Топонимика

Безнең Балыклының топонимикасына килгәндә Заря тавыннан башласак, аның исемен кояш чыгышын күзәтүче кешеләр кушкан булырга тиеш (әгәр Заря, Зәрә сүзе татарча бүтән мәгънәне аңлатмаса) алар латышлар очында яшәүчеләргә турырак килә. Мукшы, латыш телләрендә таң ату ничек атала торгандыр, ә менә мишәрләр аны исемләргә бик мөмкин. Хәер мишәрләрдә дә элеккеге кыпчак (половцы), мукшы я буртас, бераз болгар теле дә катнашкан диләр бит. Ә бәлки бүтәнчәдер? Без бит әле үзебезнең татар телебезне дә яхшы белмибез. Акбур тавының исеме үк әйтеп тора, аның ташын (известняк) казып, ломнар белән каергалап алып, яндырып һәм он хәленә тикле төеп, суда изеп, тиешле урыннарны акбурлыйлар иде. Бу известь биредә миллион еллар элек диңгез төбе иде, дип әйтеп тора. Моңа тагын бер дәлил: сыңар каен янындагы таш карьерыннан бер 20 см. зурлыкта, нык ташка ябышкан, ачык-аның күренеп тора торган балык скелеты да чыккан иде. Безнең инештәге "Кызыл канат"-пескарь, анда диситләм метр үргә таба менә алмый. Мөти тавы (кызыл яр яны) әллә ни белән аерылмаса да, анда 1949 елда беренче нефть эзләүчеләр агач вышка куеп бик озак бораулладылар. Франко, Студебккер дигән трофей машиналар, авыл аша тузан туздырып, йөреп тордылар. Тик уңай нәтиҗәгә ирешә алмадылар бугай, ничә метр тирәнлектәдер, бик көчле җир асты су агымына юлыгып, шуннан тирән бораулый алмадылар ахры, трубасын томалап киттеләр. Аны томалаганчы, труба башына колакны куеп тыңлаганда, шул су агымның гөжләп акканы ачык ишетелеп тора иде. Әсәкәй тавы-анда әсәкәй (суер) ташлары булганга шулай аталгандыр (ташлар бик күп булмаса да). Бер почмагыннан, көньягыннан "Изгеләр чишмәсе" агып чыга, тау башыннан диярлек, арырак дөрес тау биегерәк. Тагын Мирәй, Йөрәк, Күмәч һәм башка исемле таулар бар. Мәсәлән Тиләгәзне салкын чишмә янынннан чыгып башланган үр, тау Мотаука дип атала, нәрсә аңлатканы билгесез. Елгалардан Шарлама турында бераз язылган иде инде. Ул Кисенде һәм Әдекәй урманнары арасындагы сазлырак урыннан башланып ага, шар, шарлы дигән сүзнең Ңсазлыкң дигәнлеген ачыклаган идек. Ә Тиләгәз турында төгәл белмим,

дисәм дә ярый. Иске Ярмәк кешесе Фәрит Сабитов Тиләгәз елгасын “Тилегазый” түгелме икән, ди. Ә бәлки, яз тилереп ташып ага “тиле яз” түгелме икән? Бу якларда бит әле башкортлар йөрегән, яшәп тә алганнар. П.И.Рычков “Оренбургские степи” дигән китабында Урал буе Юштырка, Салмыш елгалары янында “Тельгазы” елгасы барын яза. Безнең “Тиләгәз” ярмәкләрнң “Тилегазый” сына бик ошаган. Белмәссең, бәлки башкортлар үз елгаларына ошатып, шулай кушып киткәннәрдер. Мукшылар, латыш, чуваш телләрендә ул исем ничек яңгырый, нәрсә аңлаталар, башкортча “Тельгазы” да, әлегә билгесез. Бездән, водоразделдан, урман эченнән Кинәле елгасына таба ага торган кечерәк “Тәрәгәл” елгасы бар, чувашлар аны “Тергала” дип йөретәләр. Мүкле күл ягыннан Ална елгасы (инеш) агып чыга, ул да суларын Кинәле елгасына коя. Ул якта бар да урман эченнән агып чыккан чишмәләр, елгачыклар. Ст.Выселки, Осоргино, Поникла, Чугуновка чишмәләре дә, сулары да мул. Осоргинодагы чишмәне (суы мул, яхшы) Шахов чишмәсе дияләр.

Элек, украиннар килгәнче, тирә-як тоташ урманнар булган. Бу турыда елга буендагы чокырлардагы агачлар бүген дә “без тоташ урман эчендә идек”, дип кычкырып торалар күк. Тик боларын кисеп алалмаганнар, чөнки чокырдагы җир кирәкмәгән. Балыклының көньягындагы Ике урман арасы (Нәрә юллары) безне, делянка ясап, Олы урманнан Чокыр бүләкне аердылар, диләр. Чокыр бүләк, Чиялек, Янган имәнлек, Заготскот урманы белән Әмир бүләге, Гәрәй урманы, Моторин, Талкыш, Тәрәгәл, Мотаука өстендәге имәнлек зур түгел, Алиша чокыры-елгасы буйлап сирәк кенә каенлык бар. Байтуган урманына таба “Кырык имәнлек”, дөрес хәзер анда күбрәк каеннар гына үсә. Авыл халкы аннан каеннарын кисеп, тузын каезлап алып, дегет базында май белән кайнатып, дегет ясаганнар, арба күчәрләрен майларга, шулай ук маллар җәрәхәтенә сөртеп, дәвалар өчен “ару дегет тә” ясап, кулланганнар. Тагын Зур Каршы Урман, кече Каршы урманнар бар. Шушы урманнарның баклары халыкныкы (общинный) булган, соңырак-колхозныкы, хәзер дә 230га колхозныкы санала, ә калганнары-казеный, хөкемәтнеке, хәер аларны арендага биргәннәрме, сатканнармы, дигән сүзләр йөри. Заря тавы артында, Мөти тавы белән ике арада шулай ук урман булган. Анда хәзер дә кипкән имән төпләре бар, череп

бетмәгәннәр, ә үсүче агачларны якында булгач кискәннәр, вак үсентеләрен маллар ашап бетергән, ныгып китәргә бирмәгәннәр. Ачыда, Шарлама башында, Сазда байтак агачлар үскән, тик шулай ук якын булганга кискәннәр, мал да ашаган. Менә хәзер, колхозлар таралып беткәндә, көчсезләнгәч, техника искергәч, ягулык алырга акча юклыктан җирләр рәтләп сөрелми, шуңа анда яңадан агачлар үсә башлады.

Безнең урманнарда пошый, кыр кәҗәсе (косуля), төлке, куян, селәүсен (рысь, үзем күргәнем юк, дөрес), ондатра, кондызлар яшиләр. Сирәк кенә бүреләр дә килеп чыккалый, ә элегерәк алар күп иде. Миңа үземә дә, Кисенде артында ике тапкыр бүре очырады, тик “мирно” гына үз юлыбыздан китеп бардык, әмма бүре белән якыннан очырашу куанычлы вакыйга түгел. Алар элек төннәрдә авылга килеп этләрне, сарыкларны алып китктәләделәр, көтүләргә өерләре белән һөҗүм итеп, сарыкларны дистәләп буганнары булды. Тауларда йомыраннар, сыркалар колониясе күп. Җитмешенче елларда бездән, сыркаларны тотып, башка районнарга да, үрчетер өчендер җибәргәләделәр. Басу юлыннан төнлә барганда, машина уты яктысында җир куяны, кушаяк (тушканчик) күренгәли, кечкенә кенгуру кебек сикерә.

Кошларның да байтак төрләре бар. Мин орнитолог түгел, үзебезчә атап йөрегән каргалар(карасы да, аласы да), чыпчык, песнәк, сыерчык, чәүкә, саескан, күгәрчен, козгын, суер, көртлек, тургай, былбыл, бытбылдык, тартар, кыр тавыгы, кыр үрдәге, челән һәм ябалаклар, элегерәк мәчет-клуб исән чакта, аның астында ярканатлар күп иде, хәзер юклар.

Күлләребез күп түгел. Иң зурысы-Мүкле күл, хәзер бездә Моховой гына дип йөриләр. Мәйданы бер ун гектарлап бар, бигерәк тә яз, кыш кар күп яуган елларда киң җәелә. Аның тирәсе зур, тоташ урманнар булган. 1903-1913 елларда Ст.Выселкига халык утыра башлагач, урманнарны кисеп, төпләгәннәр, чәчүлекләр ясар өчен. Алар безнең Балыклы халкына агачны “бушка” биргәннәр, тик агач алучы аны тамыры белән алу шарты белән. Самара-Мансур, Балыклы-Мүкле күл-Байтуган-Сок Карамалы-Бөгелмә маршруты белән “Караклар юлы”, “Воровская дорога” булган. Мүкле күлнең тирә-ягыннан бик күп урманнарны кискәч, күлнең суы кими, саега һәм аннан бик күп кеше сөякләре килеп чыга. Чөнки, Байтуган урманында юлбасарлар яшеренеп, үз корбаннарын, юлаучыларны көтеп

торганнар, юлларын кисеп, аларны талаганнар, атын байлыгын алып, үзләрен үтереп, күлгә ыргыта булганнар. Зима-горе-Зимагорлар. Торна күле диелгән урын бик бәләкәй, бик явымлы елларда гына чокыры тулып, агып чыга. Поляй юлы башында зур күл дигән чокыр (минемчә карстовый булырга кирәк) кар сулары белән генә кайбер елны тула яза, ә җәй көне кибеп бетә. Анда кара әрем генә үсә. Кызыл ярдагы күл-чокыр, җир уртасында, анда да кар сулары гына җыела. Бездә чишмәләр байтак. Сүүткәргеч уздырганчы аларны буралап, яхшы чистартып торалар иде. Хәзер оныта башладык ахырысы. Ә бит чистартмасак...? Үз вакытында, XIX гасырда булырга кирәк, Кизләү чишмәсенең суын, урам уртасыннан ерганак казып, төшергән булганнар, ул Таллы урамы буйлап агып тора, чишмә өстендәге бурасын, тузган саен алыштырып торалар. Элегерәк тирә-ягында кечерәк кенә сазлык иде, хәзер зурайганнан зурая бара. Әллә чишмәсен чистартабыз, яхшыртабыз дип, боздык микән? Ә Г.Кәнзел бер елны трактор ковшы белән вак таш та салган... 2005 елда Кизләүдән суны труба белән урамга төшерделәр. Бу эшне оештыручы-волость җитәкчесе Шәрәфетдинов Раил иде. Икенче агымсуны җитмешенче еллар башында, мин һәм Галимов Әхәт абый, колхоз идәрәсе, авыл советы җитәкчеләренең киңәше белән, Себер урамына арык ясап, Ачыдан су үткәрергә алындык. Алдан мин вешкалар каккалап, ерганакның юнәлешен турылап, билгеләп чыктым. Әхәт абый грейдер белән ярып, кат-кат узып, ерганак ясап, Ачы суын Себер урамына төшердек. Су болай матур гына агып тора. Тик язгы ташу сулары киткәч, арык башыннан юлын төзәткәләп, суны юллап, җибәрергә кирәк. Рәшит, Әхәт бабайлар, яшерәк чакта мине эшләделәр дип, чылтырый. Кайбер иренмәгән иптәшләр тирәсенә агачлар да утырттылар. Чишмәләрнең исемнәрен каян килеп чыккан дисәң, Кизләү-бәреп чыга торган чишмә, күзләр, күзләү сүзе. Тагын “Тымай” чишмәсе, авыл суы, инеш Балыклинка (Балыклы су) белән Җәмилә елгасы-чокыры кушылган җиргә таба суы яхшы, ә исемен, бәлки монда күчеп килүчеләр кушканнардыр, бәлки тымызык, талгын ага мәгънәсенә ишарәдер. Су агымы буйлап югарырак, “Минехәер чишмәсе”, Сагдеев Минехәер бабайның бакча башы шул чишмә ярына терәлгән иде, шуннан чишмәгә кырын сукмак төшә иде, ул бабай чишмәне даим карап чистартып торды, кышын кардан,

боздан арчый иде. Йорты Себер очына чыга торган юл читендә, тауда иде. Хәер, ул чишмәнең башка исеме, “Олы чишмә”, чөнки элек Олы урамда һәм Безводовкада яшәүчеләр күпчелек шул чишмәдән су алалар иде. тагын да югарырак “Чылтыр чишмә бар”. Таулы яр (Урта кыр) ягыннан авыл ягына труба белән агып тора. Шарламада чишмә, Кысырык урам башында-Дауд чишмәсе, суы яхшы, мул. Ә кайсы Дауд Давид исеме белән әйтелеп калгандыр-белмибез. Тагын сазда Ч Д чишмәсе, Кисмук, Вагаҗ, урманда Саный һәм башка чишмәләр бар. Балыклы Су буйлап Тиләгәзгә җиткәндә “Салкын чишмә” бар. Ул 1950 елларда әзерәк өстәрәк иде, ә аннары бераз аскарак күчкән, суы яхшы, мул да. Әсәкәй тавыннан “Изгеләр чишмәсе” ага. Шарлама елгасы башында да, Тиләгәзнең югары ягында да чишмәләр бар. Бу сулар турында сөйләгәндә, безнең Балыклы суын “тавык та атлап чыга” дигән әйтеп бар. Ә шулай да, узган гасырның җитмешенче елларында колхозның йөз егермедән артык сарыгы шунда батып үлде. Ферма сарыклары белән авыл халкының көтүе, ни сәбәптер, бергә кушыла. Көтү каршылаучы халык, хатын кыз, бала-чага артларыннан кычкыра-кычкыра меңләп башны авылга таба куалар, күпер әле юк иде, маллар елга аша чыкканда, паникада, лайлы, баткак урында бер-берсе өстенә менеп, өелеп тапталып үләләр. Судлашып беттек. Менә сиңа “тавык та атлап чыга”!

# Гражданнар сугышының һәм ачлык елларының авылга кагылышы



Инкыйлаб, гражданнар сугышы, ачлык Балыклы авылы халкының тормышында да эзсез узмаган. Чөнки, гражданнар сугышы елларында безнең якларда чуалышлар шактый катлаулы булган, диләр. Ник дисәң, бер якта Богырыслан тимер юлы стансасы, икенче якта, ерак түгел-Кләүле-Бөгелмә тимер юлы, ул елларда төп транспорт челтәрләре. Без бала чакта, тыныч төннәрдә, паравозның гудок тавышлары безгә, Балыклыга, чаклы ишетелә иде.

Вахитова Мәрьям, Вахитов Мөхәммәтвәли Закир кызы һәм улы сөйләүләре буенча, 1919 елның язында аларның өендә "кызылларның" штабы булган. Күрәсең, өй зур, иркен була. Бер төндә, тык-тык, чык-чык иткән тавышка уянып карасалар, өйдә бер солдат та калмаган. Отряд тиз-тиз авылдан ындырлар ягына, Богырыслан юлы ягына чыгып киткән. Ә өйдәге хатын-кызлар "кара әле, чыпчыклар да ничек борчылып чыркылдый",-диюгә, Закир бабай, "бу нинди чыпчыклар булсын, пулемет тавышы бу!"-дип, өйдәгеләрне барысын да тышка, кар базына төшергән. (Ул сугыштан, ахры, яраланып кайткан булган). Бу ыгы-зыгы, атыштан авыл башында, ындырлар янында 12 кеше ятып кала. Араларында аклар да, кызыллар да булган. Икенче көнне, шунда ук күмәк зират казып, аларны күмгәннәр. Зират тирәсе читән белән тоткан иде. Ул урын хәзерге кирпеч мәктәптән әзерәк читтәрәк иде. Бу атышларда авыл кешеләре арасында үлүче дә, яраланучы да булмаган сымак, билгесез. Атышлар бик көчле булган, чөнки без, малайлар авыл башында мылтык гильзалары табып, алар белән уйнап йөри идек, әле хәзер дә, юк-юк та гильзалар, пулялар очрый.

Аклар Байтуган ягыннан (юлыннан) килгәннәр. Мылтыклар, кылычлар, озын сөңгеләр белән коралланган булалар. Бер

шиксез, пулеметлар да булган. Сөңгеләрен йортка, коймага сөяп куялар иде, дип сөйләделәр.

Бер көнне шундый хәл булып ала. Багаутдин бабайлар янындагы мәчет каршында, Сәлимҗан абзый, шулай булгач, әниләрнең дә туганы (Гәззә әби ягыннан), тик тормаган теле белән: "Боларны җуярга кирәк", дип, халыкны котырта башлаган. Ә аклар арасында татарча белүче башкортлар да була. Шунда бу агайның эченә штык белән кадыйлар да, йортка кертеп ташлыйлар һәм ул шунда үлә.

Ә ике яшь егетне "шпион" дип, Шарламада, Даут күпереннән өстәрәк атып үтерәләр. Сөйләүләрчә, алар татар булганнар, ахыры кызыллар белән бәйләнешләре булган. Закир бабайны да аклар, аты-арбасы белән, яраланган солдатларын салып, обозлар белән алып китәләр. Алар белән бабай Богырысланда, Заглядиндә, ахыры Бозаулыкта да йөргән. Аннары атын сбруйлары белән калдырып, кайтып (качып) китә һәм өч айдан соң гына өенә кайта. Ә аты, йөгәненең тезгеннәрен өзеп, алты айдан, көз көне өйләренә кайткан, дип сөйләделәр.

Менә бу язганнарны куәтләп, Камышлы районы архивыннан алган "Об истории Камышлинского района за 1533-1960 годы" дигән таныклыкта язылган. "...В селе Балыкла кулаки напали на небольшой отряд-40 человек красногвардейцев, пытаясь обезоружить, которые тоже отступали на Запад, остановились в селе на отдых. Но отряд открыл стрельбу, разогнал толпу нападающих, при этом застрелили 4-х человек. Были бои и в 1919 году в марте. Когда Красная Армия отступала в селе Татарский Байтуган произошла перестрелка, белые находились в селе Русский Байтуган. Когда белые начали отступать, в мае были бои в селе Балыкла и в других селах. В Балыкле видимо было очень жарко. Белым офицерам, прибежавшим в Камышлу без погонов, они посрывали, тут снова стали пришивать погоны себе. Когда районные села заняли белоколчаковцы, как вороны стали слетаться домой бежавшие купцы, кулаки и помещики. Но им недолго суждено теперь топтать земли района". Бу язма таныклыкны кем язганы билгесез. Гражданнар сугышында һәләк булган солдатлар зираты өстендәге торкан читән-частокол тузып, юкка чыккан. Хәзер, Совет властеның 50 еллыкларын билгеләгән чорда, гражданнар сугышында корбан булган красно-белогвардеецларга, искә алыр өчен, рәхмәтле 22 нче Партсъезд

“Правда” колхозы, Куйбышевтагы Масленников заводыннан булган шефлар ярдәме белән, аларга һәйкәл куйдылар. Тагын әле Алишада Батырга һәйкәл бар.

Билгеле булганча, Совет власте хакимиятлеккә килгәч, илдә башта продразверстка, аннан Н.Э.П. хөкем сөрә. Шуларның да шаукымыдыр, каты корылык аркасында игеннәр янып-көеп уңышлар булмаудан да, Идел буе ареалында куркыныч ачлык барлыкка килә.

1921 нче елгы ачлык авылыбызда да күп кенә кешеләр башына җитә. Авыл кешеләре арасында да, чит авыллардан килеп хәер сорашып йөрүчеләр дә (хәзергечә-бомжлар) ачтан күп үләләр. Үлекләрне зират янындагы бер читән абзарга җыеп, кучалап күмгәннәр.

Яз җиткәч, ач халык сырка, йомран тотып, балтырган, кычыткан, карга һәм башка тапкан кош йомыркаларын ашап, тамак туйдырганнар. Ахыры, әле яз җиткәч юкә агачы бөресен, чөгендер яфраклары, төплекәйләр ашаганнарын сөйлиләр иде әбиләр, әниләр.

Шушы ачлык елда, Кысырык урамындагы зур таш келәттә) ул Даут бабайныкы булган) ашханә ясап, Америка биргән кукурузадан ризык әзерләп, халыкны ашатканнар, дияләр иде. Сахибкамал апа-әби сөйләвенчә, аларның күршеләрендә кеше үлә. Туганнары аны бакча ызанына кабер казып, өч көн буена Кротково чокырына таба күмгәннәр. Ач халык зиратка бик барасы килмәгәндер, яисә бара да алмаган.

Безнең Балыклының ике егете хәер сорашып Седяковода йөриләр. Йөри торгач попка да керәләр. Поп хәерне бирә дә, әгәр чукынсагыз, мин сезгә ашарга күбрәк тә бирәм, ди. Болар, ачтан үлгәнче дип, чукыналар. Тик бу егетләрнең чукынуы, озакламый авылда билгеле була. Поп биргән ризык озакка җитми, егетләр ачтан үләләр. Авылдашлары, болар хәзер мөселман түгел дип, зираттан читтәрәк, Заря тавы итәгенәрәк, күмәләр. Кемнәрдер алар өстенә каен агачы утырткан булган, мин белгәндә ул агач бик картайган иде, хәзер инде ул юк.

# Колхоз



“Путь Ленина” колхозы. 1958 ел.

Һәр узган эшнең, әгәр борылып карасаң, үзенә күрә бәләкәй генә тарих башы була. Без дә бераз артка борылып карыйк әле. Авыл хуҗалыгы 1921 нче елгы ачлыктан соң, акрын гына “аякка” баса башлый. Егерменче еллар социализмга нигез салу, Ленин васыятьләрен үтәп, күмәк хуҗалыкка бару чоры була. Бу мәсьәләне Р.К.П.(б)ның 1927 нче елның декабрендә үткән съездында авылда күмәк хуҗалык (коллективизация) ясарга, аларны техника белән коралландырырга, дип карар чыгара. Чөнки, 1926-1927 нче елларда да 8 млн.гектар җир сука белән сөрелә торган була. Ә ашлыкларны урып-җыюның 3/4 өлеше урак, чалгы белән урылган һәм күбесе цибагач белән сугылган. Бездә цепь урынына озын таяк башында каеш белән ныгытылган палка иде. Йөз йортка 3,3 сабан, 0,3 веялка һәм 0,03 молотилка була. Шушындый вакытта җитештерү мөнәсәбәтләрен үзгәртү, кулакларны бетерү бурычы тора. Совет хөкүмәте артель белән эшләүне беренче мөһим бурыч итеп куя.

1929 нчы елда безнең Балыклыда да авыл хуҗалыгы артеле оештыру эше кузгала. Бу эшне бигрәк тә комсомоллар җанландырып җибәрә, чөнки коммунистлар авылда әле юк диярлек була. Башта колхозга 14 хуҗалык, иң ярлы, кайсыларына нинди тормышта да югалтыр малы булмый, шулар керәләр. Артельгә “Кызыл көрәшче”, дип исем бирәләр. Менә ул безнең



*"Кызыл крәшче" колхозы.*
*Язгы чәчү тәмамлануга бәйрәм итү. 1953 ел.*

беренче колхозчыларның исемлеге: Галимов Мөдәрис, Мәҗитов Гариф, Ахметшин Мәрданша, Якупов Исмәгил, Зиятдинов Газетдин, Аскаров Ахмадулла, Каримов Вәли, Билалов Сахаб, Музафаров Садри, Валиев Абдулхак, Хәбибуллин Юсуп, Валиахметов Салим, Галиуллин Насиб, Ганниев Нәсибулла.

Бу күмәк хуҗалыкның беренче оештыручылары: Галимов Мөдәрис, Хәбибуллин Юсуп, Ахметшин Мәрданша, Музафаров Садри һәм Мәҗитов Гариф булалар. Артельнең (колхозның) беренче рәисе - "25 меңче" Мухтаров Сабир була. Аерым хуҗалыклар, идин чакта алдан яхшы әзерләгән җирләрдә беренче күмәк хезмәтнең нәтиҗәсе-ашлыкларның уңышы яхшы була. Артельнең һәр әгъзасы үзенең гаиләсендәге һәр кешегә 14 әр пот (1 пот-16 кг) ашлык ала. Ә инде 1930-1931 нче елларда артельгә (колхозга) бик күп хуҗалыклар керәләр.

Председатель әле һаман шул "25 меңче" Мухтаров Сабир була. Тора-бара безнең колхозда председательләр бик күп булалар. Менә аларның исемлекләре: Мухтаров Сабир-1929 нчы елдан, Ахметгалиев Хусаин, Мусин Фатих, Хасаншин, Аксенов, Абдулов Нәгим, Ахметов Газиз, Хамидуллин Хамидулла, Вахитов Вәли, Ширшов Василий Тимофеевич, Сиразов Гаттар, Сагдеев Нигмат, Нигматуллин Шарифҗан-30-ти тысячник, Абсаттаров Вәли, Вәлиев Хәбиб, Билалов Кыям, Шамсутдинов Шәйхетдин, Ягудин Закир, Шарапов Нагим, Вешкин А.М., Ахметшин Мәрданша, Кутузов Сагит, Нигматуллин Хабиб Г., Каюмов Минахтәм, Сагиров Минахсан, Фардеев Рәшит, Нигматуллин Рафаэль.

Председательләрдән Шамсутдинов Нәдер 1952 нче елда Вахитов Вәли Куйбышевта бер ел курсларда укыганда, аның урынына эшләде.

Совет хөкүмәте һәрвакыт колхозларны яклап чыга, аларга ярдәм күрсәтеп, беренче булып тракторлар җибәрә. Бигрәк тә, 1931 нче елны Балыклы МТСы ачылгач, безнең колхозда да тракторлар эшли башлый. Ә колхоз МТСка техника эшләгән өчен натуроплата түләргә тиеш була. “Кызыл көрәшче” колхозында беренче трактористлар - Хәбибуллин Юсуп, Аскаров Әхмәдулла, Ганиев Нәсиб. Беренче комбайнерлар-Сабуров Миргабиҗан, Шамсутдинов Риза.

1935 нче елны колхоз мул уңыш ала. Ашлыкны хөкүмәткә тапшыру, ташу өчен “Кызыл обозлар” оештырыла. 1937-1938 нче елларда колхозчыларга хезмәт хакын, трудодниларга ашлыкны йортларга илтеп бушаталар. Бу артельдә, эшне алып бару өчен 7 кырчылык бригадасы оештырыла. Һәр бригаданың үз җире, атлары, инвентарьләре була. Соңрак, аларны берләштереп, 4 бригад калып, озак еллар эшләделәр. Артельдә эшләр җайланып китә, чөнки артельгә кергәндә, һәр хуҗалык гариза язып, үз аты, арбасы, сбруйлар белән кергән. Мин әле Кәфия әбиебезнең сөйләгәннәрен хәтерлим: Мин бригадка атыбызга өйдән кормы алып барып ашата идем. Син аның янына барсаң, ул иреннәрен медер-медер китереп сине каршы ала! Бригадта чит кешеләр атны җиккәндә, нәрсә, Кәфиянеме җигәбезме?, дип әйтәләр, кәферләр!, дип әйткәне бар иде әбинең!

Коллективизация Балыклыда да бик тыныч кына бармаган. Уңганлыгы, эшчәнлеге аркасында яхшырак, хәллерәк яшәүче кешеләрне бер гаепләре булмаса да, раскулачивать иткәннәр. Менә бер мисал:

*Справка*

*Председателю суда п.Усолье Сибирское Иркутской области*
*от гражданки Фатхутдиновой Сара Миназовны 1916*
*г.рождения, проживающей в с.Балыкла, Самарской области.*

**Заявление.**

Я проживаю в селе Балыкла со дня рождения, знаю семью Даутова Кашафа Даутовича с раннего детства. Знаю, что семья имела большое хозяйство (строения, землю, технику и инвентарь для обработки, скот, птицу и т.д.) и была раскулачена и выслана в Иркутскую область в 1931 г.

На день высылки семья имела состав:
Даутов Кашаф Д.-1888 г.р.-Глава семьи.
Даутова Гайша-1898г.р.-жена.
Сын-Даутов Сахаб К.-1910 г.р.
Дочь-Даутова Асма К.-1912 г.р.
Дочь- ДаутоваСазидя К.-1921 г.р.
Дочь-Даутова Гаиля К.
Сын-Даутов Минахтям.
Сын-Даутов Гильмутдин.
Сын-Даутов Минаксан.

При раскулачивании все имущество было изъято, в чем расписываюсь.

**1.11.1999г. подпись: Сара.**
**Подпись Вахитов Р.В.**
**Гербовая печать. Рег.№08.**

Раскулачиваниелар Балыклыда байтак була. Бөтен беренче материал башлап үзебезнең Балыклы авыл советыннан бирелгән. Менә белгәннәрнең исемлекләрен тагын китерик: Хисматов Гайзулла Нигматович-1887 г.р. Соңыннан колхозда яхшы эшләп "Заслуженный колхозник" дигән исем яулады.

Ганниев Султан-1894 г.р.
Ганниева Гельмениса-1898 г.р.
Шайдуллин Шафик-1887 г.р.
Шайдуллина Минниса-1892 г.р.
Шайдуллин Мухаметвали-1912 г.р.
Шайдуллина Марьям-1914 г.р.
Ангалышева Ханифә
Рафикова (Вахитова) Фатыйма-1920 г.р.
Фархутдинова Наилә
Фархутдинова Зәйтүнә
Ганниев Зиннур
Коняева
Ангалышев Абдулбар-Карамалдан.

Раскулачиваниеләрдән, дөресрәге авыл халкының атын, сыерын, булган техникасын, абзарларына чаклы талаудан җыелган милекне "Кызыл көрәшче" колхозы файдасына алалар. Тик талап, елатып, каргалып алынган әйбер, милек яхшыга илтми. Баштагы елларда эшнең нәтиҗәсе төрлечә

була. Мәсәлән, 1933 нче елны 1928 нче ел белән чагыштырганда, 1/3 гә кими, ашлык уңышы 7-8 центнердан артмый. Олырак буын авылдашлар хәтерлидер, ничек бригадирлар көн саен иртүк йорт саен йөреп, колхозчыларны йә ишектән, йә тәрәзә аша эшкә чакырып йөрегәннәрен...Һәр колхозчы елына мәҗбүри рәвештә, фәлән кадәр трудодни эшләргә тиеш була. Аны колхоз идарәсе үзе билгеләп куя. Әгәр үтәмәсәң, төрле җәза каралган иде, йә тунеядец дип хөкемгә тарту, минимумың тулмаса ул ел пенсиягә чыкканда исәпләнми иде. Ни генә булмасын, күмәк хуҗалыкта шәхси иясе булмаган техниканы һәм малларны саклау, күп вакытта, тиешле дәрәҗәдә булмады, йөзләгән баш бозаулар, дуңгызлар үлде, башка югалтулар да байтак булды. Урлау, эчүчелек алдарак йөреде. Барыбер, җитешсезлекләр булса да, күпчелек Балыклы халкы тырыш иде. Авылда матур гына өйләр салып керә башладылар, сугыштан соң исән кайткан ирләр һәм үсеп килүче яшьләр. Фермаларда коровниклар (шестирядка с фонарем) салдылар. Беренче мәртәбә безнең авылда дуңгыз фермасы ясадылар.

Совхозларда торак йортлар да, башка биналар, каралтылар да хөкүмәт акчасына эшләнделәр, ә колхозларда башкача, колхозы да, колхозчысы да бөтен тормышын үз көче белән алып барды, дип була.

1950 нче елны колхоз председателе булып Балыклы МТСында механизатор-комбайнер булып эшләгән Вахитов Вәли Закир улы сайланды. Сугыштан соңгы бик авыр еллар. Техника җитәрлек булмау сәбәпле, күп кырчылык эшләрендә ат һәм кул көче кулланыла иде әле. Колхозда автомашиналардан фәкать бер, сугышта булып кайткан “полуторка” бар иде. Шулай да, берничә ел эчендә колхоз эш күрсәткечләре белән Камышлы районында беренчелекне яулый. Шуның өчен колхозга “поощрение” рәвешендә җиңел машина “Победа” бирелә. Ә председатель В.З.Вахитов Лениногорск шәһәрендәге нефтьчеләр белән килешеп, “Победа”сын электростанциягә алмаштыра. Үзе киредән ат белән тарантаста йөри башлый. Электростанцияне ферма янында махсус бина корып, көйләп җибәргәч, урамнар буйлап имән баганалар утыртып, токуздырып, авылда электр лампочкалары яна башлады, югыйсә МТС та гына бар иде. Вахитов В.З. байтак еллар, 10 ел дәверендә, шул вазыйфасын

уңышлы башкарып, колхозларны кушып, берләштерә башлаганчы эшләде. Тырыш һәм яхшы нәтиҗәле хезмәте өчен хөкүмәт тарафыннан “Хезмәт Кызыл байрагы”ордены белән бүләкләнде.

1953 нче елдан колхозларда хезмәт хакы түләү бераз артты. Бигрәк тә механизаторларга үсте, гарантияләп.

Колхозда сыер, сарык, дуңгыз, тавык фермалары, атлар конюшняләре булдырылдылар. Иске манарасын кискән мәчет-клуб янәшәсендә 1958 нче елны гипсоблоктан яңа клуб-СДК төзи башладылар.

1958 нче елда МТСлар беткәч, “Кызыл көрәшче” колхозына 7 трактор, 4 комбайн бирелә. Чәчү мәйданнары 1958 нче елда 2400 гектар тәшкил итә, аннан соң, алтмышынчы еллар азагында, заготскотка бирелгән җиребез, совхоз “Рассвет”тан яңадан безгә кайтты. Анда сөрелә торган җирләр генә 150 гектардан артык иде.

1959 нчы елда “Кызыл көрәшче” колхозына “Заря” колхозын (п. Михайловка, п.Пугачевка, дер.Степановка) һәм “Путь Ленина” колхозын (д.Конновка, п. Мазгут) кушып, берләшкән колхозны “Путь Ленина” дип исемләделәр. (Председатель-Ширшов Василий Тимофеевич).

1961 нче елның сентябрендә колхозны икегә бүлделәр. Берсе имени XXII Партсъезда (с.Балыкла, председатель-Ахметшин Мәрданша), ә икенчесе “Заря” (п.Михайловка, п. Пугачевка, д.Степановка, д.Конновка, п.Мазгут).

Мин белгән чорда бөртекле ашлыклардан иң югары уңыш колхозда 1968 нче елда гектардан уртача 23.3 центнер алдык, (пар кырлары булмаса да). Кайбер кырлар 42 шәр центнер уңыш бирделәр. Бу вакытта колхоз председателе Х.Г.Нигматуллин, ә мин агроном идек. Шул ук 1968 нче елгы уңыштан колхоз хөкүмәткә икмәк сату планын өчләтә үтәп, хуҗалык буенча рентабельность-121,5 процент тәшкил итә. Билгеле, безгә ул елны “небесная канцелярия” дә ярдәм итте, вакытында яңгырлар явып торды.

1969 нчы елда ук, язгы якта, Балыклы халкы авылда колхоз оештырылуының 40 еллыгын билгеләп, Каршы урманда бик зурлап бәйрәм иттеләр. Өлкәдән, Куйбышевтан телевидение, Масленников заводыннан шефлар, район җитәкчеләре килеп катнаштылар.

ХХП нче Партсъезд колхозы 1970 нче елның башына кадәр генә шул исемдә яшәде, ә 7 нче февральдә ул Шевченко колхозы (Ст.Выселки, п.Поникла) белән кушылды һәм “Правда” исемен йөретә башлады. Ә Осоргино, Чугуновкалар инде таралып беткән иде.

Яңа кушылган колхозның җире 8885 гектар, авылхуҗалыгы җирләре-8334 га, сөрелә торган җирләр җирләр-5853 га, көтүлекләр-2406 га. Эре мөгезле маллар-955 баш, шулардан сыерлар-323 баш, дуңгызлар-1108 баш, сарыклар-2252 баш.

Кабат берләшкән колхозның председателе итеп Х.Г.Нигматуллин сайланды. Ә мин баш агроном булып калдым. Төрле вакытта минем белән агрономнар булып Калиновский, Салахов М.Н., Хамзин Р.М., Сафиуллин Н.Н., Гайнутдинов Фәһим эшләделәр.

Бу елларда колхозларны материаль-техник яктан тәэмин итү уңышлы барды дип була. Дөрес, запчастьләр җитми, ремонтлар начар дип, зарлана идек. Ә шулай да, зерновой комбайннарны күпме теләсәң, шул кадәр алырга мөмкин иде, әле аны китереп тә бирә иделәр. Мәсәлән, 100 гектар бөртекле ашлыкны вакытында урып алыр өчен бер комбайн исәбеннән чыгып санаганда, колхозның техника белән кораллануын түбәндәге саннар сөйли:

| | 1958 ел | 1965 ел | 1985 ел | 2000 ел |
|---|---|---|---|---|
| Тракторлар | 7 шт | 16 шт | 28 шт | 23 шт |
| Комбайннар | 4 шт | 5 шт | 18 шт | 13 шт |

Бу елларда колхозда сыерлар саны да яхшы гына арткан иде. Мәсәлән, 1961 нче елда-144 баш, 1965 нче елда-135 баш (бруцеллез), 1988 нче елда-640 баш булды, 660 башка җиткән иде.

Ә инде перестройкадан соң нык кимеде. 1990 нчы ел-560 баш, 1997 нче ел-200 баш калды, 1999 нчы ел-210 баш, 2000 нче елда-220 баш сыер булды.

Шунысын да әйтергә кирәк, чиста парлар юк иде. Занятый парларга чәчелгән уҗымнар язга юкка чыга. Ахыры илебез белән буш башаклар булганбыздыр, райкомнан бирелгән күрсәтмәне генә үтәп торып. Хәзер ичмаса ул якка иркен, шулай яхшы да, үзең уйлыйсың ничек уңыш алып була.

Колхоз җитәкчесе булып Хәбиб Гайзуллович Нигматуллин

эшләгән заманны, 60-70 нче елларны аерым әйтеп китәсе килә, чөнки бу чорда мин аның белән бергә агроном да, партоешма секретаре булып та эшләгәч, бу вакытларны яхшы беләм дип әйтеп була.

Хәбиб Гайзуллович вакытында клуб - СДК төзелеп бетте, вальцовый тегермән (бу тирәдәге авылларда беренче булып) һәм фураж тегермәне (простой помол) төзелделәр һәм эшләделәр. Колхозда кирпечтән правление бинасы, коровниклар (спаренный) төзелде. Яңа урында 2 этажлы, кирпечтән мәктәп, тулысынча колхоз акчасына, хозспособом. Кирпечтән дуңгыз фермасы, амбарлар янында яңа складлар, шулардан берсе гипсоблочный , дежурка-сторожка, өч ЗАВ, весовое хозяйство, шулай ук колхоз исәбеннән авылны телефонизацияләү, күперләр, ике мастерской, атлар конюшнясе, картофелехранилище, пилорама, телятниклар һ.б. төзелеп бетеп, файдалануга тапшырылдылар.

Колхозчының хезмәте авыр булса да, ул елларда ай саен эш хакы түләнеп торды, күп үк булмаса да премияләр дә биргәлиләр иде. Басуларда тракторлар язын-көзен ике смена эшләделәр. Урып-җыю вакытында комбайннар чык төшкәнче туктамадылар (кай вакытта төнлә барып ашата да идек). Вакыты белән механизаторлар, штурвальныйлар өйләренә кайтмыйча, бункерларда гына йоклаган очыраклар булгалый иде. Амбарлар янында, токта асфальт булмаса да, үләнне тамыры белән кырып, ток ясап, көндез хатын-кызлар дистәләп, ә төнлә, кичке сменада күбесенчә яшьләр эшләде. Элегерәк, бөртекне веялкалар аша, кул белән әйләндереп, чүптән чистарту башкарыла иде. Аннары бензин моторлары чыкты, тора-бара электродвигательле ярыйсы гына эшли торган агрегатлар уйлап чыгардылар. Иң яхшысы, билгеле ЗАВлар иде. Алар чыкканчы, токта вышка ясап, ашлыкны өскә чиләк белән биреп, аннан аны аска ыргытып, җилгәргән период та булды.

Көчле яңгырлар вакытында, токтан яңгыр суы белән ашлыклар аккалады да. Прокуратура, народный контроль тикшерүләре, аларның хаклымы-юкмы җәзаларын да алгаладык. Төрлесе булды.

Ирешкән уңышлары өчен колхоз КПСС Үзәк Комитетының күчмә Кызыл Байрагы белән,  ә тырыш хезмәт күрсәткән колхозчы авылдашлар хөкүмәтнең орден-медальләре белән бүләкләнделәр.

Менә аларның исемлеге:
Вахитов Вәли - председатель колхоза
Хамзин Минәхмәт-бригадир
Абсаттаров Фәрит-механизатор
Билалов Рәшит-агроном
Галиев Равил-шофер
Нигматуллин Хәбиб-председатель колхоза
Харисов Хабибнур-механизатор
Губайдуллин Хамидулла-механизатор
Фатхутдинов Зават-механизатор
Байбеков Фәйзулла-механизатор
Сибгатов Җәгъфәр-механизатор
Хасанов Наил-механизатор.

Ул чорларда төзү эшләре өчен, колхозның башка-кирәк ярагына материал табуы читен иде. Шуңа аларны табу өчен төрле, кайчакта бик үк законлы булмаган ысулларга барырга туры килгәләү дә булды. Менә бер эпизод. Бервакыт Х.Г.Нигмәтуллин бер “операция” оештыра. Нефтяникларның “урынсыз яткан трубаларын, вышка сегментларын, цистерналарын төнге буранда тракторлар белән тарттырып, ферма янына кайтартты һәм колхоз хуҗалыгына эшкә җибәрде. Алардан сүткән угольниклар Пулат бүләгендә-Тиләгәздә-елгада эстакадада, искергән Дауд күпере урынына яхшы нигез-основание булып, хезмәт итеп яталар. Ә цистерналарыннан фермада малларга кормы, тапаган саламны тутырып, парлап бирер өчен җайланма ясадылар. Безнең анда эшләүчеләр анарга “Байконур” дияләр иде. Югалган метал әйберләрен хуҗалары килеп эзләп, тикшереп йөределәр, алай-болай түгел, вертолетлар белән. Основные средства бит, аларны, бигрәк тә вышка сегментларын списать итәргә бик кыен диләр.

Җәй көне, печән өмәләрендә, колхоз симез тәкәләрен суеп, кашеварлар учак өсләренә тагылган казаннарда шурпа пешереп, берничә дистә өмәче бригад саен табын ясап, кичкә таба ишәеп киткән өмәчеләрне бераз “кәефләндереп”, сыйлау уздырыла иде. Аннан печәнне кипкәч, кул белән җыеп, атлар белән фурманнарга төяп ташып, эскертләргә ияләр иде, әлбәттә барысы да кул көче белән эшләнә иде. Соңга таба төрле сенокосилкалар, копнительләр, пресс-подборщиклар кайта

башлады. Эскерт өю стогометательләргә бирелде. Колхоз бөртекле культуралардан башка тагын бәрәңге-200га, 150га якын мәк йә кориандр, мал күп чакта 500 әр гектар азык культуралары (кукуруза, вика-овес, люцерна, костер, донник һ.б.). Кукуруза бик уңган елларда җыеп бетереп булмыйча, кар астында калгалады. Алдарак, сугыштан соң, көксагыз, киндераш, җитен чәчелгән булган. Җитенне әле соңырак, перестройка чорында тагын чәчә башладык. Бәрәңге үстерү бигрәк тә авыр эш, ә алуы тагын да кыенрак, аеруча көне белән кырдан хөкүмәткә-Куйбышевка озатуы. Куйбышевтан заводлардан эшчеләр, институтлардан студентлар, хәрби частьләрдән солдатлар, 200 ләп кеше бәрәңге алышырга килгәләделәр. Мәкне мәктәп балалары утыйлар иде. Берәр гектар утап чыгалар иде, әлбәттә күбрәк акчасына кызыгып. Тик мәкне озакламый чәчүдән туктатырга мәҗбүр булдык, чөнки читтән килүче "охотниклар" әфъюнчылар күбәеп китте, милиция дә саклап маташты, әмма барыбер чәчү бетте.

Колхоз председательләре турында сүзне дәвам итеп, безнең әтиебез, Билалов Кыям сугышка кадәр, 1941 нче елның августында сугышка киткәнче, башта Совет, аннан колхоз председателе булган. Мин нигытып хәтерләмим, тик ат белән тарантаста йөри иде төсле. Соңгы илле ел эчендәге колхоз председательләре арасында, Балыклы халкының тормышын яхшырту өчен, сугыштан соңгы елларда күп көч куючы Вахитов Вәли Закирович булды дияр идем. Ул эшли башлаганда колхоз таркау хәлдә була. Бригадларда корчаңгы атлар, фермаларда ярым ач, арык сыерлар, бөтен авыр колхоз эшен җигелеп тартучы көч-сугыш аркасында тол калган хатын-кыз һәм сугыш инвалидлары булды. Ә эшкә ярый башлаган яшьләрне хөкүмәт фәрманы белән, мәҗбүри рәвештә шәһәргә ФЗО га җибәрделәр, теләмәгәннәрен, качарга маташучыларны аулап, тотып озаткаладылар. Шундый хәлдә Вахитов В.З. бар көчен, энергиясен эшкә сарыфлап, ару-талу белми колхозны тарта һәм хуҗалыкны аякка бастырып, районда алдынгы колхозлар санына чыгара. Үзенең тырышлыгы, халык мәнфәгатьләрен кайгыртучанлыгы, намуслы, игелекле, ярдәмле, нәфсесезлеге белән ул авылдашларының һәм тирә-як күрше халыкларның тирән ихтирамын яулады.



*Комбайнер Каюмов Минахмет, ярдәмчесе Билалов Марсель. 1990 ел.*




*“Правда” колхозы. Печән чабу*



*Кырда чәчүгә чыгу алды*




*Колхозда силос әзерләү*



*Чәчү агрегаты*



*Агроном кырда*



Колхозда печән чабу




Мастерскойда ремонт вакыты



*Язгы чәчүне тәмамлау җиелышы. 1979 ел.*



*Фермерлар. 1959 ел.*



*Каримова Хәмидә*



Икенче, яхшы абруй казанган председатель-Хәбиб Гайзуллович Нигматуллин төзелеш өлкәсенә күп игътибар бирде, тормышыбызны көнкүрешебезне яхшыртырга омтылды. Колхозның гына түгел, ә колхозчыларның, авыл халкының күмәк тормышын яхшыртырга да күп көч куйды. Кырларның уңдырышлыгын күтәреп, культураларның уңышларын арттыру ягында да читтә тормады, эчендә кайнады, яхшы беләм, чөнки бергә эшләдек. Аның вакытында авылны гомуми хөкүмәт электро челтәренә тоташтырып, даими электр энергиясе белән тәэмин иттерде. Алдарак язылган эшләренә өстәп, колхоз акчасына авылда телефонизация төзелде, халыкка өйләр төзү өчен колхоз техника, автомашиналар биреп торды. Ул бер башлаган эшен ярты юлда калдырмады. Аның белән барча мәсьәләне уртага салып сөйләшеп, хәл итеп була. Аны хуҗалык эшләрен яхшы оештыручан җитәкче дип бәяләп була. Авыл халкы да, тирә-яклардагы кешеләр дә аны ихтирам итә, аның кайда да сүзе үтә. Аңа мөрәҗәгать иткән кешегә турыдан ярдәм итә алмаса, киңәш белән булса да булышырга тырыша. Төрле җыелышларда эчтәлекле, төпле чыгышлары, киңәшләре бар.

Бик тә тынгысыз кеше, председатель Сагиров Минаксән Ахметгалиевич эшләгән елларга ифрат та авыр, акчасызлык туры килде. Нәкъ менә шундый заманнарда аның кебек тынгысыз, фәгал, актив кешеләр, кайчакта кызыбрак китсә дә, авыл өчен бик урынлы, нәтиҗәле эшлиләр. Ул колхозны, күрше авыллардагы кебек агым уңаена тапшырып, таралырга ирек бирмәде, колхоз итеп саклап калды. Эшләгән кешегә колхозда хезмәт хакы түбән булса да, эш урыны бар. Сагировның тырышлыгы белән авылга бик көтелгән газ үткәрелде, ГРП төзелде, зиратны метал ихата белән әйләндереп алу да аның тырышлыгы белән эшләнде, авыл халкы болар өчен аңа бик рәхмәтле. Тагын икешәр фатирлы ике йорт төзелеп, файдага бирелде.

Ә колхоз хәле илдәгечә. Уртак, күмәк көч белән төзелгән күп кенә коровниклар, телятниклар бушый баралар, акча кытлыгы аркасында ягулык, запчастьләр алыр өчен шул малларны сатарга туры килә. Бу хәл югарыдагы хакимнәрне һич борчымый. Сагиров, миңа калса, кулыннан килгән кадәр, малларның калганнарын булса да, сакларга тырыша. Чөнки

мал булгач, халыкка бигрәк тә кыш көннәрендә эш юк, диярлек, булса да-бушка, элеккеге трудодни системасына әйләнеп бара. Хзерге заман тырыш, тынгысыз, эзләнүчән, яңача фикер йөртә торган кешеләр заманына әйләнде. Минемчә волость хакимиятенә, колхоз хуҗаларына, яшьләргә бергә уйлашып, авылыбыз милкен, хуҗалыгын саклап калу, аны үстерүнең яңа юлларын эзләргә кирәктер.

Янә колхозда председатель булып эшләп алган шәхесләр турында дәвам. Каюмов Минәхтәм һәм Фардеев Рәшит вакытларында колхозда квартирлар төзелде, шулар әзрәк яшьләрне авылда тота әле. Каюмов Минәхтәм вакытында фермада 4-х рядный коровник, 200 баш сыер өчен, шулай ук зур родильный бинасы (телятнигы белән) төзелде, токта бетон мәйданчык һәм ашханә корыла башлады. Фардеев Рәшит амбарлар янына тагын бер яңа склад төзетте.

Һәр заманның була үзенең күренекле кешеләре, һәрбер чорның үз алдынгылары, йолдызлары, әләмчеләре. Андыйлар турында да әйтеп үтәсем килә, чөнки алар минем чордашлар, бергә эшләгән хезмәттәшләр. Фикеремчә, безнең Балыклыда тырыш, намуслы, намуслы хезмәт үрнәге күрсәтеп эшләгән алдынгы авылдашлар бихисап, бар да орден, медаль белән бүләкләнмәсәләр дә. Комбайнерлардан Хасанов Нәззах, соңырак малае-Хасанов Наил, Әхәт Закиров, Фәрит Абсаттаров, Хамидулла Гобәйдуллин, Дамир Сайфутдинов һ.б.; шоферлардан-Идрис Ангалышев, Сираҗ Сайфетдинов, Саҗит Билалов, Равил Галиев, Кәрам һәм Сахиман Шараповлар, Рәшит Шарапов, Әнәс Хамзин һ.б.; трактористлардан Нәҗми Юсупов, Нәсиб Хәбибуллин, Рәшит Ахметзянов, Рәшит Галлямов, Әхәт Галимов, Галимҗан Халимов, Хәбибнур Харисов, Җават Фатхутдинов һ.б.

Малчылыкта-Рушания һәм Әнисә Юсуповалар,Фәнүзә, Хәмдия Гиззатуллина-Ахмадуллина, Давлетшина Рәкибә, Хакимова Равилә, Минсәхи Шангарәев, Мәрьям Шамсутдинова (Коняева), сыер савучы-дояр Билалов Зыя. Күп еллар буена зоотехник булып эшләгән Халидә Шиһаповна Фардееваны аерым билгеләп үтәсе килә. МТМ мөдире Әюп Абсаттаров, сварщик Рифкать Ягфаров, ток мөдире Кәнзел Галиев, төрле эшләрдә катнашып эшләгән,

алдынгы, атказанган колхозчылар Нигъмәтуллин Гайзулла, Ахмадуллин Хәйрулла һәм башка бик күп тырыш хезмәт итүчеләр колхоз өчен күп көчләрен куйдылар. Фидакарь хезмәтләре өчен зур рәхмәт аларга!

Алдынгы сыер савучыбыз Сагдиева Нәбирә апаны хөкүмәт бүләгенә, орден йә медальга дип документлар әзерләп югарыга җибәргән идек. Кләүле КПСС район комитетыннан тикшерелеп узган иде. Ләкин Куйбышевта КГБ тикшергәч, уздырмаган. Әллә инде ФЗО дан качып кайткангамы, әллә кесәсенә 800 грамм бөртек салып кайткан өчен алты айга хөкем ителгәнгәме?

Күп булды инде чорыбыз белән якты киләчәккә, коммунизмга таба сикәлтәле юлда янәшә, кулга-кул тотышып атлаучыларыбыз да, арттан иярүчеләр дә... Коммунизм хакында көлемсерәбрәк сөйләсәк тә, ул бик ерак та булмаган икән, чөнки барыбыз да тигез идек. Шикле миллионерлар, миллиардерлар, олигархлар юк иде.

Ә мин үз чорымны, ни булса да хурлауга, төрле куштаннар уйлап тапкан “торгынлык чоры” дигән, фикеремчә ялгыш бәяләүгә каршы һәм риза түгел. Бигрәк тә 70-80 нче еллардагы илебезнең дә, авыл хуҗалыгының да халәте югары биеклектә, тәррәкыят кичерү чоры иде. Шуңа, көчебезне, ил куәтен тоемлап, безнең тирә-ягыбыздагы көнче дәүләтләрнең хакимият даирәләре, бүгенгечә дошманлык үрнәкләрен ачыктан ыржайта алмыйлар иде, ә элеккегечә, тиешле дәрәҗәдә абруебызны санлап сөйләшәләр иде.

Әлбәттә, үткән чорыбызда авырлыклар да, ялгышлык-хаталар да, начарлыклар да булгалагандыр, объектив сәбәпләр белән дә, җитәкчеләрнең җитешсезлекләреннән дә, бәлки, әмма яхшы яклар, халыкка канәгатьлек бирә торган эшләр күбрәк булды төсле.

Без үткәннәребез һәм бүгенге көнебез, тормышыбыз турында бу кәгазьгә язгалап, Балыклыбыз тарихы каршында, начармы, яхшымы җавап тотып маташу, чордашлар гаепләмәсләр дип өметләнәм. Киләчәктә, бәлки тарих көләр дә, белмәссең. Чөнки ул яңа буын, яшьләр белән инде бу дөньяда беркайчан да очраша алмаячакбыз.

# Механизаторлар, шоферлар

Авыл тарихы, аның искән җилләре, эзләре буйлап барсаң, шик юк- нәрсә дә булса табасың. Моңа озак еллар бергә эшләгән механизаторларны, шоферларны да әле нигытып эзләмичә дә, белгәннәрен искә алыйк әле. Кайсылары сугыш вакытында, сугыштан соң эшләде, ә күбесе "Застой" дип аталган елларда, тиздән коммунизм була дип эшләделәр, яшәделәр. Әле бу иптәшләрнең күбесенең техника янындагы солярка исләре дә бетмәгән.

Мусин Нәгыйм
Хамзин Хәмит
Хабибуллин Нәсиб
Галимов Әхәт
Абсаттаров Әюб
Әхмәтҗанов Рәшит
Фәтхетдинов Җават
Гобәйдуллин Равил
Коняев Ильяс
Хасанов Нәзах
Коняев Исхак
Галлямов Рәшит
Билилов Саҗит
Ангалышов Идрис
Хамзин Минәхмәт
Мавлютов Зәкиулла
Гобәйдуллин Хәмидулла
Кәримов Мәгдән
Шәйхетдинов Рәшит
Усманов Рәхимҗан
Йосыпов Хәмит
Гыйляҗев Әгтәс
Ганниев Минәхтәм
Гобәйдуллин Фаик
Әхмәдуллин Рәшит
Рәхмәтуллин Эдуард
Фарукшин Наил
Халимов Нургали
Закиров Әхәт
Сәйфетдинов Сираҗ
Абсаттаров Фәрит
Әһлиуллин Әхсән
Шарапов Рәшит
Гобәйдуллин Миргабиҗан
Гыйляҗетдинов Минәхмәт
Мөниров Исламнур
Мөниров Хәбиб
Билалов Инсаф
Хәбиров Зәкиулла
Халимов Хаҗивәли
Сәгыйров Нәфигулла
Сөләйманов Зәйнулла
Камалиев Рәшит
Шарапов Кәрәм
Шарапов Сахиман
Халимов Галимҗан
Шарапов Галялетдин
Хасанов Наил
Закиров Рамил
Галиев Равил
Хамзин Халик
Шангаряев Рафаэль
Коняев Идрис
Музафаров Кыям
Шәмсетдинов Фәсәй
Сәгъдиев Әпти

Абсаттаров Әбүгали
Ганниев Минегалим
Билалов Мәҗит
Сәйфетдинов Дамир
Шәрәфетдинов Рафыйк
Музафаров Фаик
Әхмәдуллин Рәмис
Фәтхетдинов Нәбиулла
Фардеев Минвәли
Каюмов Минәхмәт
Каюмов Альберт
Дәүләтшин Нәҗип
Сәгдеев Минсәгыйт
Шарапов Гомәр
Билалов Рәхим
Билалов Рафаэль
Насыйров Мәҗит
Байбеков Фәйзулла
Сибгатов Җәгъфәр
Якупов Хәмит
Ангалышов Руслан
Гобәйдуллин Ренат
Халимов Нәдергали
Насыйров Мәҗит
Хайруллин Әбүзәр
Хайруллин Сәмигулла
Хайруллин Зәйнулла
Юсупов Минсагит

## *Малчылыкта эшләүче хатын-кызлар*

Мин хәзер соң булса да авылыбыз эзләреннән байтак бардым. Ә малчылыкта эшләгән йөзгә якын кеше турында язарга ничектер аптырап калдым. Бездә бит сыер, дуңгыз, сарык, тавык, ат фермалары бар иде. Мондагы эшләүче хатын-кызлар бер генә эштә эшләмәделәр. Шуның өчен аларны искә төшереп күмәк язам. Шуны әйтеп үтәргә кирәк, илебез хуҗаларының 1993-1995 еллардагы приватизация дигән политикасы, малчылыкның рентабельностен югалтты...

Барыбер безнең малчылыкта көннән-төнгә кадәр эшләгән халыкның күбесе озак еллар булсын диеп эшләүләре белән искә алыйк. Авызың чалыш булганга көзгегә үпкәләүдә файда юк диләр бит. Эшләп йөргән чакта көн дә дневник алып барырга иде, юк, язып барылмады.

Монда аларның истә калганнары:

Аскарова Асия
Гафурова Диләә
Усманова Камәр
Гафурова Шәмсенур
Насыйрова Кәримә
Кәримова Сәлимә
Ваһаҗева Мөхтәрәмә
Йосыпова Рушания
Йосыпова Әнисә
Насыйрова Халидә
Гыйляҗева Минзада
Дәүләтшина Энисэ
Вагыйзова Җария
Шакурова Җария
Усманова Фәридә
Шагиева Әлфия

Кәримова Минебәдәр
Йосыпова Мәдинә
Сәгъдеева Нәбирә
Насыйрова Гөлсинә
Билалова Динә
Билалова Хәлимә
Мавлютова Минсафа
Хөснетдинова Нәфисә
Хөснетдинова Нурия
Дәүләтшина Мәгъдәнур
Закирова Хаҗәр
Шәйхетдинова Гакилә
Хөсәинова Җамал
Билалова Халидә
Халимова Зәйнәп
Әхмәдуллина Мәдинә
Әхмәдуллина Миннур
Әхмәдуллина Гөлчирә
Рәхмәтуллина Асия
Шәмсетдинова Мәрьям
Шәмсетдинова Минниса
Шәйхетдинова Мәгъдәнур
Ягъфарова Махира
Әхмәтҗянова Роза
Усманова Кәримә
Халимова Рафика
Әһлиуллина Әминә
Халимова Сәлимә
Дәүләтшина Рәкибә
Хакимова Равилә
Шакурова Дания
Шакурова Мәхтүмә
Гыйззәтуллина Фәнүзә
Әхмәдуллина Хәмдия
Насыйрова Сәкинә
Мөнирова Фәһимә
Хайруллина Сәрия
Хайруллина Сәрия
Хамзина Талига
Сафина Гөлсинә
Усманова Мәдинә
Каюмова Роза
Шарапова Миңсылу
Сафина-Ильина Хәдичә
Абсаттарова Әминә
Аһлиуллина Мөхедия

# МТС



*МТС эшчеләре. 1953 ел.*

Балыклы МТСы авылның көньягына, Шарлама елгасының башына табарак, авылдан читтәрәк урнашкан иде, чөнки әле авыл кырыенда халыкның ындырлары, ашлык, кормы, ары-бире техникасын, эш коралларын саклый торган урын булгандыр. Бәлки МТС өчен урын сайлаучыларның үз сәбәпләре, таләпләре булгандыр. Ишеткәнемчә, Балыклы МТСы ике районны, Камышлы (Байтуган) белән Похвистнево районнарын тәэмин итәр өчен, авылларда коллективизация көчәйгән вакытта, 1931 нче елның язында оештырыла һәм шул елның язында ук цистерналарны, Интер, Фордзон, Путиловец дигән тракторларны, трактористлар-Ахметшин Мәрданша, Каримов Ибрай, Аскаров Әхмәдулла, Аскаров Шафик, Ганниев Нәсип, Ганниев Шәһит, Шамсутдинов Закир, Хәбибуллин Юсуп, үзйөрешләре белән куып кайталар.

Бөтен авыл халкы бу "шайтан арбаларын" карарга чыга, гаҗәпләнү һәм бераз шикләнү белән карап, булачак МТС ягына, әлегә буш кырга, озатып калалар.

МТСның төп корылмасы-мастерское, саман кирпечтән салынган, түбәсе саламны мәте балчыгы белән бутаган измә белән ябылган иде. Эчендә утын белән ягыла торган, һәр цех саен аерым мичләр бар иде. Һәр цехта, токарный,

фрезерный, чарлау, тишү өчен махсус җайланмалар, станоклар урнаштырылган иде. Аларны хәрәкәткә китерер өчен аерым бүлмәдә эшли торган нефть двигателеннән траншеягә салган валлар системасы эшләнгән иде. Сугыштан соң, нефть двигателе урынына дизель электростанция көйләп куеп, ул системаны эл двигательләргә алыштырдылар. Бервакыт җил белән эшли торган эл станциясе дә куеп маташканнар иде, тик ышанычлы итеп эшләтә алмадылар. Тракторлар ремонтлау өчен аерым, ягылмый торган агач мастерской-гараж бар иде. Аның торецында тимерче цехы - (кузница), пристройкасында-медный цех. Кузнечный цехта Андрющенко һәм Вагапов Минәхмәт, медный цехта-Мусин Нафик белән Вафин Рафаэль эшләделәр. Төп мастерскойда аерым бүлмәдә-комплектовочный цех-анда кыш көннәрендә комплектовщиклар булып Вахитов Вәли, Нигъмәтуллин Нәбиулла, Шарафетдинов Борһан һ.б. эшли. Магнетолар төзәтә торган электроцехта Рәхмәтуллин Саяр эшләде. Тагын МТСның өч бүлмәле конторасы, аерым ашханәсе, ларегы белән, аерым бинада клуб, радиостанция. Пожарка конюшнясе белән аерым, запчастьләр склады, башы да япмаган такта гараж бар иде. Ике коеның мастерской янындагысы чиста, күп сулы, яхшы иде, ә бараклар янындагысы, аралары ике-өч йөз метр булырмы-суы бик тирәндә һәм әз иде.


Нефтебаза территориясе әйләнәсе штакетник белән тоткан, эчендә зур (70куб/м) цистерналар аерым тәртиптә, махсус нигезләргә куелган, майлар өчен аерым бер землянка һәм кечерәк кенә агач өй-дежурка. Анда Харисова Җәүһәр апа озак еллар төрле сорт горючее-ягулыклар, китергәннәрен кабул итеп, цистерналарга, кирәк җиргә озатканда-мичкәләргә кул насосы белән качать итеп торды. Ә әтисе шунда каравылчы иде. Нефтебаза мөдире булып Хусаинов Миргабиҗан һәм Сыйтдиков Әнәс эшләделәр.

Нефтебазага ягулыкны МТСның баштагы елларында да, сугыш елларында да Кләүле станцасыннан атлар белән ташыганнар, запчастьләрне дә Кләүледән дә, Сургуттан ГУТАП дигән организациядән шулай ук атлар белән, ә кышын трактор чанасында, толыплар киеп барып, алып кайталар иде. Тора-бара, сугыштан соң, ягулыкны бензовозлар ташыды, башка кирәк

әйберләрне ташыр өчен автомашиналар булды. Кләүлегә ашлыкны да җәй атлар, арбалар белән, ә кышын, шул ук трактор чанасында.

Без, авыл малайлары, МТС клубына кино карарга менә идек. МТС та читтән килеп эшләүчеләр байтак булды. Алар өчен барак төсле тулай торак-общежитие да, хөкүмәт тәэминатында бугай, бар иде.

МТС әкренләп, колхозларга техник булышлык күрсәтү буенча мөмкинлекләрен арттыра, киңәйтә бара, чөнки техникасы ел саен арта тора. 1935 нче елның башына МТС та инде 43 трактор, 7 комбайн (СЗК, Коммунар һәм Сталинец-1), 25 молотилка, сабаннар һәм башка инвентарьлар җыела. Бу елларда МТС түбәндәге авыллардагы колхозларда чәчкән, урган: Балыклы, Яңа Балыклы (Карамал), Камышлы, Дәүләткол, Бозбаш, Йолдыз, Яңа һәм Иске Ярмәкләр, Чулпан, Седяково, Чекмаловка, Михайловка, Пугачевка, Степановка, Конновка, Мәзгүт, Ст.Выселки, Поникла, Яңа Осоргино, Чугуновка (Топкий, Ямный, Редкий поселоклары), Яңа һәм Иске Чаговка, Хмелевка, Неклюдово, Дурасово. Яңа һәм Иске Усман, Бакай авыллары, Татар, Рус, Чуваш Байтуганнары, Алтын Тау, Красный Яр поселоклары баштан МТСка кергәннәрме, юкмы-белмим. Тик “Кулак поселогы” - Красный Бережок - МТС хезмәте күрсәтү рәтенә башта кертелмәгән булган.



*МТСның уборка агрегаты*

МТС инде шактый зурайган булса да, колхозларның барчасына да ярдәм, булышлык күрсәтеп өлгерә алмый, колхозлар күп, ә көч һәм белем җитми. Ә икмәк авыл халкына да, шәһәр кешесенә дә көн дә кирәк. Хөкүмәткә, арта барган ашлык сату планнары үтәлми башлый. 1933 нче елны, МТС ларны ныгытуны күздә тотып, аларда политотделлар ясыйлар. Политотдел җитәкчеләрен ВКП(б)ның Үзәк комитеты үзе билгели. Аларның төп бурычлары хөкүмәткә ашлык тапшыруны арттыру, тәртипне җайлау, яңа кадрлар хәзерләү, техникаларны рациональ рәвештә эшләтү була. Политотдел җитәкчеләре: Гаврилов, Рахманкулов, Абдеев В., Ахметшин М. булалар. Балыклы МТСында директорлар: Шелковников, Гатауллин, Сагдеев, Галимуллин, Абдеев В., Байбеков А.Г., Кузнецов В.И., Ахметшин М. булалар. Рабочком председателе итеп-Вахитов В.З.сайлана. Инженерлар: Тихонов М.Я., Михайлова Нина, мастерской мөдирләре: Каримов Н.М., Шафигуллин Ш., Вахитов В.З.Агрономнар:Тарабрин., Камалиева Зәйнәп, Нугайбекова Әминә, Вахитов Наил. Соңырак колхозда, МТС ябылгач:Багаутдинов Гата, Фаттахов Мәҗит, Вахитов Наил, Баляба Виктор, Билалов Рәшит, Гайнутдинов Фәһим, Хамзин Рәфкать, Калиновский Николай Петрович, Сафиуллин Нургали, Салахов Марат һ.б. Бухгалтерлар: Юсупов Нәзах, Усманов Мөхәммәт, Фаттахова Таухидә, Вагазов Хәмит, токарьлар: Громов, Радионов Павел, Сулейманов Бисмах, фрезеровщик Билалов Нурхамәт, слесарь- Рахматуллин Саяр, сварщик-Салахов Әсхәт, трактористлар: мин белгән Балыклы авылы кешеләре

Мусин Нәгим, Ганниев Минегалим, Юсупов Мөхәммәт, Билалов Рәхим, Шарапов Гумәр, Галимов Әхәт, Коняев Ильяс, Шарапов Галәлетдин, Гафуров Инсаф, Зарипов Абдрахман (Камышлыдан) һ.б.

Сугыш елларында тракторчы хатын-кызлардан: Абсаттарова Миннур, Галимова Минсруй, Сагирова Фатима, Нәбиуллина Гельмеҗиян, Юсупова Мәсхүдә (Бозбаш авылы кызы). Хатын-кызларның бригадиры-Зарипова Мәймүнә (Камышлыдан).

Балыклыдан комбайнерлар: Вахитов Вәли, Шамсутдинов Нәдер, Халиуллин Ярулла, Абсаттаров Әбугали, Коняев Исхак, Ганиев Минегалим, Фатхутдинов Нәбиулла, Хасанов Нәзах, Сагдеев Әпти, Багаутдинов Кыям һ.б.

Комбайнер Вахитов Вәлине 1940 нчы елны 1000 гектар ашлык урып җыйган өчен, премия рәвешендә Мәскәүгә күргәзмәгә - ВДНХга җибәрәләр. Мин ничә еллар комбайнерлар белән кайнашып та, инде яңарак, яхшырак комбайннар белән дә 1000 гектар урып суктыра алучы булмады, бу бик зур эш! Болай, суктырмыйча, покоска, валокка салучылар гына булды. МТС шоферлары: Юсупов Минәхмәт, Фардиев Минәхмәт, Шамсутдинов Фәсәй, Багаутдинов Кыям, Сулейманов Зәйнулла, Ярмәктән-Нургали абзый (бензовозда), Чекмаловкадан-Ольга, җиңел машина, трофейный "Виллис"та директорны йөртүче Ульян поселогыннан-Волкин Синнур.

Трактор бригадаларында, төрле периодларда бригадир булып эшләгән кешеләр: Хамзин Минәхмәт, Гафуров Инсаф, Абсаттаровлар-Сарим, Аюб, Коняев Ильяс, Ангалышев Газинур, Галлямов Кәрим, Шарапов Галялетдин; Ст.Выселкада-Дуплий И.Ф. соңырак-Фотин В., Дема В.В.

Галиев Нигмәт, Абзалов Бәдертдин, Вафин Гәзнур, Хабибуллин Сәйфулла, Сиразетдинов Гайфетдин, Губайдуллин Зәйнулла, Сафарин Григорий һ.б. механиклар булып эшләделәр. Ремонт эшеннән башка, алар запчастьлар да ташыдылар. Ә без, трактор бригадасында учетчик-заправщиклар-Аглиуллин Гариф абый һәм мин, Билалов Рәшит, 5 көн саен, язын-көзен тракторларның эшләре турында МТС бухгалтериясенә отчет биреп тора идек, ә көнлек сведениияне колхоз идарәсенә тапшыра идек. Кырларга шул эшләрне үлчәргә, сажень тотып, һаваларның ниндилегенә карамый, җәяүләп йөри идем. Аякта "мыегы чыккан чабата" иде. Күп йөри торгач ул да туза, әмма аякка җиңел.

Тракторларда, тагылма җир эшкәртү коралларын тагып, ычкындырып торырга, эшкә көйләргә прицепщик-плугарьлар-кызлар, трактористлар белән бергә, сменаны эшләп чыккач, трактор будкаларында, нарларда, яз да, көз дә кунып эшләделәр. Плугарьның вазыйфасы-смена буена сабан өстендәге тимер утыргычта йөреп, сөрү тирәнлеген күзәтеп, җайлап тору була. Кайчак, төнлә арып йоклап китеп егылып, сабан астында калып, имгәнүчеләр дә булды. Кашевар Вильданова (Усманова) Камәр апа иртәнге җидегә ашарга әзерләп, өлгертеп тора иде.

Водовозлар булып, үгезләр белән, Хасанов Инсаф, Галимов Минзәки, Билалов Рөстәм-мичкә белән, тракторлар эшләгән һәр кырның да ике башына, китереп куя иделәр, чөнки ул

вакытлардагы тракторларның моторлары кызып, радиаторда сулары кайнап кимегәнгә, суны өстәп торасы иде. Ягулыкны, майларны ташучылар-Усманов Закир, Насыров Рәфкать һ.б.булдылар.

Комбайннар җитешмәү сәбәпле, алдарак ашлыкларның бер өлешен лабогрейкалар белән чабып, хатын-кызлар көннәр буе көлтәләргә бәйләп, зуратларга куялар, аннан атлар, үгезләр белән ташып, озын саплы кул сәнәкләре белән эскертләргә өя торганнар иде. Мин үзем, 1949 нчы елны, 7 классны укып бетергәч, ат белән эскерт янына көлтә ташыдым. Ә көз соңында, кышын карда кул белән юл ачып, эскерт янына молотилка йә комбайн куеп, көлтәләрне суктыралар иде.

1953 нче елның сентябрендә узган КПСС үзәк Комитетының пленумы вакытында дәүләт җитәкчеләре авыл хуҗалыгының бик ярлы, мөшкел хәлдә икәнен аңладылар, булса кирәк. Трактористларга, механизаторларга эш өчен хезмәт хакы түләүне арттырдылар, гарантияләделәр. Нәкъ бу елларда чирәм җирләрне күтәреп, үзләштерү мәсьәләсе күтәрелде һәм күп яшьләр, комсомоллар күтәренке романтик хис белән анда бара башладылар. 1954 нче елны МТСта трактористлар әзерләү курслары ачылды. Мин дә анда укыдым. Укытучыбыз Елин И. иде. МТСка яңа техника-С-80 тракторлары, үзйөрешле С-4 комбайннары кайта башлады. 1958 нче елда Н.С.Хрущевның импульсив карары нигезендә МТСлар ЛЗС-РТСка әйләнде. Техникалар колхозларга сатылды. Балыклы МТСның корылмалары берничә ел “Кызыл көрәшче” колхозының мастерское булып тора. Яңа, гипсоблоктан салынган контора бинасы башта участковая больница-стационар булып алды, ул ябылгач, лесничество конторасы урнаша, бераз вакыт фатир да булып торды, аннан бетте.

Шулай, авылыбызда МТС 27 ел дәвамында эшләп, район колхозларында җирне сөргән, чәчкән, ашлыгын урган. Билгеле инде, хөкүмәткә натуроплатасын түләткән. Бигрәк тә, Яңа Ярмәк кешесе, МТС директоры Абдеев Вафа А. чорында.

# ВАТАН СУГЫШЫ ЧОРЫ



Сугыш алдыннан, инде азрак рәткә керә башлаган, авылыбыз тормышын Ватан сугышы боза. Сугыш башлангач безнең халыкның бөтен тормыш кагыйдәләре пыран-заран килде, диләр.

Мин бәләкәй булсам да, аз гына хәтерлим, ул вакытта безнең өйдә радиоалгыч бар иде, бугай. Дүрт почмаклы, стаканнан зуррак, батарейлары белән. Әти шуны тыңлый иде, янына тагын кемнәрдер радионы тыңларга керәләр иде төсле. Сугыш башлангачтыр инде, аны озак тотмыйча, алганнар, батарейкалары гына калган һәм биргән квитансалары, матчага кыстырган килеш озак тордылар.

Сугыш башлануы турында күп кеше Сабан туеннан соң, Камышлыдан ишетеп кайта. Тик әле халыкта тирән борчылу, курку хисе шундук күңелләргә кереп, тетрәтми. Берничә көн, ир-атның күбесе, китәрмен дә кайтмам, дип уйламый, уйласа да нишләсен, кайсысы уйларга да теләмәгәндер. Сугыш тудыра торган җитешсезлекләрне, авырлыкларны, бигрәк тә ашлык, азык җитмәсен авыл халкы әле ачык күзалламый, сугыш озакка барыр дип уйламый, чөнки соңгы нык ачлык еллары артта калган, онытыла язган. Халык арасында: "Әй, килмәгәе соң ул "мимеч", дигән уйны күңелендә йомып йөрүчеләр дә булуы бик ихтимал. Озакламый, салмак кына, картина үзгәрә, авыл халкының хәле, инде бер уңайга көйләнгән яшәү калыпларыннан, колеясыннан чыга башлый. Яшәү торган саен катлаулана бара. Сугышның башланган айларында әле авылдашлар ашлыктан он тарттырып,

хатын-кызлар мул итеп икмәк салганнар, ә тора-бара, икмәк салганда, инде аңарга бәрәңгене кырып, шуны өстәргә туры килә башлый. Инәй миннән, алюмин тәлинкәне кадак белән тиштереп, кыргыч ясаткан иде. Миңа 7-8 яшьләр булгандыр, ул тәлинкә кыргыч әле дә исән, каядыр келәттә эленеп тора. Шул кыргыч аша чыгарган бәрәңгене, бер-ике уч он кушып, ипи сала башлыйлар. Ә шулай ашарлык мөмкинлекләре булмаганнар, ачтан шешенеп йөргәннәр. Шулай, сугыш китергән ачлык, авылдашларны яңадан төрлечә тамак туйдырырга өйрәтә, мәҗбүр итә. Бер уч онны бер чиләк бәрәңгегә бутап камыр ясарга, инде урылган кырдан башак җыярга (көздән аны да җыярга тыела), ә язга ул башак күксеп агуга әйләнә. Шул башактан Сәйфетдин бабайлар өй эчләре белән, яшь кыз Минибаева Мөкатдимә агуланып үләләр. Мин бер мәртәбә, Тиләгәзе елгасы аша, яз көне Ст.Выселка кырына бата-чума башак җыярга барганны хәтерлим. Ә инәй ул башакны нишләткәндер, исемдә юк. Тагын, кыш чыккач, бакчалардан өшегән бәрәңгене табып, казып (бездә аны “пәлге” дияләр иде) анардан көлчә, җәймә кебек нәрсә пешереп ашаганны мин дә хәтерлим. Балтырган, кычыткан, чөгендер яфрагыннан аш пешерәләр иде, йомырка, май да өстәлсә, бик тә тәмле тоела иде.

Соңырак, бер вакыт, хөкүмәт кибетләргә, Азиядәндер инде, сап-сары, теш сындырырдай каты, мамык төбе (жмых) җепләре белән, китерткән иде. Аны да авыз итәргә туры килде.

Кешеләр үгез, кайсылары хәтта сыер җигеп, бакча сөрделәр, кышын да, язгы наст белән дә, җилкәсендә бәйләм-бәйләм урманнан утын күтәреп кайтты халык.

Инәй (мәрхүм, урыны оҗмахта булсын, иншалла!), иптәш, тол калган хатыннар белән, сыер маен җыеп, стансага чаклы җәяү, бәләкәй чана тартып, Куйбышевка базарга барып сата иделәр. Ни эшлисең, исән кешегә үзенә дә, бала-чагага да (ә без өчәү), ашарга да, кием-салым да кирәк бит.

Бу сугыш каһәре китергән ачлык, ялангачлык авылыбыз халкын аермаган, хөсетлек, бер-береннән читләшү хисе чәчә алмаган, алар бергәләшеп, тупланып яшәгәннәр. Шырпы булмаган чакта (шырпысы да бит әле тарак шырпы!), мичтә калдырылган кисәү сүнсә, иртүк, караңгыдан күршеләрдән утлы кисәү табып, йә утлы күмер алып кайтып, мич кабызалар иде.


Тәмәке тартучылар чакма чагып, игәү сыныгы белән чакма ташына сугып, чаткыларыннан мамык сыман нәрсәгә ут кабып, шуннан тәмәке кабыза иделәр.

Шушы уңайдан, А.М.Хәйровның "Есть в Заволжье село" дигән китабыннан бер өзек китерәсем килә: "С первых дней войны перед партийными организациями ставилась задача мобилизовать все материальные и духовные силы населения на разгром врага под девизом: "Все для фронта, все для победы!" Чтобы выполнить эту задачу надо было организованно вести полевые работы, обеспечить успешное выполнение государственных планов по всем показателям, обеспечить население бомбоубежищами, по настоящему организовать работу по всеобщему военному обучению; вести упорную работу по сбору и отправке теплых вещей фронтовикам, и средств в фонд обороны, перевести работу всех организаций на военный лад.

Колхозники колхоза "Кызыл көрәшче" (село Балыкла) обратились ко всем труженикам полей района. Обращение было опубликовано в газете "За высокий урожай" в номере за 22 июня 1942 года, где записано: "Страна переживает самые тяжелые дни. Красная Армия и труженики тыла делают все для приближения победы. Рабочие военных заводов работают на станках 18 часов. Учитывая сложившуюся обстановку мы берем на себя следующие обязательства: на комбайне в сутки убирать и обмолотить хлеба с площади не менее 25 га; собрать для Красной Армии и рабочих промышленных предприятий по 1 ц картофеля с каждого двора. Сбор теплых вещей завершить к 1 ноября. Там же в это время особо остро стоял вопрос о кадрах механизаторов. У нас в декабре 1941 г. на курсах трактористов при Балыклинской МТС, почти все обучаемые были девушки. В районе шел сбор денег на строительство самолета "Юный пионер" и строительство танковой колонны. За это пришло приветствие от И.В.Сталина.

*"За сбор и внесение на строительство танковой колонны "Куйбышевский колхозник" 1 млн. 345 тыс. рублей передайте от меня и Красной Армии привет. Спасибо всем колхозникам и колхозницам Камышлинского района".*

**И.Сталин.**



Все графы заполнять полностью

НАГРАДНОЙ ЛИСТ

1. Фамилия, имя и отчество ЗАЙНАГУТДИНОВ Зуфляр Анахметович
2. Звание Старший сержант 3. Должность, часть Командир орудия 13[illegible] стрелкового полка 72 стрелковой Павловской Краснознаменной дивизии
Представляется к ордену "СЛАВА ТРЕТЬЕЙ СТЕПЕНИ"
4. Год рождения 1923 5. Национальность Татарин 6. Партийность Кандидат ВКП/б/ с 1943 года
7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и в Отечественной войне (где и когда) Отечественная война с 1943 года
8. Имеет ли ранения и контузии в Отечественной войне Ранен 12.2.43 г. и 24.2.44 г
9. С какого времени в Красной Армии с 1943 года 10. Каким РВК призван Камышлинским РВК Куйбышевской области
11. Чем ранее награжден (за какие отличия) Не награжден
12. Постоянный домашний адрес представляемого к награждению и адрес его семьи

Шул язмаларда әйтелә, нормаларны арттырып үтәү гадәткә керә, халык тырышып эшли. Ә бит сугыш елларында кышлар ифрат суык була иде. Ишек яңаклары, тупсалары, тәрәзә төпләре катламланып бозлана иделәр. Тәрәзә пыялаларында төрле бизәкле фигуралар барлыкка килә иде. Болар безнең балачак һәм яшьлек чорының күренешләре, аларны кайсысын ишетеп, күбрәген үзебез күреп үстек.

1941-1942 нче елның кышында күп имән агачлары туңган. Берничә елдан соң Кротково лесничествосы кисәргә рөхсәт итте. Алдан аларны кисеп, "Сажин салып" кучалап өясең, ул урын Мукшы урманында, "Казанлы чишмә" янында. Өйгән кучаларны лесниклар килеп принимать иткәч, йә ат, йә үгез белән, дровник чанага төяп, авылга, йортка ташыйсың.

1941-1945 нче елларда Балыклыдан ике йөздән артык ир-ат, төп эшче крестьяннар сугышка китә. Бөтен эш хатын-кыз иңбашына ишелеп кала. Чәчү мәйданнары 1/3 гә кыскартыла. Хәтерлим әле, инәй мине, 8 яшьлекне, олау (фурман) башында торырга алып бара иде. Шунда күрә идем, Богырыслан юлы ягындагы кырларны, Урта кырны чүп үләне, каракура, әрем, сарут басып киткән иде. Менә шулай үсте безнең кебекләр, "Дети войны".

Сугышка алынган 230 кешедән 136 сы (60%) шул дәһшәтле

сугыш кырларында ятып калалар. Ил язмышы-ир язмышы, диелә бит. Ул сугышта һәлак булучыларның күбесенең баш очында йә казык кагылган, йә тишек солдат каскасы куелган. Ил тарихы да безнең йөздән артык авылдашлар каны белән язылган.

Менә алар, тапканнарымны язам:

Абдрафиков Абдрахман - 1920 г.р. Ст.сержант, погиб 05.09.43г. пос.Мосилево, Смоленской обл.

Абдрафиков Минәхмәт -1929 г.р. Сержант, пропал без вести.

Абзялилов Гайфулла - 1908 г.р. Рядовой, пропал без вести.

Аглиуллин Нигматулла - 1906 г.р. Рядовой, погиб 26.08.43 г. ст.Беспалов, Харьковск. обл.

Билалов Минаб - 1903 г.р.Рядовой, пропал без вести.

Аглиуллин Зәки -1903 г.р.Рядовой, погиб 25.03.42г.д.Борисов, Новгородск. обл.

Абсаттаров Вәли - 1907г.р. Пропал без вести.

Валеев М. - мәгълүмат юк.

Галлямов М.А. - мәгълүмат юк.

Аглиуллин Нәфигулла - 1923 г.р. Рядовой, погиб 13.10.43 г. Могилевская обл.

Аскаров Инсаф - 1923 г.р.Пропал без вести.

Ахметзянов Шакирзян - 1908 г.р.Старшина, погиб 19.03.43г дер.Дюки, Смоленск. обл.

Абсаттаров М. - мәгълүмат юк.

Ахметшин Гаделша - 1922 г.р. Пропал без вести.

Ангалышев Зәйнулла - 1910 г.р. Ст.Лейтенант, погиб 16.07.44г. дер.Коропель, Литва.

Ахметзянов Рахимзян - 1924 г.р.Рядовой, пропал без вести.

Вагазов Ахметгали - 1919 г.р. сержант, погиб 1941 г. под Тамбовым.

Валиахметов Насих - 1917 г.р. рядовой, погиб 25.03.44г. пос.Кр.Полянка, Могилев.обл.

Валеев Давлет - 1906г.р. Пропал без вести.

Галиуллин Г.Г. - мәгълүмат юк.

Галимов Х.Г. - мәгълүмат юк.

Габбазов Самигулла - 1911г.р.-пропал без вести.

Ахметзянов Минегалим - 1911 г.р. сержант, погиб, ноябрь 1941г.

Билалов Кыям Шарапович - 1909 г.р. старшина, погиб 19.09.43 г. х.Червона Долина, Дн.петр.обл.

Билалов Кашаф Ш. - 1907 г.р. рядовой, погиб 1943г.Тула.

Багаутдинов Минзаки - 1903г.р. рядовой, погиб, август 1942г.

Багаутдинов Гали - 1910г.р. рядовой, погиб, окт.1941г. под Смоленском.

Вахитов Ахат М. - пропал без вести.

Галимов Ибрагим Х. - 1901г.р. рядовой, погиб 1942г.

Гиматдинов Ибрагим Абунагимович - пропал без вести.

Галиев Юнес - 1909г.р. рядовой, погиб 09.08.43г. дер.Красногорск, Орловской обл.

Гаряев Хаматгали - 1901 г.р.рядовой, погиб1943г.

Галимов И. - мәгълүмат юк.

Гилязов Минахмет - 1909г.р. гв.Кр.арм-ц, погиб 28.09.42г. с.Хмелевка, Волгоград.обл.

Ганниев Минегалим - 1904г.р. рядовой, погиб окт.42г. с.Тетеревка, Прохор.р-н, Белгород.обл.

Гафуров Абдракип - 1904г.р.-пропал без вести.

Ганниев Абдулвали - 1903г.р.рядовой, погиб 06.03.42г.

Галлямов Гильмутдин - 1908 г.р.-пропал без вести.

Гиматдинов А. - мәгълүмат юк.

Забиров Наби - 1908 г.р. Ст.Лейтенант, погиб 20.02.43г.дер.Макарова, Ленингр.обл.

Зайников Н. - мәгълүмат юк.

Кадыров Сагир - 1901г.р.рядовой, погиб август 1942г.

Галиев Миргалим - 1913г.р., рядовой, погиб в октябре 1943г.

Галиев Саид - 1917г.р.-пропал без вести.

Галиев Шафик - рядовой, погиб 06.02.45г.

Гизетдинов М. - мәгълүмат юк.

Галлямов Гильмутдин - 1908 г.р. пропал без вести.

Кудряков Ахмет - 1897 г.р. погиб 06.05.44г.дер.Глинка, Витебск. обл.

Мустакимов Гайфутдин - 1923г.р., рядовой, погиб в декабре 1942г.

Мингалимов Г.Ш. - мәгълүмат юк.

Минибаев Абдулла - 1897 г.р.-пропал без вести.

Мустакимов А.Г. - мәгълүмат юк.

Насыров Насибулла - 1914г.р. рядовой, погиб 12.09.42г.д.Синявка, Ленингр.обл.

Сафин Абдулхак - 1925 г.р. пропал без вести.

Насыров Гариф - 1905г.р. рядовой, погиб в мае 1943г.

Сафиуллин Шәйхулла - 1905г.р.рядов. Умер от ран 15.05.44г.дер.Вилянет.Румыния.

Садыков З.Г. - мәгълүмат юк.

Сулейманов Зуфар - 1919г.р.рядовой, погиб 19.09.44 г.с.Алиоша, Пенсильвания.

Сагиров Насибулла - 1909г.р. пропал без вести.

Сафин Шафик - 1906г.р. рядовой, погиб в июле 1942г.

Каримов Ахмадулла - 1897г.р. рядовой, погиб 08.04.42г. дер.Фомина, Калужск.обл.

Усманов С.З. - мәгълүмат юк.

Усманов М.А - мәгълүмат юк.

Усманов Хасанша - 1914г.р. погиб 03.12.42г. дер.Дерзовка, Воронежской обл.

Усманов А.З. - мәгълүмат юк.

Усманов Фатих - 1903г.р.рядовой, погиб в апреле 1942г.

Усманов С.З. - мәгълүмат юк.

Фатхутдинов М.М. - мәгълүмат юк.

Фатхутдинов Б.М. - мәгълүмат юк.

Фарукшин Исмагил - 1925 г.р.рядовой, погиб в ноябре 1942г. Миллер р-н, Ростов.обл.

Фархутдинов С.Х. - мәгълүмат юк.

Фархутдинов Шәйхелислам - 1925г.р.рядовой, умер от ран 25.02.44г. д.Бор.Псковской обл.

Фаткуллин Гали - 1903г.р. рядовой, погиб в марте 1942г.

Фархутдинов Сахаб - 1914г.р.серж.погиб 22.04.45г.с.Хабын, Чехословакия.

Халимов Абдулахат - 1914г.р. рядовой, погиб в январе 1942г.

Халимов Минегали - 1911г.р. рядовой, погиб в марте 1942г.

Харисов Г.К. - мәгълүмат юк.

Хисматов Миннулла - 1908г.р. рядовой, умер от ран 15.08.43г. Смоленская обл.

Хабибуллин Юсуп - 1911г.р.старшина. Погиб 22.09.42г. пос.Киршик.Ленинград.обл.

Сафиуллин Самигулла - 1912 г.р.пропал без вести.

Хакимов Ганни - 1901г.р. рядовой, погиб 11.02.42г.

Хамзин Халик - 1923г.р.рядовой, погиб 10.10.42г. г.Волгоград.

Хайрутдинов Г.Х. - мәгълүмат юк.

Хайруллин Н.А. - мәгълүмат юк.

Шайдуллин Минахмет - 1920г.р. лейтенант, погиб 07.09.41г. село Туровка, Киевской обл.

Шайдуллин Ахметвали - 1921 г.р. пропал без вести.

Шарапов Г.С. - мәгълүмат юк.

Шарапов Кашаф - 1906 г.р. пропал без вести.

Шангаряев Минегали - 1901г.р. рядовой, погиб 25.08.43г.х.Хазарка, Харьков.обл.

Шайхутдинов Нуртдин - 1907 г.р.-пропал без вести.

Шабаев Инсаф - 1919г.р. пропал без вести

Шамсутдинов Ризатдин - 1911г.р. ефрейтор, погиб 16.03.44г. д.Кадраш, Смоленск.обл.

Шайдуллин Минахмет - 1920г.р. пропал без вести.

Шарапов Г.С. - мәгълүмат юк.

Шайдуллин Хайбрахим - 1911г.р. рядовой, погиб 30.11.44г. в плену.

Шайдуллин Зуфар - 1913г.р. пропал без вести.

Юсупов Сахаб - 1918г.р. мл.сержант, погиб 29.08.42г. х.Затон, Ростовск.обл.

Юсупов Кыям - 1921 г.р. пропал без вести. (Калыма?)

Якупов Лукман - 1924 г.р.рядовой, погиб 16.07.43г. с.Поворот, Курской обл.

Ягфаров Шаяхмет - 1903г.р. рядовой, погиб в марте 1942г.

Ягфаров Ризатдин - 1916г.р.-рядовой, погиб в марте 1942г.

Ягудин Абдрахман - 1921 г.р.рядовой, погиб в феврале 1942г.

Вахитов Хамит М. - 1926 г.р.рядовой, умер от ран, похоронен в Литве.

Билалов Минегали - 1903 г.р.-пропал без вести.

Фардеев Минвали - 1924 г.р. рядовой, погиб 10.07.43г. х.Веселый, Прохор р-н, Белгород.обл.

Фардеев Хази М. - 1900 г.р. рядовой, погиб в январе 1942г.

Шамсутдинов Нургали - 1902г.р., рядовой, погиб 14.10.43г. похоронен д.Кожемяки, Витебск.обл.

Тагын язылмаган кешеләр бар диләр, тик хәзер мин аларны таба алмыйм, әлегә алар миңа билгеле түгел. Ә “Книга Памяти” китабында, һәлак булучыларның кайсы авылдан икәнлекләре әйтелмәгән, анда барысы да юк та сыман.

Балалар! Бәлки бабагыз Билалов Кыям Шарапович турында, ул кайларда шул канкойгыч сугышта батырларча катнашып, кайда, кайчан илебез иреге өчен, безнең өчен баш куйганын төгәл белмисездер. Менә, укып карагыз. Аның, Ленинград, Волхов фронтларыннан, ранение алганчы язган хатлары байтак



*К.Ш. Билалов (Украинада һәлак булган 1943 елны) һәм С.Ф. Билалов. Госпиталь. Иваново шәһәре. 1942 ел.*

иде, кызганычка, сакланмаганнар. Луга ягында яраланып, Иваново шәһәрендә бугай алты ай госпитальдә дәвалана. Анда чакта әле Билалов Сахаб абзый белән очрашалар. Госпитальдән соң, ул Көньякка, Курск дугасына җибәрелә. Сугыш тарихыннан билгеле булганча, 1943 нче елның җәендә анда коточкыч каты бәрелешләр була. Менә аннан язган хатларыннан бер өзек: "...Унтугызынчы атаканы отбивать иттек, ә мин бүген дә исән әле...". Димәк, бабагыз, сугышларның иң авыр, иң көчле барган җирләрендә катнашкан. Чөнки, Ленинград, Волхов, Курск дугасында сугышның хәл иткеч урыннары. Авылдашларның да бит һәлак булган урыннары, күпчелек Ленинград, Смоленск, Сталинград, Курск...

Менә бер, бик саргайган кәгазьдәге хаты сакланган, аны күчереп язам: "...Рәшит, улым, мин кайта алмасам минем турыда язарлар дошман белән яхшы сугышты дип. 1942-1943 г.г.һәм тагын да мин катырак сугышачакмын. Вафат булсам-ватаным өчен. Кулыгызны кысып- атагыз Кыям. 26 август, 1943 нче ел".

*"Здравствуйте семья Билалова Кыяма Шараповича. Мария! Сообщаю, что ваш муж и отец Ваших детей Кыям Шарапович*

*вчера, т.е. 19.09.43 г. в 15.00 убит от вражеской бомбардировки. Похоронили мы его в хуторе Червона Долина Днепропетровской области (ул.Павлоградский район, Р.Б.) Вечная ему слава павшему сражавшись с немецко-фашистскими войсками за свою Родину, за Вас и за весь советский народ, который еще находится в ярме немецкого фашизма. На этом кончаю, досвидания. С приветом бывший товарищ Кыяма Шараповича Кобзарец Василий Ф. с которым служили вместе с ноября 1942г. Я житель Красной Глинки*".

Менә бер ай эчендә ике хат, ә эчтәлекләре...

Мин, үсә төшкәч, Красная Глинкага барган идем, анда сельсоветларында да, төрле җирдә дә сорашкаладым, Кобзарецны белүчене тапмадым. Хәзер инде, за Великую Родину сугышып, күпме халык вафат булган җирләрдә, чит ил хасил булды. Электә дә, ахры бик зур булмаган дуслык, дошманлыкка әйләнеп бара...

Равия сеңелемнең кызы Венера Украинада яшәгәч, бабасының үлгән җиренә ел саен диярлек бара. Ул каберлектә 123 кеше күмелгән. Өсләрендә һәйкәл тора икән.

Ә исәннәрне, исән кайтканнарны туган җирләрендә ни көтә?

Сугышта булып кайтканнарның күбесендә орден, медальләр бар иде. Тик алар хәзергә эзсез югалды дип була. Исемдә калганнардан менә шулар: Абсаттаров Абугали, Ахметов Газиз, Ахметшин Мәрданша, Насыров Вәли, Зәйнегетдинов Зөфәр (ике Орден Славы), Багаутдинов Бәкер, Сулейманов Исмәгыйль (ике Орден Славы), Галимов Сәләй (Орден Славы), Фатхутдинов Сираҗның да орденнары бар иде. Ә Багаув Кыям, шулай ук күп орденлы, Германиядә бер шәһәрдә комендант булып торган, ул аннан трофейный мотоцикл да алып кайткан иде. Ә инде бу каһәр сугыш утында югалганнар, үлеп калганнар, хәбәрсез югалганнарны, исемсез, кардәшлек каберлекләрендә күмелгәннәрне Аллаһы Тәгалә үзе генә белә.

Алдарак, сугыштан исән-имин өйләренә әйләнеп кайткан каһарманнарны ни көтә, дигән идем. Авылда тоташ таркаулык, ачлык, ялангачлык. Малларга кормы җитмәүдән, арык атларны, сыерларны корсак астыннан ике җирдән аркан үткәреп, түбә өрлегенә асып, күтәртеп куялар иде. Яз көне яңарак ябылган салам башлы өйләрдән, башка корылмалардан салам төшереп, малларга ашаталар иде. Атлар, билгеле инде ачлыктан, тоташ

корчаңгы, тимерәү белән авырыйлар иде. Ч.Д.күпере янында, ике станок-сарай эшләнгән иде. Атларны муены тикле, башларын гына махсус тишекләрдән тышка чыгарып, шунда ябалар иде һәм эчке ягында агу, күкерт яндырып, аларны дәвалыйлар иде, бугай. Мин боларга үзем катнашканым булмады, шуннан узып йөргәндә күргәннәрдән язам.

Сугыш барганда колхоздан сугышка атларны да алганнар. Сугыштан соң колхозда эшләр башкарырга атлар җитмәгәч, үгезләрне җигәргә өйрәтәләр. Ст.Выселкада, хохолларда ярмо җиксәләр, бездә, Балыклыда ат камытын кире якка әйләндереп ясаган иделәр. Чөнки бит, үгез йөкне җилкә белән тарта, ә ат күкерәк белән. Ашлык ташу, тракторларга су, ягулык илтү, урманга утынга, печән, салам ташу барысы да үгезләр белән, тол хатын-кызлар, малайлар, сугыштан гарипләнеп кайткан ирләр башкара иде.

Колхозны, колхозчыларны, немец фашистларын тар-мар итеп кайткан җиңүчеләрне кайгыртучы, кызыксынучы юк иде. Игенче ачтан интегә. Яз көне черек бәрәңге, балтырган, кузгалак җыеп, умач уып, коры аш, алабута кушып пешергән ипи ашап, тамак туйдырырга мәҗбүр булды безнең Балыклы халкы. Хәер, безнеке генә түгел. Дөрес, сыер асрый алганнарда сөт, катык, әзрәк май да була иде. Аларына да хөкүмәт налог сала, тапшырырга задание бирелә. Колхозыбыз “Кызыл көрәшче” бик көчсез хәлгә калган була. Халыкның бар карап торганы-үз хуҗалыгы һәм шул бер сыеры. Күмәк хуҗалыктан бернидә алырга юк, киресенчә, халык үз хуҗалыгыннан тапканнарны дәүләткә тапшыра, налог түли. Авыл хуҗалары, (Билгеле, өстән фәрман алып), агитаторларны кушып, аларның күбесе укытучылар, башка актив-депутатлар, йорт саен йөреп, үгетләп, заемга яздыралар, бер түләрсез әле диеп. Ә озак та үтми, шулар ук, йорт саен йөреп, инде заемыгызны түләгез дип, кыстап, хәтта өркетеп даулап йөриләр. Ул чордагы законнар бик кырыс иде. Халык нишләсен, заем каһәреннән котылыйм дип, соңгы кәҗәсен базарда сата, ит налогын түлим дип-сарыгын илтә, йә булмаса бозавын заготскотка илтеп тапшыра, бозау зуррак булса, бер-ике кеше бергә кушыла. Ярый, заготскот үзебездә булгач, илтәргә якын иде. Хет шунысына канәгать.

Кырчылык бригадирлары, Гәти абзый, Мирхаҗи абзый һ.б. халыкны иртүк эшкә дәшеп йөргәндә, яз башында: “Быелгы

уңыштан һәр трудоднигә өч килодан бүләбез", дип вәгъдә итәләр, көз көне икмәк бүлгәндә ул өч кило, кинәт мке-өч йөз граммга әйләнә иде.

Халык ат урынына (ул бит юк, ә бригадтан бирмиләр, тыела), күп вакытта бәләкәй арба, күбрәк "Уф Алла" дип билгеле, ә Балыклыда "Темпы" дип йөртелгән әйберне тартты, кулланды. "Темпы"ны, безнең тапкыр мишәрләр, "темпы индустриализации, темпы коллективизации" диеп модага кергән чордан алып кушканнардыр инде. Ул "темпы"ны безнең заман балалар, үсмерләр бик яхшы беләләр, хәтерлиләр. Чөнки аны утын, үлән төяп, байтак тартырга туры килде. Без тартсак та, ичмаса исән-сау идек, ә күпме сугыштан гарипләнеп, инвалид булып кайткан абзыйлар, шул каһәрне тарттылар! Кайчакта, аларга Шарлама чокырының үрен тартышып менәргә ярдәм иткәли идек. Ә лесниклар шул "темпы" белән корыган ботак-чатакны төяп тартып кайтканда, җәфалыйлар иде, балтаңны алалар, сүгәләр, яныйлар иде. Урманнан малларга үләнне "темпы"га булса да чапсаң, йә урак белән урсаң, лесниклар, Михайловканыкы-Алексотка, ә Седякованыкы- Гришка Коновалов тотып чалгыңны, йә урагыңны ала торганнар иде. Янәсе, урманга кермә. Дөрес, аларның да төрлесе бар иде. Мисал, Кисенде урманы артында (Кротково лесничествосы) корыган өрәңге агачларын кисеп йөргәндә яныбызга лесник формасына киенгән кешеләр килеп чыктылар. Безнең котыбыз алынды. Ә алар: "Малайлар, не нарушайте!", диделәр дә, китеп бардылар. Менә аларга, рәхмәттән башка ни әйтәсең?!

Хәзер, белмим халык әзәйгәнгәме, үлән агач төпләрендә генә түгел, урман тугайларында, аланлыкларда да чабылмый, урманда егылган, корыган агачлар аунап, череп ята, күп җирдә каракура-бурьян үсә. Алдарак, исән-имин калган сугыш батырларын кайткач ни көтә? дигән сөальгә җавапны кыскача булса да, тасвирлап бирдем. Әлбәттә, аларның күз алдына килгән авыл әхвәле шатланырлык булмый. Шулай булса да, халык төшенкелеккә бирелмичә, барча авырлыкларны бердәм ерып чыга, тормышны әкренләп җайга салалар.

## Барыбызда хезмәт иттек



Рәшит. Севастополь



Кыям Билалов (сулдан).
Оренбург. 1933 ел




Рөстәм. Казахстан




Марсель. Оренбург



*Феодосия шәһәре*



*Р.К.Билалов с шваброй. 1955 ел*



*Керченск проливы*



9 май 1975 ел

9 май 1980 ел





*Ветераннар. 9 май 1985 ел*




*Ветераннар. 9 май 1995 ел*

## Тол хатыннар һәм сугыш ятимнәре

Тол хатыннар, сугыш ятимнәре турында язарга тотынгач, бүгенге дөньяның, хәлиткеч мәсьәләләре элеккеләрнекеннән әллә ни аерылып тормый төсле. Шулай бит, тарихка борылып карасаң, Беренче Бөтендөнья сугышында безнең Шарап бабай вафат була, ә Кәфия әби өч бала белән тол кала. Шул өч баланың берсе минем әтәй - Кыям Шарапович. Әбигә ул балаларны атасыз үстерергә җинел булмагандыр, чөнки әтәй малай чакта М. Ганькино чувашларында ялланып көтү көтә.

Беренче Бөтендөнья сугышында калган ятимнәр белән хәзерге икенче Бөтендөнья сугышы ятимнәренең һәм тол хатыннарының өметләре белән мөмкинлекләре арасында каршылык артты төсле, чөнки мин үзем сугыш ятиме, ә инәй тол хатын. Авылда яшәү мәсьәләсен беренче чиратта үзеңнең сыерың булу чишә иде.

Тол хатыннар һәм сугыш ятимнәре күбесенчә колхозда эшләп, тиздән коммунизм була дип картайдылар, күбесе теге дөньяга китте. Җитмәсә бүгенге дөнья XXI гасыр башлары төрле каршылыкларның бәхәс кыры булып тора. Барысы да үзенекен тәкъдим итә. Бүгенге тормыш кайсы ягы беләндер сәүдәгә охшаш. Ләкин боларын инде әле исән булган тол хатыннар һәм картайган сугыш ятимнәре чишә алмас, боларны аларның онык, оныкчыклары чишәчәк дияргә генә кала. Ә безнең хөкүмәт бу сугыш аркасында ятим калган балалар турында онытты. Ә бит балачакта атасызлар белән аталылыр арасында аерма бик зур иде. Ярар, кәгазьдә булса да аларның исемнәрен үзебезнең авыл тарихы битләренә кертеп калыйк.

Сугыш аркасында тол калган хатыннар

Сәфиуллина Хәтирә
Билалова Мәрьям
Усманова Мөнәвәрә
Галимова Миннеруй
Абсаттарова Фәхригаләм
Ангалышева Мәрьям
Кәримова Мәшүдә
Әхмәдуллина
Шәйхетдинова Хисал
Шәмсетдинова Ганҗиян
Шәмсетдинова Фәхирә
Усманова Гатифә
Халимова Мәрзия
Закирова Сәрбия
Шангаряева Рәхимә
Әхмәдуллина Минебанат
Әхмәдуллина
Харисова Җәүһәр
Билалова Зәрига
Фаттахова Зәлифә

Әхмәтҗанова Зәкия
Вәлиева Бәдәр
Габбазова
Гиляҗева Гаширә
Минебаева
Насыйрова Камәрия
Сәгыйрова Факия
Шарапова Минкамал
Йосыпова Гөлчирә
Халимова Гыйлмбанат
Вәлиева Бәдәр
Фәтхетдинова Фахирә
Шәнгәряева
Насыйрова Әлемхани
Ганниева Хәдичә
Вәлиева Бәдрия
Галиева Мөгелсем
Галимова Камәр

Сугыш ятимнәре

Сәфиуллин Шәйхлислам
Сәфиуллин Шәмсулла
Сәфиуллин Шәрифулла
Билалов Рәшит
Билалова Равия
Билалов Рөстәм
Усманов Мөхәммәт
Усманов Мөхәммәтвәли
Усманова Мәдинә
Усманов Закир
Кәримов Гайфи
Кәримов Зәки
Кәримова Хәмидә
Кәримова Сәлимә
Әхмәдуллина Нурлыбанат
Әхмәдуллин Зәйнулла
Әхмәдуллина Зәйтүнә
Шәйхетдинов Рәшит
Шәйхетдинова Гакилә
Шәйхетдинова Наилә
Шәмсетдинов Касыйм
Шәмсетдинов Рөстәм
Шәмсетдинова Гайшә
Шәмсетдинов Миргалим
Шәмсетдинова Минасма
Шәмсетдинов Наил
Шәмсетдинова Назимә
Шәмсетдинова Зәкия
Усманов Нәсих
Усманова Кәримә
Халимов Равил
Халимова Рушания
Шангаряев Минсәхи
Шангаряева Әкълимә
Шангаряева Хәтимә
Әхмәдуллина Гөлчирә
Харисов Хәбибнур
Харисов Кыям
Харисова Мәрьям
Фәттахов Гамил
Фәттахова Назыймә
Фәттахова Гайшә
Шарапов Гомәр
Әхмәтҗанов Рәшит
Әхмәтҗанов Галимҗан
Абдрафыйков Абдулхак
Абдрафыйкова Разия
Абсаттарова Минасма
Абсаттарова Тәлига
Абсаттарова Ләбибә
Ангалышев Хәйдәр
Вәлиев Рәис
Габбазов Гариф
Гыйляҗев Гата

Гыйляҗева Мөхтәрәмә
Гыйляҗев Гайил
Минебаев Әхсән
Минебаева Мөкәтдимә
Насыйров Рәфкат
Сәгыйров Нәфигулла
Сатарова Хәзимә
Хакимов Әхәт
Хакимова Рәшидә
Шарапов Рәшит
Шарапов Минәксән
Шарапов Бисмах
Шарапова Минасма
Йосыпова Әнисә
Йосыпова Рушания
Галимов Дамир
Галимова Зәйтүнә
Галимова Роза
Халимов Хазивәли
Халимов Надергали
Халимова Рафыйка
Галимов Минзәки
Галимов Рәис
Валиев Зөфәр
Фәтхетдинов Җават
Фәтхетдинова Наилә
Шангаряев Әмир
Шангаряев Өлкәр
Насыйрова Мәрьям
Насыйрова Рәйсә
Ганниева Мәрьям
Усманов Мәсхүт
Усманов Сәгыйт
Халимова Нурлыбанат
Кәримов Нурулла

## Сугышта һәм төрле конфликтларда катнашкан авылдашлар

Туксанынчы елларда Ватан сугышында үлеп калучылар, сугышта катнашып исән калучылар турында “Книга Памяти” ләр чыгарылды. Мин дә шулардан авылдашларны һәм Карамалларны күчереп язарга булдым. Менә алар:

Абсаттаров Абугали Х.-1916-1998г.г.-ст.сержант
Аглиуллин Хамидулла-1899-1993г.г.-рядовой
Ангалышев Газизнур-1912-2000г.г.-рядовой
Ангалышев Идрис-1916-1968г.г.-рядовой
Аскаров Низам-1914-1972г.г.-рядовой
Ахметов Газиз С.-1906-1990г.г.-ст.лейтенант
Ахметшин Марданша М.-1912-1993г.г.-капитан
Багаутдинов Бакер М.-1916-1996г.г.-мл.сержант
Багаутдинов Кыям-1912-1992 г.г.-ст.лейтенант
Бадретдинов Габдерәүф-1914-1965 г.г.-рядовой
Билалов Сахаб-1910-1979г.г.-старшина
Билалов Рәхим Ф.-1914-1958г.г-рядовой
Валиахметов Нәбиулла С.-1915-1968г.г.-рядовой

Вафин Вахит А.-1906-1955г.г.-рядовой
Галиев Маннан М.-1907-1977г.г.-рядовой
Галимов Миргабизян-1912-1971г.г.-рядовой
Галимов Исмагиль З.-1908-1993г.г.-рядовой
Галимов Садри Ш.-1907-1954г.г.-рядовой
Ганниев Ганни Х.-1904-1989г.г.-рядовой
Галялиев Минаб Г.-1901-1966г.г.-рядовой
Ганниев Абдулла-1898-1980г.г.-рядовой
Гафуров Инсаф М.-1910-1964г.г.-рядовой
Гафуров Насих А.-1911-1984 г.г.-рядовой
Ганниев Салимзян
Давлетшин Мубаракша Б.1903-1953 г.г.-рядовой
Зайнагутдинов Зуфар Я.-1923-1996г.г.-лейтенант
Закиров Минахмет А.-1906-1982г.г.-рядовой
Каримов Заки А.-1926-1985г.г.-рядовой
Каримов Гайфи А.
Каримов Нурый М.-1914-1998г.г.-сержант
Коняев Ильяс М.-1914-1988г.г.-рядовой
Кутузов Сагит С.-1916-1978г.г.-рядовой
Мавлютов Заки З.-1916-1943г.г.-ст.сержант
Махмутов Шакирзян -1914-1976г.г. рядовой
Мингалимов Минахмет-1911-1964г.г.-рядовой
Мусин Фатих Вагаз.-1911-1963г.г.-лейтенант
Мусин Фатих Хафиз.-1905-1969г.г.-рядовой
Мустафин Закир. Мубин.-1907-1984г.г.-рядовой
Насыров Вали З.-1907-1984г.г.-рядовой
Насыров Гиляз М.-1914-1969 г.г. лейтенант
Рахматуллин Ахметсаяр-1903-1961 г.г.
Сагдеев Гиляз С.-1902-1972г.г.-рядовой
Сагдеев Инсаф С.-1905-1966г.г. рядовой
Сагдеев Миневали С. -1894-1966г.г.
Сагдеев Рафай Ризатд.-1923-1998г.г.-рядовой
Садыков Шамиль-1907-1975г.г.-рядовой
Сайфутдинов Сираз Х.-1915-1990г.г.-сержант
Саяров Кашаф С.-1902-1986г.г-рядовой
Сиразетдинов Гайфи С.-1925-1990г.г.
Сулейманов Исмагиль-1922-1983г.г.-сержант
Сулейманов Мотыгулла-1916-1990г.г.-рядовой.
Сулейманов Фаляхутдин С.-1905-1990г.г-рядовой.

Садыков Әнәс З.
Тухватуллин Гати Аг.-1908-1996г.г.-рядовой
Усманов Насих Г.-1923-1985 г.г.-ст.сержант
Фардеев Вали Ш.-1924-1982г.г.-рядовой
Фардеев Минахмет Ш.
Фархутдинов Хабибулла К.-1920-1996г.г.-рядовой
Фаттахов Аксан Х.-1893-1953 г.г.-сержант
Фаттахов Хамит А.-1921-1953г.г.-ст.лейтенант
Фатхутдинов Сираз М.-1919-1984г.г-мл.лейтенант
Хайруллин Шарифулла Х.-1898-1980г.г.-рядовой
Халимов Мирхази Ш.-1908-1966г.г.-рядовой
Хасанов Мубин Х.-1908-1991г.г.-рядовой
Хасанов Нагим Х.-1910-1993г.г.-рядовой
Хисамиев Сахаб Б.-1910-1993г.г.-рядовой
Хисматов Сагидулла-1903-1985г.г.-ефрейтор
Хусаинов Мирга Х.-1925-1973г.г.-рядовой
Шагиев Заки А.-1910-1996г.г.-рядовой
Шайдуллин Хабиб Ак.-1912-1995г.г.-рядовой
Шайдуллин Шарифулла Б.-1901-1973г.г.-старшина
Шаймарданов Гата Х.-1909-1983г.г.-рядовой
Шайхутдинов Инсаф Ш. ?-1958г.-рядовой.
Шайхутдинов Сахаб.Ш.-1896-1980г.г.-рядовой
Шакуров Абдрахим А. 1909-1983г.г-рядовой
Шамсутдинов Ибениамин Ш.-1919-1995г.г.
Шангаряев Аксан Г.-1923-1988 г.г. сержант
Шарапов Галялетдин Ф.-1909-1991г.г.-рядовой
Юсупов Гильмутдин Ф.-1917-1985г.г.-рядовой
Юсупов Назах Ф.-1915-1992г.г.-рядовой
Юсупов Сабир С.-1925-1962г.г-старшина
Юсупов Кыям-Польша
Ягфаров Нуриахм.-1908-1995г.г.-рядовой
Вагазов Ахат М.В.-1928-2008г.г.-старшина
Фарукшин Хабиб И.
Сафин Юсуп В.
Сагдеев Минахмет
Галимов Саляй
Сайфутдинов Бисмах
Нигматуллин Нагимулла
Мавлютов Заки

Хасанов Назах
Халимов Нурсахи
Галялиев Мутавафик-борьба с бандитами. Прибалтика.
Вахитов Хамит

### Афган сугышында катнашкан авылдашлар

Вагазов Руслан Ахатович
Шакуров Фанис М.
Сулейманов Рашит Б.

### Кубада-Карибский кризиста катнашучы

Шарапов Ильшат Карямович

### Чечнядә


Юсупов Рәсил М.
Рахматуллин Рафаэль
Юсупов Руслан
Насыров Ильдар
Борисов Евгений
Хусаинов Рамиль
Каюмов Марат
Шайхутдинов Ильшат
Сулейманов Рамиль
Фархутдинов

### Сербия-Косово да, контракт буенча

Гиззатуллин Рөстәм
Усманов Руслан

### Кытай-Даманский утравында

Мингазов Марат Сиразович -медаль белән бүләкләнгән



*Ваһаҗев Руслан Әхәт улы*

### Гражданнар сугышында катнашканнар

Губайдуллин Галим
Аглиуллин Хамидулла (өч сугыш ветераны)
Шайхутдинов Сахаб

### Урта Азиядә басмачлар белән сугышучылар

Ахметов Газиз Султанович
Губайдуллин Галим

### Беренче Бөтендөнья сугышында катнашучылар

Адһамов Сараҗ, Хусаинов Харис, Вагазов Минвәли, Вахитов Закир, Билалов Шарап-һәлак.

Һәр авылдаш, кайсы сугышта катнашкан булса да, ул иң беренче нәүбәттә илен, туган җирен, үз гаиләсен саклау уе белән, дошманга каршы торган. Алар безнең хәтер төбендә даими саклануга лаек һәм сакланырга тиешләр. Хәзерге тормыш шартлары үткәнгә караганда күпкә күпкә яхшыргангамы, яшь буынга олылар тарафыннан үткәнебезне, тарихыбызны өйрәнеп, ата-бабаларыбызны тирән ихтирам һәм хөрмәт белән хәтерләүнең яшәү өчен иң мөһим сыйфат икәнен күңелләренә сеңдерә белмәгәнгәме, теләмәгәнгәме, кешеләрнең акылы, зиһене, хәтере саега бара сымак. Битарафлык, үзебезнең, һәм бигрәк тә балаларыбызның, оныкларыбызның киләчәгенә гамьсез караш күңелләребезгә, миләребезгә сеңде. Бүгенгене генә кайгыртып яшибез, тук тормыштан ваемсызлык баса түгелме? Барча фронтовикларның, сугыш кырларында баш куйганнарның, исән кайтып та, тәннәрендә алып кайткан осколоклардан, җәрәхәтләрдән, авырулардан озакламый авылда үлүчеләрнең, һәм соңгы вакытларда туган бәрелешләрдә катнашкан авылдашларның балалары, оныклары, оныкчыклары бар. Аларның күңеленә, зиһененә һәр гаилә, мәктәп сеңдерәме борынгы тамырларыбыз белән кызыксынуны, ата-бабаларыбызның яшәү шартлары, нинди кыенлыклар кичереп, дәһшәтле афәт, сугышларда үзләрен аямыйча, бүгенге тыныч тормыш, милләтебез, телебез өчен җаннарын фида кылган авылдашларның каһарманлыгын даим истә тотып, баш иеп, лаеклы ихтирам, патриотик-илгәсәклек хисен тәрбияләү җитәрлек дәрәҗәдәме? Болар барысы да бит безнең тарихыбыз, ә үткән тарихны онытырга һич тә ярамый!

Авылда сугышка алынмаган өлкән яшьтәге ир-ат, йә бронь белән калып эшләүчеләр, хатын-кызлар, хәтта үсмер бала-чагалар (кайберәүләр башлангыч мәктәпне дә төгәлли алмыйча) һәр тарафта тырыш, фидакарь хезмәт күрсәттеләр, фронтовиклар кебек үк Совет Армиясенә немец-фашистларны җиңүдә зур өлеш керттеләр. Хәтеремдә, безнең инәй, Мәрьям, “ташкай” Мөнәвәрә апа, Минкамал апа һәм башка толлар, кышкы суыкта, өсләрендә сырган “куфайка” һәм “кожан” билдән бау белән буган, аякта чабата йә кат-кат астына ямау салган иске киез итек, тамак ярым ач килеш ерак кырдагы салам эскертенә көрәк белән юл арчып, ат чанасына бастырыклап салам төяп, көн саен корчаңгы атлар белән фермага салам, печән ташыганнары.

Ә унбиш-уналты яшьлек үсмер малайлар, шулай ук кыш буена атлар белән чанага 70-80 килолы капчыклар төяп, арлы-бирле киемнән, мәчет-клубта ясалган “глубинкадагы” ашлыкны обоз белән, яннарына бер-ике олырак кеше биреп, Кләүле стансасына ташыйлар иде, ә язга таба кирегә, Кляүледән колхозга орлык китерә иделәр, чөнки хөкүмәт орлыклык калдырмыйча, бар ашлыкны тапшырта иде. Җәйләрдә шулар ук, ат белән такта әрҗәле арбада комбайннар бункерыннан бөртекне, кырда ук чирәмне яндырып ясалган токларга иртә төнгә чаклы ташып тора иделәр, бодай бөртеген учакта куырып ашап, кырда ук, арбалар астында кунып, кул арасына керердәй кыз балаларны да даими эшкә җиктеләр: токта ашлык чистарту, кырда чүп утау, сушилкада чи ашлык киптерү һ.б.

Монда колхоз эшендә генә түгел, ә Волганың уң якларына барып окоплар казуларда, урманнар кисүдә (швырок) авылдашлар бик нык катнашты, сугыштан соң аларның күбесен медальләр белән бүләкләделәр.

Ә бронь белән сугышка алынмыйча МТС карамагында калдырылган ирләр, гомумән МТСта эшләүчеләр бик кырыс дисциплинага, хәрби тәртипкә буйсынып эшләделәр. Политотдел, НКВДның даими күзәтүе, контроле астында, биш минутка эшкә соңга калу, яисә йөкләнгән заданиеңне берәр сәбәп белән үтәмәсәң, җинаять санала һәм төрмә яный. Мәсәлән, 1942-1943 нче елның кышында комбайнер Вахитов Вәли абзый Камышлы кырында эскерт янында комбайны белән көлтә суктыра, Камышлы хатыннары белән. Комбайнның мотордан төп барабанга тоташтырылган ремень, искергәнлектән тоташ өзелә. Яңасы юк, чара бер: ялгау. Вәли абзый ярдәмчесе белән каешның өзек очларын тишкеч (бородок) ярдәмендә тишеп, пластинкалар куеп, болтлар белән ялгаудан бушамыйлар. Эш тора. НКВД вәкиле көн дә килеп, тикшереп тора. Бер-ике көн шулай азаплангач, ашлык рәтле сугылмый. НКВД иптәш килеп, абзыйны вредитель, диеп, наган белән төбәп, Камышлыга алып китеп яба. Өч көн ябып тоткач, райком, райисполком яклавы, юллавы белән, катгый кисәтү ясап, абзыйны чыгарып, янә эшенә кайтаралар.

Ә гомумән, сугыш чорына эләккән, әтиләре сугыш кырларында ятып калган ятимнәр, әле физик яктан ныгып җитмичә авыр эшкә җигелгән “Сугыш балалары” хөкүмәт тарафыннан искә алынмыйлар, тарихи документларда алар турында сүз юк диярлек, немецларның концлагерендә булган балалар турында азмы-күпме кайгырту сизелә, ә тылдагы балалар да концлагерь шартларына якын мөхиттә булдылар бит. Кызганычка, ул чорның авыл

тормышы язма документларда язылмаган, фоторәсемнәрдә теркәлмәгән, булганнары да җыелмаган, сакланмаган. Җиңү бәйрәмнәрендә төшерелгән фотрәсемнәрдә генә, сугыш елларында яңа җитлегеп килгән яшь-җилкенчәкләрнең шактый олыгайган кыяфәтләрен (исәннәренең) күрергә була, аларга бит инде 70-80 яшь! Бик күпләре инде бакыйлыкта.

Сугышлардан нык гарипләнеп кайтучылар байтак иде. Мәсәлән, әле мин белгәне, 1914-1918 нче еллардагы сугыштан бер аяксыз кайткан Хусаинов Харис бабай бар иде. Гомер буе агач аяк киеп йөреде, мәрхүм. Хөкүмәт тә яхшы. Аны сугышка патша хөкүмәте мобилизовать итеп алса да, ул шул Рәсәй өчен сугышып, аягын өздереп кайткан ич! Ә империалистик сугыш инвалиды дип, пенсия түләмиләр.

Авылда байтак иде кулсызлар да, күзсезләр дә бар иде. Соңгы Ватан сугышыннан кайткан Юсупов Гильмутдин, Сулейманов Мотыгулла берәр аяксыз, Гафуров Насих, Хисамиев Сахаб-берәр кулсыз иделәр. Күзсезләр дә, җимерек битлеләр дә, нык контузия ителгәннәр дә булды. Мәсәлән, Бәдретдинов Габдерәүф абзый. Тәннәрендә, йөрәк яннарында тимер ярчык-осколок йөртүчеләр, мәсәлән, Зайнагутдинов Зөфәр абзый һәм башка төрле яралылар да авылыбызда булды, мәсәлән Шангараев Әксән абыйның аягының сеңере өзек иде, сугыштан соң, әле шул килеш колхозда эшләп йөреде.

Сугыш вакытында бер Сабкай Нәбие дигән кеше Олы Урманда да, Карамал башында да күренгәләгән, ахыры, дезиртир булган, качып йөрегән. Төнлә авылга килеп, халыкның сарыкларын урлап китеп суйган, кар базларына төшкәләгән дияләр иде. Кайбер кешеләр ялгызы урманга барырга курка булганнар, Сабкай Нәбие килеп чыгар дип. Соңыннан ни булганы, кая киткәне билгесез.

Менә, ниһаять, тарихи язмамның сугышларга, аларның авыл халкына күпме бәла, зыян китерүләренә багышланган бүлекне, үзем күреп белгәннәремне, ишеткәннәремне, төрле документлардан укыганнарымны шунда туплап, мөмкин кадәр тулырак итәргә тырышып, йөз пронцент төгәллекне дәгъваламыйча, тәмамлыйм.

Белмәссең, бәлки шушы язмалар авылдашларыбызның гаиләләрендә ата-бабаларының тарихы белән кызыксынырга бер этәреш булыр. Яшьрәк, дәртлерәк җанатарлар, эзтабарлар үсеп чыгар һәм тагын яңа чыганаклар, материаллар табып өстәрләр, тулыландырырлар дигән өметтә калам.

# Авылда төрле елларда булган хәлләр

Авылыбыз тарихына кереп калган төрле вакыйгалар, фаҗигале хәлләр, ярым көлкеле, ярым аяныч эпизодлар бихисап. Алдарак әйткәнемчә, кыш көне бездә кар күбрәк ява, көчле бураннар еш була. Шундый өермәле, ачы бураннарга безнең авылда "Йосып буран" дип әйтәләр. Ишетүем буенча, 1928 нче елның март башында Йосып бабай Байтуган авылындагы тегермәннән кайтканда шундый буранда адашкан. Аты батып кала, икенче көнне табалар, исән була бугай, ә үзе юлны югалтып, Заря тауларын, Камышлы юлларын уратып йөреп, Акбур тавына табарак, хәлсезләнеп, егылып үлә. Яз көне үзен кырда маллар саклаучылар табалар. 1958 нче елның февраль азагы, март башларында котырган буранда Камышлыдан Балыклыга кайтканда, Зайнаков Галимулла абыйның әнисе Мәшүдә әби, ә авылда табиб булып эшләүче Суркова Валентинаның сеңелесе Симәннән килешли адашып йөри-йөри, әлеге Акбур тавы тирәсендә хәлсезләнеп, туңып үләләр.

Илленче елларда, 6 нчы декабрьдә Похвистневода торучы бер Балыклы хатыны М.Ганькино янында адашып, туңып үлә. Мүкле күл янындагы бер кырга Чувайка диләр. Чуваш кызы Байтуганнан Степные Выселкага барганда адашып, туңып үлә.

Өй сыларга балчык алганда, балчык ишелеп төшеп, казучыларны басып имгәтә, үтерә. Төялгән ат олавындагы боргыч ычкынып китеп, бер кешене сугып үтерә. Ат арбасында утырып таудан төшкәндә, ат дулап китеп, бәрелеп үлүчеләр дә булган. Тракторлар, автомашиналар белән тапталып, кысылып үлүчеләр күп булды.

Ярмәк очында, авыл читендә иске тегермән бар иде. Анда тегермәнче Вафин Вахит абый эшләде. Тегермән ташы машинный залда урнаштырылган нефть двигателеннән шкифлар, ременьнәр ярдәмендә хәрәкаткә китерелә иде. 1955 нче елның март аенда, ничә еллар эшләгән тәҗрибәле кеше, ниндидер саксызлык белән, әйләнеп торган шкифлар янына якын килә һәм чыгып, тырпаеп торган деталь-шпонка плащ чабуын эләктерү сәбәпле, бер кулы киеме белән калак сөягеннән тартылып алына. Уллары Гәзнур һәм Рафаэль үзен ат белән Камышлы больницасына төшереп җиткергәнче җан бирә. Ә өзелгән кулын курку, каушау белән тегермәндә үк калдыралар, аны соңыннан барып алып кайталар. 1965 елда печән өмәсе вакытында, яшенле яңгыр чыгып ява

башлый. Будкалы машина эченә һәм астына  халык яңгырдан яшеренеп кереп кача. Шул вакытта яшен автомашинага ата, ә аста Шәмсетдинов Рөстәм машина мостына тотынып яткан була һәм яшен аның аша җиргә үтә, хушына китерә алмыйлар, үлә. Ә калганнары бераз чирләсәләр дә исән калалар.

1985 нче елның җәендә, уннан артык кешенең, көнаралаш диярлек абзарлары, иске МТМ складлары яндылар. Дөрес булса, бер пироман шулай яндырып, авыл халкын нык куркытып торды. Кешеләр йортларын чиратлап саклый башладылар.

Карамалда берәүнең келәтендә күселәр бик нык үрчиләр. Болар берсен тотып, бензинга батырып, тегенәргә ут төртәләр, янәсе күсе каты чинар, калганнары моны ишетеп, качачак. Ә күсе, ут төрткәч, хуҗаның кулыннан ычкына да, келәт астына, белгән җиренә кереп китә, келәт янып бетә. Күселәр дә билгеле, бетәләр.

Язган языйм инде тагы бер эпизод турында. 1946 нчы елны, ике- өч автомашина Камышлы тавыннан тузан туздырып килеп (элек юл Марга турыга зират яныннан менә иде) Олы урамдагы Билалов Фаттах (Зияй) бабайлар каршындагы сиртмәле кое янына туктадылар. Кузовларда тезелешеп утырган әсир Япон солдатлары иде. Сакчылар, алда да, артта да безнең солдатлар, мылтык тотып басып торалар. Машинадан төшеп коедан су алдылар, җәй көне бит, кайсылары эчкәндер, мөгаен. Ул Япон солдатларыннан Кисенде урманы артында, Тәрәгәлгә таба, зур делянка ясап, урман кистергәннәр иде. Берсе әле шунда үлеп тә калган. Миңа бер абзый ул урынны күрсәтеп, сөйләгән иде, менә Япон солдатының зираты, дип. Ул урын Коры елга чокырына таба, ягъни аны чыккач та. Ун-унбиш еллардан соң, ул делянкадан корыган имән төпләрен казып алып утынга ала идек. Эше күп тә, авыр да, ә кыш көне бик яхшы яна, җылыта. Утын турында тагын сүз. Урманнан зелпе (бересклет) тамырын байтак казыдык, аны кыйнап, кабыгын төшереп, киптереп, лесника тапшыра идек, ә ул аның өчен утын бирде. Ул зелпе тамырын резина җитештерүдә кулланалар икән.

Бәләкәй Каршы урман астындагы авыл суы- Балыклинка башланган урында 1953 нче елның көзендә, ЛЗС техникасы зур итеп бөя өеп, буа ясадылар. Шарламадагы буаны җитмешенче еллар башында колхоз рәисе Нигматуллин Х.Г ЧТЗ-С-80 тракторы белән будыртты. Бу буаларның икесендә дә, яз көне салкын суда көзән җыерудан яшьләр батып, һәлак булдылар. Шарламадагы буаны кыш көне кондызлармы, су

күсесе-ондатраларны ердылар. Кондызлар хәзер күбәйде, Шарлама башына таба үзләре бугаларын коралар.

Истә булганнардан тагын бер эпизод. 1975 нче елда Куйбышевтан обкомның беренче секретаре (хәзергечә-губернатор) В.П.Орлов фәкать шоферы белән икәү, безнең якларга килеп чыга. Кырлар буйлап ашлыкларны карап йөрегәч, Заготскот кырынадагы, тау битендә урнашкан сыерлар утарын күреп малларны карарга була. Ул вакытта сыер савучы кызлар, сыерларны төш вакытында да кул белән савалар иде. Ферманың яшь, тана сыерлары, бер унбишләп баш, үзләрен үзләре имә иделәр. Аларга, иммәсеннәр өчен, ферма мөдире, зоотехниклар җайланма, тышка тырпайтып вак кадаклар каккан ремень тубаллар кидергәннәр. Вәт кирәк бит шунда, Орлов карда киртәсенә сөялеп, малларга карап торганда, бер тана сыер яннарына ук килеп, бөгелеп үз-үзен имә башлый. В.П.Орлов: - Күп йөредем, күпне күрдем, ләкин мондый могҗизалы очракны күрмәдем, дигән, бу нинди порода, кайдан алдыгыз?- дип сораган. Шул көнне, төштән соң, Клявлинога КПСС райкомына киңәшмәгә җыйдылар. Барганда без, Орлов бу тана сыерлар турында сөйләр, безне шелтәләр дип уйлаган идек, ялгыштык. Ул аны борчыган башка мәсьәләләр турында күберәк сөйләде, чөнки корылыктан җирләр нык ярылган иде, шуңа ул ашлыклар турында күбрәк кайгырту белгертте. Аңа үз өлкәсендә шундый сыерлар булуы күңелле булмагандыр, бәлки. Алай да, алар турында сүз булды.

Ә үзебездә, колхозда, бозаулар да байтак үлгәләде, аяксыз сарыклар да булгалады. В.П.Орлов обком секретаре булган чорда эшләгән колхоз җитәкчеләренең, партсекретарьләрнең аның турында бердәм фикере: иң яхшы, төпле, мәгънәле, яхшы оештыручы, уңай мөнәсәбәтле, лаеклы абруйга ия җитәкче иде. Миннән генә килсә, аның исемен Куйбышев- Самара тарихына кертер идем.

"Зур" начальниклар килүе көтелсә, районнан мәҗбүр итеп, бер кирәкмәгән электр баганаларын агартып буяп йөредек. Ә юллар  начар, асфальт юк иде әле. Шул "Зур" начальниклар килгәндә районнан грейдер җибәреп, юлны кырдыралар иде. Колхоз грейдеры ватылды. Ә асфальт юл, Камышлы-Похвистнево, 80 нче елларда гына төзелде.

Тормышта төрле хәлләр бар иде. Мәктәп балалары пионерлагерьлар ясап, Әдекәй урманы янында, йә Салкын чишмә янында вагончиклар, палаткалар куеп, җәй көне айлар буе ял итеп

яттылар. Балалар мәктәптә күп иде, үзләренә күрә анда төрле уеннар, ярышлар уздырдылар. Алар белән бергә айлар буе укытучылары да шунда булдылар. Балалар булдырган кадәр колхоз кырларында эшлиләр, булышалар иде. Кыяр, кәбестә, бер елны яңа үсемлек куузику үстереп маташтык үзләре белән. Эшләгән эшләре өчен вакытына карата акчасын да яхшы гына алдылар.

Искә алган электр баганалары күпчелек чәчелә торган кырлар аша атлыйлар. Кырны эшкәрткәндә техника аларны читләтеп уза. Богырыслан юлы буендагы кырда, сеялкалар чәчми калдырган багана төпләренә кул белән чәчәргә дип, Билалов Сахаб абзый белән Фаттахов Мәҗит абыйның җигелгән атларына яхшы орлык- агуланган бодай төяп җибәрдек. Бер атна-ун көннән барып карасам, багана төпләрендә бодайлар рәтләп чыкмаган, чөнки чәчелмәгән. Тегеләрдән сорыйм: нигә чәчкәнегез чыкмаган, дип. Алар, авызларын ерып, без орлыкны ерагырак та, тирәнерәк тә чәчтек шул диләр. Алар икән бодайны М.Ганькинога илтеп самогонга алыштырган булып чыкты.

Язсаң авылда кызык кына вакыйгалар күп булды. Менә берсе. Колхозда эшли торган халыкны гомүм тукландыру өчен даими рәвештә мал суя иделәр. Бер көнне мал суючылар янына килеп, "Яврәй" Сәрвәр апа болардан: -Сыерыгызның башын сатмыйсызмы?-ди. Тегеләр: - Бер савыт, сиңа баш, диләр. Савыт инде, билгеле, бер шешә аракы. Теге апа "Савыт" алып килгәнче, сыер башыннан телен төбеннән үк кисеп алалар. Сәрвәр апа өйдә карый, ә башның теле юк, анда "сыерчык" оясы гына калган. Яңадан суючылар янына барып: -Сахаб, сыерның теле нигә юк?-дип сорагач, Сәрвәр апага Сахаб абзый: -Аның теле булса, кем суяр иде, дип җавап бирә.

Балыклыда зур су юк дибез, дөресе дә шулай. Ә менә Алишаның коры елгасында дүрт тонналы буш автомашина ГАЗ-53 Б су белән акты, дөресрәге, әйләнеп чокырга төшкән иде. Бу сиксәненче еллар азагы иде. Яз. Чулпан каршындагы кырда бодай чәчәбез. Клявлинонық, Сельхозтехника берләшмәсеннән алып кына кайткан, өр-яңа, госномерлары да юк килеш, машинада төяп торучы Каримов Гайфи абзый кузовтагы орлыкны сеялкаларга салып бетерә. Шофер яңадан орлыкка кайтырга ашыга, чөнки түбәтәй кадәрле генә бер болыт чыккан иде. Мин "Жигули" белән кайтып киттем, ә болар әкрен генә чокырга төшәләр, тик чыгып җитә алмыйлар. Камышлы кыры ягыннан (Алиша

башыннан) су ташкыны машинаны агызып, астарак су казыган чокырга илтеп, әйләндереп төшерә. Машина шоферы, яшь, таза кеше машинадан сикереп өлгерә, ә Гәйфи абзый олы пенсионер, су ташкынында, Седяковога чаклы диярлек агып төшә. Анда чокыр киңәеп җәелә, агым күрәсең әкеренәя һәм Гәйфи абзый, үләннәргә тотына- тотына, ярга чыгып, соркалар оясы өстенә килеп утыра. Икенче машинада шофер Әнәс Хамзин була. Яңгырда чәчү агрегаты туктый, алар югарыдан бу мөшкел хәлне күреп торалар. Әнәс барып, чирәм өстеннән хәлсез Гәйфи абзыйны алып, машинасына утыртып, Камышлы больницасына илтә. Абзыйның авызы, борыны, колакларына чаклы пычырак, ләм белән тулган, киемнәре карарлык түгел, пычракка баткан була. Больницада: - Нәрсә булды?-дип сорыйлар. Ә Әнәс, туктагыз, әзрәк рәткә кергәч, ул үзе сөйләр, дигән. Чөнки, Гәйфи абзый сөйләршергә бик ярата иде. Олы ук булса да, таза кеше булып чыкты. Әле бу хәлдән соң да, озак кына яшәде. Ә теге машинаны өр-яңа килеш списать иттеләр, запчастькә диделәр, чөнки чокырга әйләнеп, нык имгәнгән иде, торгызырлык булмаган. Ә Камышлыда, Ходайның рәхмәте, ул көнне яңгыр таммаган да!

Андый коймa яңгырлар булгалый шул. Кайвакытта көтүләр Тиләгәзедә, аның аргы ягында, Мутаукада була, ә анда күперләр юк. Шундый каты яңгырлар булганда, көтү кайтканда сарыклар, бәрәннәр дә аккалады.

Тагы бер фаҗигалы вакыйга турында язып китәргә кирәктер. Җәй көнне дә адашып була икән. Хәзер ул хәлгә ун еллап вакыт узды инде. Зарига апа (җиңги, чөнки әтәйнең абыйсы Кашаф абзый хатыны, Даутова), Багаутдин бабай кызы булган. 80 яше байтак узган көенә Олы урман ягына, җиләк җыярга дип китә, әмма кире кайтмый, юк та юк. Бөтен авылыбыз белән, яше, олысы, балалар Чокыр бүләк, Олы урман, Әдекәйдән өч көн эзләдек. Тик әби юк, табылмады, югалды. Берничә елдан Тәрәгәл башына таба, Зур тугайдан ары агач төбеннән М. Ганькино көтүчесе сөякләрен таба. Похвистневога хәбәр итәләр, милиция килеп тикшерә. Судмедэксперт тикшерүләр үткәргәч, ул мәетне әби икәнлеген раслый. Әллә чирләп китеп, олы кеше бит, әллә адашып, кире якка, еракка китеп, Тәрәгәл башына таба узып, кайта алмыйча үлгән. Хәзер инде аңа теләгебез бер: урыны оҗмахта булсын.

Менә тагын бәйрәмнәр, Сабан туйлары белән бәйле бер факт турында. Җитмешенче еллар башы, Сабан туе бәйрәменә колхоз

халык күңелен күтәрер өчен бүләк рәвешендә, Башкортстан артистларын чакырды. Кибетләр эшли, һәр нәрсә бар, эчемлекләргә кадәр. Башкортларның концертлары яхшы гына булды. Халык матур гына ял итә. Шунда кунак артистларыбыз да тик тормаган күрәмсең, бераз кызып алганнар. Гадәттәгечә, артистлар белән безнең Балыклы мишәрләре нидер бүлә алмаганнар, ыгы-зыгы купкан. Шул буталышта башкорт егетләренең (Башкортстаннан булгач башкорт дим инде, ә алар чын Казан ягы татарлары иде) берсенең уң колагы киселәме, тешләп өзеләме, колак формасын югалта. Каршы Урманың акланын актарып эзләсәләр дә, ул колак очын таба алмадылар, ул куе үлән арасыннан таба аласыңмы? Ә ике мужик төрмәдә утырып кайтты, кайсы ныгырак гаепле булгандыр. Ул башкорт кешесе дә, әлбәттә Балыклыны оныта алмый торгандыр, чөнки колак дигән нәрсә яңадан үсми бит, ул тырнак түгел.

20 нче гасырның илленче елларының башы. Вахитов В.З. колхоз рәисе, ә Билалов С. аның урынбасары. Яз көне Сахаб абзый Рычково спирт заводыннан, бурычка колхоз кырында чәчү өчен орлыкка күпмедер бәрәңге алып кайтара. Менә җәй көне Рычково спирт заводыннан бер кеше Балыклыга, биргән бәрәңгеләрен эзләп килә. Колхоз идарәсендә шулай утыралар киңәшеп, ситуацияне ачыклап. Сахаб абзый, күзен дә йоммыйча, бу килгән вәкилгә, ул кул куеп алган кеше үлде бит, ди. Чыннан да шул елны җәй көне Каримов Ибрай абзый үлгән иде. Теге кеше әйтә:- Кара инде, ул кеше сезгә ничек охшаган иде, аның мыегы гына юк иде, ә үзе сезнең кебек смуглый иде, ди. Нишләргә, спирт заводында бүтән әйберне списать итеп була, ә бәрәңгене юк, аның спирты югалмый ди, бу. Сельсоветка кереп, Ибрай абзыйның үлгәненә справка алып, кайтып китә. Әлбәттә, ул Сахаб абзыйны таныган, ә үлгән кешегә бәрәңгене списать итеп була икән, справка булгач.

Сугыштан соңгы еллар. Ашлыкларны урып- җыю вакыты. Ул чакларда җитәкчеләр, башка активистлар катнашы белән төнге дежурстволар оештырыла иде. Шулай бер агай, кырдагы токтан берничә капчык ашлык арбасына салып, ат белән кич-кырын, мыштым гына кайтып килгәндә, хуҗалар тоталар үзен. Анда- монда хәбәр итмичә, ашлыгын Таллы урам башындагы Кырмалау Мифтахетдин дигән бабайга кертеп бушаттыралар. Ашлыкны колхоз рәисе ярдәмчесе Сахаб Билаловка колхоз идарәсенә алып төшәргә кушалар. Икенче көнне идарәдә Сахаб абзыйдан сорыйлар:

“Капчыклар белән ашлык кая, төшердеңме?”,- дип. Ә теге күзен дә йоммыйча әйтеп сала: -соң бит ике капчыкны сиңа, колхоз рәисенә төртеп күрсәтә, ике капчыкны - сиңа, ди сельсовет рәисенә, берсен - сиңа, партоешма секретаренә, төшереп капка төпләрегезгә куйдым, хатыннарыгыздан сорагыз, алып куйганнардыр, ди. Ә чынында ул ашлыкны төнлә Синьковкага озата.

Хәзер язачагым бөтенләй үк Балыклы авылы тарихына кагылмаса да, языйм әле, чөнки үзем шул сферада кайнашып алган кеше.

Агроном булып эшләгәндә мине бер период колхоз профсоюз оешмасының председателе итеп сайлаганнар иде. Профсоюз район комитетында яхшы таныш, ипле генә иптәшләр эшли. Колхозчы профсоюз әгъзаләреннән, минем ярдәмчем Асия Сәгдеева взносларны даими җыеп, отчет биреп тордык. Үзебездә калган акчасына мәктәп балаларына ике баян алып бирдек, спорт инвентарьләре алырга ярдәм иттек. Акчасы булгач, ел саен отчет җыелышларыннан соң “бәйрәмнәр” ясадык, теләкләре булгач, үзләренең акчалары бит. Байтак кына колхозчыларны Кавказ ягына да, Серноводскига, Кинель-Черкассның “Колос”ына да дәваланырга, ял итәргә курорт, санаторийларга җибәрдек, чит илләргә дә баргаладылар. Менә бер көнне КПСС райкомына чакырдылар. Залда утырабыз. Райкомның беренче секретаре И.Д.Кочкин елмая-елмая, путевкалар биреп, курорт-санаторийларга кешеләрегезне җибәргәндә, киемнәрен карабрак озатыгыз, ди. Эш болай булган икән. Кочкинны обком секретаре Куйбышевка дәшеп алган да, безгә сөйләгәнен әйткән.

Болгариядә безнең туристлар, Варна да ял итәләр икән. Кара диңгездә су коеналар. Безнең Клявлинодан ары Ключ авылының А фамилияле председателе дә су коенырга уйлаган. Көн кызу, ә тегенең өстендә күрәсең плавки, йә трусы да булмаган. Ул озак уйлап та, шикләнеп тә тормыйча, ап- ак кальсоннан суга кереп киткән, ә Германиянең “Штерн” журналының хәбәрчесе моны фотога төшереп, журналларында “Карагыз, Советлар Союзының кооператив председателе куроттта” дип язып чыгарган. Ул журнал Брежневка җитә, анысы Орловка, кемне җибәрәсез, нигә илне хурлыкка калдырасыз, путевкага акча табылган, ә трусикка җитмәгән, ди. Хәер, Союз вакытында путевка бәясенең, мин белгәнчә, 15 процентын гына түлиләр иде. Балыклыда, әйтә алмыйм, без санаторийга китүчеләрнең киемнәрен карап җибәрдек дип, әмма ял итеп кайткан кешеләребез турында начар сүз, киная ишетмәдек. Ял итүчеләр фәкать рәхмәт кенә әйтттеләр.

# Гаиләләр кору

***Бу теманы да кузгатырга кирәктер ахрысы. Өйләнү, тормыш кору ул бөтен җирдә бар.***

Тик төрле җирдә төрлечә башкарыла, һәр милләттә, һәр төбәктә үзенчәлекле йолалар белән уздырыла. Әлбәттә, өйләнүнең төп вакыйгасы- туйны уздыру колачы, беренче чиратта, кесәңнең калынлыгына карый. Егет белән кыз һәм ике якның әти-әниләре бергә килешеп, ризалык булса, алар инде үзләренең матди хәлләреннән чыгып, туй хәстәрен күрәләр. Ә инде, ниндедер сәбәпләр аркасында, тулы ризалык булмаган очракта, өйләнүнең башка төр мисаллары да Балыклыда булган һәм бар иде. Әгәр кыз белән егет өйләнешүләренә каршылык очратсалар, йә туйлар кузгатырлык матди мөмкинлек сай булса, кыз егеткә үзенең ризалыгы белән, "ябышып чыгу", дигән, гомумән татарда һәм авылыбызда да шактый таралган хәл бар иде. Ә инде егет ошатып йөргән кыз бергә кушылырга катгый риза булмый икән, ул кайчакта, ярым җинаятьле ысул, кызны ирексез "урлау"га тәвәккәллек иткән. Мондый эш, әлбәттә, киләчәк уртак тормыш өчен кыенлыклар, хәтта бәхетсезлек, фаҗига тудыруы да мөмкин була. Шулай да Балыклыда "кыз урлау" очраклары булган. Хәер, кайчагында, кыз урлауны оештырган егет дуслары белән көлкеле хәлгә калганнары да булгалаган. Кыз ягы, күрәсең сизенеп, сагаеп торганнар һәм теге урларга җыенучы егетләрне йорт тирәсендә шәйләгәч, берәр әбиме, йә исә башка олырак, чаярак хатын-кызмы, урланачак кыз киемнәренә киенеп йортка чыга һәм... урлана, караңгыда ашыгу белән "урлаучылар" "кызны" эләктереп алып китәләр, ә бераздан, эш ачыклангач, хурлыкка калуларын аңлыйлар.

Безне? анабыз, Мәрьям атабыз Кыямга "ябышып" чыккан булган. Мин моны, бала чакта, аларның, хатын-кызларның үз-ара көлешеп сөйләшүләреннән шунда ара-тирә колакка чалынганнардан язам. Әтәйнең дә атасы, Шарап бабай, инәйнең дә атасы-Закир бабай инде дөньяда булмыйлар. Ул "Ябышу", күрәсең гади генә булган, кыз егет белән сөйләшеп, егеткә ияреп каршы тыкырыктан гына, киткән, яңа тормыш корырга... Мин туып, әзерәк сөйләшә, аңлый башлагач күрәмсең сораганмын, кызыксынганмын инде, миңа малай кешене коедан алалар, кызларны чишмәдән алып кайталар дип аңлатканнар.


ВОИНАМ ОДНОСЕЛЬЧАНАМ
ВЕЛИКОЙ











Ә үзем, укып кайтып колхозда эшли башлагач, өйләнергә ниятләдем һәм озак еллар дуслашып йөрегән кызым Мөкәтдимәне, эштә җигеп йөри торган җирән алаша атым белән возок чанага утырттым да, йолдызлы аяз төндә, шыгырдап торган карлы урамнардан өебезгә, яңа тормыш корырга алып кайттым. Безне бабай белән әби, капкаларына сөялеп, озатып калдылар. Ә инәй, Мөкәтдимәне өйгә алып кергәндә, бусагага мендәр ташлады. Бусы нинди йола булгандыр? Ул вакыт атеистик чор булса да, алдан бабайлар өендә мулла чакырып, безне инде никахлаштырганнар иде.

Ә иртән Рәшитнең өйләнгәне бөтен авылга таралган иде, әйтерсең кыңгыраулап төшердем.

Аннан соң авыл советы секретаре Сираҗ абый Фатхутдинов безнең өйләнешүебезне рәсми теркәп, (регистраация в журнале ЗАГСа) таныклык бирде. Минем яктан Вахитов Вәли абзый, Мөкәтдимә ягыннан - Ваһаҗев Хәмит абый шаһит булдылар. Әлбәттә, безгә әйтелгән тәбрик-котлаулар, теләкләр, нотыкларны, гадәт буенча, бер "савытны" бушатып, юдык.

Аннары бездә ике көн туй мәҗлесләре уздырылды, туганнар, авылдашлар байтак җыелып, кабат тәбрикләделәр, бүләкләделәр. Аракыбыз, каяндыр килеп чыккан "Ерофей Павлович" иде, кунакларга бик ошаган иде бугай, тик мин башка, андый Хабаров исеме белән аталган аракы бер дә күргәнем, очыратканым булмады.

Аллаһыга шөкер, бик матур, тыныч тормыш корып яшәдек, тәртипле, игелекле өч бала тәрбияләп үстердек. Өйләнеп кайтканда кыңгыраулар кыңгырамаса да, гаиләбездә зур тавыш, гауга, савыт-саба челпәрәмә ватышу бер дә булмады, без аны белмәдек.

Ә инде кызларыбыз, үсеп җитеп, белем алып, балигъ булгач, икесе дә бер-бер артлы Чулпан егетләренә соратып, никахлашып тормышка чыктылар. Илдә нәкъ "перестройка" чоры, аракы, азык-төлекнең бик дефицит чагы булса да, зур итеп туй озату мәҗлесләре, күп җиңел машиналар белән урам йөреп, клубта тантаналы регистрация уздырдык. Егетләр ягында да зур туйлар уздырдылар, сүз әйтергә юк.

Гомумән, XX нче гасырның җитмешенче, сиксәненче елларында авыл яшьләренең өйләнешеп, гаилә кору мәсьәләсенә авыл җәмгыяте, колхоз идарәсе, партоешма һәм авыл советы

зур әһәмият бирәләр иде. Яшьләр өйләнешкәч тә, ел саен диярлек яшь гаиләләрдә балалар тугач та, аларны авыл клубына җыеп, колхоз, совет, партком, профком исеменнән тәбрикләүләр, бәби исемнәре белән танышу, колхоз хәзерләгән бүләкләр тапшырып, бәләкәй генә табын оештырып, үзләренең дә алып килгән күчтәнәчләре белән бәйрәмнәр уздыргалый идек. Ә исемнәрен алдан ук ата-аналары, бәләкәй генә табын җыеп, мендәр өстенә яткырылган сабыйның колагына сайлап куелган исемне, чакырылган мулла, тиешле догаларны укып, кычкыра, ягъни исемне куша. Шулай итеп, балалар гомер дәфтәрләрен ачып җибәрәләр, ә ул тора-бара зур тормыш китабына әйләнә, аны инде тәкъдире буенча үзләре, мөстәкыйль тутыралар. Чөнки бит һәр кешенең ни күрәсе туганда ук, Аллаһы Тәгалә көдрәте белән маңгаена язылган була диләр. Ни генә булмасын, һәр кеше тормышы өчен, барлык кылган гамәлләре өчен дөньялыкта да, ахирәттә Тәңребез каршында да үзе җавап бирә диләр. Анысы инде башка тарих, аны алдан белә алмыйбыз һәм ул яхшырактыр да.

Хәзер сабыйлар заманча, махсус балалар тудыру йортында туалар һәм анага да балага да табиблар кирәкле ярдәмне күрсәтәләр. Элек бала тудыру, баланы кабул итү (акушерлык) шөгылен тәвәккәл холыклы, тәҗрибәле кендек әбиләре башкарган. Бала тугач ул кендеген кисә, беренче коендырып, биләүгә били. Аннары берничә көн бәбәй мунчасы ягалар, ананы да, әбине дә бәбәй ашлары белән сыйлыйлар, гадәттә ул бәлеш була. Кендек әбиләр гел хөрмәтләнеп торганнар. Мәсәлән минем кендек әбием Бисал әби булган. Безнең Кәфия әбине дә, олырак кешеләр хәзер дә, ул минем кендек әбием булган, диләр. Ул, әлбәттә җебегән шәхес түгел иде, бик гайрәтле (боевой) карчык иде мәрхүм, урыны оҗмах түрендә булсын!

Ир бала туган очракта сөннәтләү бурычы туа. Ул эшне авылда “бабачы” башкара иде. Гадәттә ул чараны бала бишектә чакта ук башкаралар. Ә берәр сәбәп белән соңгарылса, кайберәүләрне үскәч, урамда уйнап йөрегәндә, бабачы килгәч, эләктереп алгалыйлар иде.

# Динебез



*Мәүлид бәйрәме. 17 декабрь 2015 ел*

Кеше үлгәч, мәетне күмү, искә алу йоллары. Әгәр кеше ныгытып авырыса, җан тәслим кылуы көтелсә, анда инде мулланы, ул югында укымышлы кешене чакыралар. Ул Коръәннән Ясин сүрәсен укый, ягъни Ясин чыга. Бу йола барлык мөэминнәрдә дә бердер инде. Бу очракта тегеләй-болай дию юк, барыбыз да мәетне "теге дөньяга" бер төрле озатабыз. Бу ата-бабалардан калган бик тотырыклы йола. Кеше үлгәч, аны аерым караватка, кыйблага каратып яткыралар, өстенә ак җәймә, йөзенә ак яулык каплыйлар.

Мәетне бездә дә, белгәнемчә мөселманнар яшәгән башка төбәкләрдә дә, вафат булган көнендә үк күмәргә, җирләргә тырышалар, бик сирәк икенче көнне, йә читтән, еләктан кайтырга тиеш туганнарын, балаларын көтәсе булганда гына.

Күмәр алдыннан мәетне, ирләр-ирләрне, хатыннар хатын-кызларны, махсус ятакта юалар һәм 20 метрлап ак кәфенлеккә кәфенлиләр. Юасы суга хуш ис килеп торсын өчен мәтрүшкә пешереп кушалар.

Зиратта иртән иртүк, "бисмилләһир-рахманир-рахимим" әйтеп, бер төркем авылдаш ир-атлар кабер казый башлыйлар көнчыгыштан көнбатышка юнәлтеп. Тирәнлеге кеше тирәнлеклеге, буе-кеше буйлык казыла. Көньякка таба ләхет уялар.

Мәетне өйдән күтәреп чыгып, җеназага салалар, элек җеназага йомшагырак әйбер җәяләр, ә мәетнең өстенә юрган ябалар. Ул әйберләр барысы да мәчеттә сакла624налар. Кайберәүләр үзләренең әйберләрен кулланалар, ул берничек тә тыелмый. Җеназаны йорттан алып чыкканчы, мулла догаларны укый, өйдәге кешеләр шулай ук Коръәннән сүрәләр укыйлар, йорт хуҗалары, туганнары сәдака тараталар. Җеназаны зиратка кул өстендә күтәреп баралар, бик сирәк, юллар бозык, пычырак вакытта, йөк машинасында, барыбер җеназаны кулда тотып, алып баралар.

Зиратта, күмәр алдыннан, җыелган халык мулла артына тезелеп басалар, мулла ярдәмчесе, мәэзин: -Бу кеше нинди кеше, яхшы идеме, бурычлары юкмы?- дип халыктан сорый.

-Бурычы юк, яхшы иде, - диләр һәм мулла догасын укый. Мәетне аста, өч кеше сөлгеләр белән каршы ала. Ләхеткә салганда, мәетнең гәүдәсенең сул ягы өстәрәк булырга тиеш.

Элек ләхет төбенә камыш түшиләр иде, әле бервакыт келәмнәр җәя башлаганар иде, мулла ярамый дигәч, туктаттылар. Ләхет алынган җир тыгыз мәте балчыгыннан булса, ләхетне капларга элек бастырып куйган имән сөягечләргә юкә агачыннан каезлап алынган киң кабык куя иделәр, ә хәзер тактадан, йә буе белән, йә күберәк утыртып (90 см.) такта тезәләр. Ә кабер ләхете комлырак, ишелә торган булса (Карамалда), өске ягына тактадан түшәм ясыйлар, йә уртага тирәнерәк казып, кайберәүләр, мәсәлән Чулпанда, кирпеч белән әйләндереп, мәетне шунда яткырып, өстен каплыйлар.

Мәетне кабергә төшергәндәге сөлгеләр, аста каршы алучыларга бирелә. Сәдакалар йорт хуҗасыныкы 40 берәмлектән ким булырга тиеш түгел, ә туганнары - кем күпме бирә ала.

Зиратта булган кешеләр, бездә алар инде ир-атлар, шушы үлүченең урыны оҗмахта булсын, дип телиләр. Аннан соң халык мулла белән бергә дога кыла һәм кайтып китә. Ә хуҗалар, үлүченең туганнары, иптәшләре зиратта булган казу коралларын, күмү әйберләрен саклана торган урыннарына, мәчеткә җыештыралар. Мулла, мәет чыккан өйгә кайтып, яңадан тиешле догасын кыла. Бездә мәет чыккан өйдә өч көн ашамыйлар. Ашарга туганнары, күршеләре дәшә, ә бу өйне юалар, җыялар.

Өчендә, җидесендә кемнәр юышкан, мәетне җыештыруда ярдәм иткән иптәшләрен дәшеп, Корьән укыйлар, сәдакалар бирәләр һәм барча бу йорттан чыккан, дога көтеп ятучы әрвахлар рухына, исемнәрен әйтеп багышлыйлар. Зурырак мәҗлес кырыгында уздырыла һәм Корьән укыла. Хәзер, үлгәннән соң 51 көнен дә билгеләп китәләр.

Бер елдан соң, шулай ук мәҗлес җыеп, елын уздыралар, искә алып, Корьән укыталар. Элек кабер өстенә агачтан бура бурап куялар иде, ә хәзер тимердән эшләнгән рәшәткә куялар, металга исемен язалар. Борынгырак заманда зур ком ташына гарәп графикасы белән чокып исемен, туган- үлгән даталарын язып кую булган. Сирәк кенә андый ташлар зыярәтнең искерәк

ягында очырыйлар әле. Хәзер күберәк мрамор, граниттан һәйкәл кую китте.

Кайбер кешеләр кабер өстенә чәчәкләр, йә агач утырталар. Мөгаен чәчәк кенә утырту кулаерактыр, дөресерәктер, чөнки агач зураеп үсеп китеп, кабер өстен томалый, картаеп, ботаклары, яфраклары коелып каберне дә, тирә- ягын да чүпкә батыра.

Зират өстен мөмкин кадәр чистарталар анысы, гадәттә язгы якта. Элегерәк авыл советында ат бар вакытта, аңарга зират өстеннән чалгы белән печән чабалар иде. Зираттан өйгә печән чабу Балыклыда юк. Динебезне тоту ягына килсәк, безнең мишәрләр биш вакыт намазны фарыз дип саныйлар, иртәнге намаз-кояш чыкканчы, таң вакыты кергәч, өйлә намазы-төш вакытында, икенде намазы-кояш баерга җиткәч, тагын ахшам һәм ясигы намазлары. Боларны эшче кешегә

башкаруы кыен, бөтен эштә дә аңа шартлар да булмый. Ә инде олы яшьтәге пенсионерларга намазларны төгәл үтәргә мөмкинлек бар, өендәме, иң дөресе мәчеткә барып укылырга тиеш. Һәрхәлдә, без барыбыз да ислам динендә мөселманнар, Аллаһының барлыгына, берлегенә инанабыз.

Гает бәйрәмнәренең намазын да, мәҗлесләрен дә элек тә, хәзер дә даими башкарабыз, корбан чалу, корбан мәҗлесләре дә уздырыла. Уразаны башлыча өлкәнерәк кешеләр төгәл тоталар, тик барыбыз да түгел, бигерәк тә җәйгә туры килгәндә. Ә без кечерәк чакта ашау - эчү хәзергедәй мул булмаса да, иртән самовардан чәй эчеп, сәхәр ашап, хәле булганнары борайдан (полба) талкан ясап тамак туйдырып, күпчелеге уразаны тоталар иде. Хәтта, тәмәке тартучы тәмәкене, аракы кебек харамны да ай буена авызларына якын да китермиләр иде.

Элегерәк, динне чикләүләр аркасында, мәчетләр ябылгач, халык җомгага аерым өйләргә йөреп, ә гает намазларын йә зират өстендә, йә элеккеге мәчет (клуб) кырыенда укырга мәҗбүрләр иде. Хәзер атна саен мәчеткә җомга намазына яхшы гына йөри башладылар.

Иске Ярмәк авылында, 1790 нчы елда мәчет төзергә хөкүмәт рөхсәт биргәнче, халкы атна саен безгә, Балыклыга җомга намазына йөрегәннәр, бу турыда Ярмәк авылы тарихы китабында дәлилләп язылган.

Минем үземдә динебезгә, милли һәм дини йолаларыбызга ихтирам балачактан ук сеңгән һәм саклана. Дөрес, динне бөтен кагыйдәләрен китереп тотам дип әйтә алмыйм, чөнки догаларны, Коръән сүрәләрен белмим диярлек, яшьлектә өйрәнелмәгән, хәтер начарлангач өйрәнүе кыен. Минем кебекләр авылда, кызганычка, күбәүләр дип әйтсәм дә, ялгышмам.

Корьәнне русча тәрҗемәсен укып карадым, аңларга бик җиңел түгел. Хәзер, перестройкадан соң, авылда мулла булып, Фархетдинов Касыйм йөри. Тавышы да укырга килешкән, моңлы, коеп куйган, ак сакаллы, түгәрәк йөзле мулла булды.

Әйтерсең, гомере буена намазлык өстендә утырган, тәмле бәлеш төбе, төрле кыстырган пироглар гына ашап, сыйланып яшәгән диярсең. Эчкән эчемлекләре дә гел сөтле чәй генә булмагандыр, чөнки мин үзем дә аның чоры кешесе...

Ә аның догалары, вәгазьләре динебезгә туры киләме юкмыанысын инде бер Ходаебыз үзе белә. Тик хәзергә авылда аның кебек, дини яктан гәрәп телен белеп, эчтәлеген тирән аңлап, үтемле итеп халыкка җиткерерлек, гыйлемле кеше әлегә юк төсле.

Соңгы вакытта гарәпчә язган догаларны, Корьән сүрәләрен, яттан белүчеләр бар, күбәйде. Хәтта, Корьәнне тулысынча яттан белүчеләр бар, шундый бәйгеләр дә уздырыла. Аларга тырышлыклары өчен Аллаһының рәхмәте яусын!

Касыймның да тырышлыгы бар, догаларны, шактый озыннарын да яттан өйрәнгән, гарәпчә язылганны да укып маташтыра. Миндә ул юк, элек бик теләмәдем, хәзер соң.

Касыймның бер кире ягы да бар. Мәчеттәге радио аша тавышны көчәйтүче җайланманы эшләтми. Янәсе кемдер әйткән, пәйгәмбәрләр азанны манарага менеп кенә халыкны намазга чакырган, дип. Анда һәр мәхәлләдә мәчет тә булган. Асылда, пәйгамбәр азан әйтмәгән, аны Билал башкарган түгелме?

Ә бит намазга дәшеп, азан көчәйткеч аша әйтелсә, зур авылга ерагырак ишетелер, балалар азан тавышын ишетеп үсәр, баш миендә үзенең татарлыгы, мөэминлеге хакында артык бер сыр өстәлер иде. Ырымбур архивының 98 нче фондында, 1847нче елны Балыклыда мәчеткә 295 кеше прихожан йөриләр диелгән, димәк авыл халыкының чама белән яртысы, яше, карты (ир-ат) мәчеткә йөрегән, алар башларына аң керә башлагач та, азан тыңлап үскән.

Авылда бераз мулла булып Сафиуллин Шәрифулла да йөреде, тик авырып, тиз үлеп китте. Хәзер Ренат дигән егет бу эшкә яхшы гына алынды, белеме бар, мәдрәсәдә укып чыккан.

Яңа меңъеллык туып килгән чакларда, авылыбыз тарихына кагылган тулырак, өстәмә материал эзләргә авылдашларыбыз Ваһаҗев Халик Минвәли улы, Нигмәтуллин Хәбиб Гәйзулла улы, Шәрәфетдинов Рафик Борһан улы, колхоздан машина алып, Уфага юл тоттылар. Юл ерак булса да, исән-имин барып, мөфтият архивында безгә кирәкле, шактый бай һәм бик искермәгән тарихи истәлекләр табалар. Дөрес, архивларның кайсында да озак, басынкы эзләнү зарур, боларның андый мөмкинлеге булмыйча, асылда дини якка кагылган мәгълүматларны җыйнап кайттылар, дини хәлләрдән башка да материаллар булган, тик аларны карамаганнар. Менә, нәрсә тапканнарын теркәп китәм: “В селе Балыкла одна соборная мечеть построена в 1870 году Указный мулла Мусатьев Абдулла утвержден 24.08.1839 году”. Монда шуны әйтергә кирәк, утверждән 24.08.39 г., димәк мәчет алдан ук булган, чөнки, Никитин язмаларында - “в Балыкле работает одна магометанская церковь”-диелгән юллар бар. Бәлки ул мәчет янгандыр, чөнки бит, югарыда язылганча, Ярм?к халкы 1790 нчы елга кадәр Балыклыга җомга намазына йөрегән.

Тагын “...имамом зам. хатыйпом и мугаллимом 2-ой указный мулла Ахметшакур Абдуллин утверждән 30 октября 1885 года...” Бездә әле хәзер дә, берәү кая да булса барырга җиңел генә киенгән булса аңарга: -Син нәрсә Шәкүр мулла намазга барганча гына киендең?-диләр.

Тагын дәвамы: “Имамом хатыйпом и мугаллимом Идрис Исхаков утверждән 4 октября 1841 года, азанчы и учителем малолетних детей”.

Уфадан алып кайтылган кәгазьләрдән укыйбыз: “...мулла-1, хатыйп-2, азанчы-1. Мужчин-381 чел. Женщин-722 ???, наличных вообще-796 чел. Монда мөгаен хата бар, хатын-кызлар-415 булган.

Фонд № 295 опис 5 т.14 т.531 “О прошении гражданки Ахметмунировой Г. о расторжении брака. 1909г.

опис 5 т. 1811 Ахметкаримовой о расторжении брака 1903 г.

№ 6566 Султангуловой о растожнеии брака 1909 г.

1815 Сулеймановой о расторжении брака.

21813 О вторичном выходе замуж кр-ки Габделкаримовой 1898 г.

Оп 4 т.4 14412 дело о проверке знаний и правил магометанской религии

Губайдуллина А избранного муллой в мечеть с. Балыкла 19 апреля, 17 июня 1885 г.”

Дин, мәчет мәсьәләсенә кагылышлы вакыйгалардан, авылда булып узган бер гыйбрәтле, анекдот сыманырак, мисал китерәсем килә. Ватан сугышының соңгы елларында, авыл картлары җомгада сөйләшеп, сәдака акчаларыннан юл чыгымнарын да биреп Шамсутдинов Садыршәет бабайны Куйбышевка, облисполкомның дин эшләре белән шөгыльләнүче бүлегенә барып, Балыклыда яңадан мәчет ачарга рөхсәт сорарга җибәрәләр, бер мәртәбә генә дә түгел. Дөрес булса, бабай Куйбышевта каядыр, сәдака акчаларына типтереп алган да, бугай, (алайга хирыслыгы булган, күрәсең), бер нинди рөхсәт ала алмыйча, авылга кайта.

Кайткач, картлар җомгага җыелгач (намазга аерым өйләргә, күбесенчә Коняев Вәли абзыйларда), сорыйлар: -Ну мәчет буламы, Садыршәет?-дип. Ә бу: -Менә быел беренче рәттә (намазда) утыручылар Заря тау итәгенә (зиратка) таба, ә киләсе елга арттагыларга анда чират- юл ди. Сезгә нинди мәчет кирәк, облисполкомнан рөхсәт юк, дип җавап биргән.

Аның каравы, хәзер “кара карлар” гына түгел, ә кичәге комсомол, партия түрәләре, президентлар, өйрәнеп ятканнар диярсең, телевизор камералары алдында ничек итеп оста чукыналар. Бүген һәрбер тыкырык саен мәчет төзе, рөхсәт бар.

Тагын сыңар каен агачыбыз тау битендә. бар бит. Бер үзе ничә еллар, нык тузган, картайган булса да, һаман үсеп утыра. Бик кызу көннәрдә маллар да күләгәсендә ышыкланалар.

Ә ул агачның килеп чыгуы болай була. Безнең авылның бер татар кызы Седяково егетенә ияреп китә, кияүгә чыга. Ләкин балага узып, аны тапканда үлә. Туганнары кызның мәетен авылга алып кайталар, әмма аны урыс булды дип, мөселман зиратына күмдермиләр. Туганнарының җирләре шул якта була, алар җыенып, кызны шунда, тау битенә күмәләр һәм кайсыдыр кабер өстенә каен агачы утырта.

1921нче елгы ачлыкта авылдан агалы-энеле егетләр Седяковога (Сидәкәүгә) барып, хәер сорашып йөриләр. Бер очтан попның өенә дә керәләр, ул егетләргә нидер бирә һәм этлеге белән, боларга чукынырга тәкъдим итә, чукынсагыз мин сезгә тагын ризык бирәм, дип.

Егетләр ачлыктан нык интеккән булганнар, күрәмсең, ачтан үлгәнче дип, болар чукыналар.

Поп тагын күпме биргәндер, ә бу хәбәр авылга килеп җитә,

беренче шул поп тырышкандыр, мөгаен. Озакламый егетләр барыбер ачтан үләләр һәм болар хәзер мөселман түгел дип, зиратка түгел, ә Заря тавының битләвенә, келәтләр артынарак күмәләр. Аларның да кабер өсләрендә озак еллар каен агачы үсеп торды, аннары картаеп, череп ауды.

Әле революциягә кадәр хөкүмәт яхшы, нараттан бурап эшләнгән, типовой мәктәп авылга тәкъдим итә. Безнең авылдашлар, балаларыбызны урыс ясамыйбыз дип, бураны алмыйлар. Аны Седяковога урнаштыралар. Яхшы, биек, матур, зур тәрәзәле, калай башлы, биш-алты бүлмәле мәктәп иде. Мин белгәндә бер бүлмәсендә укытучы Салов тора иде.

Андый мәктәп Алешкинода да бар. Дин көчле булса да, бу хәл наданлыктан түгелме?

Революциягә кадәр, мәчетләр булгач, ир балаларны мәдрәсәләрдә (мәктәптә) Указлы мулла укыткан, ә кызларны остабикә граммотага өйрәткән. Сөйләүләр буенча, кайчакта, кыш көннәрендә мәктәп мичен ягар өчен, утынны укучылар өйләреннән пүләнләп ташыганнар. Руслар үзләренең сельская приходская школаны хөкүмәт исәбеннән тотканнар, ә татарга юк. Шәкертләрне тәрбияләү ысуллары бик кырыс, әмма нәтиҗәле булган. Тәртип бозучыларга, сабагын белмәгәннәргә бер почмакта үз корбаннарын көтеп тал чыбыгы бәйләме белән әзер торган.

Мөселман дигәннән Ульян һәм Илингин поселокларыннан чувашлар да Балыклыга мәчеткә йөрегәннәр, кызлары татарларга кияүгә чыккан. Минем үземә Ульян, Илингин чувашларыннан, без мөселманнар, Балыклыга мәчеткә йөри идек дигәннәре булды. Иске Ганькинода да мөселман, ислам динен кабул итүчеләр бар иде. Тик революция һәм аннан соңгы вакыйгалар чувашларда ислам дине ныгытып тамыр җәергә форсат бирмәде.

Хәзер дә бездә чуваш, рус, чечен-ингуш, мордва, украин, казах-кыргыз, төрек, хәтта әле поляк каннары кушылган гаиләләр бар. Мәсәлән Фәридә әби Фарукшина, ул төрек кызы.

1915нче елны анда сугыш барганда, Фәридә 18 яшьлек кыз Трабзон шәһәреннән ерак түгел кырда сарыклар көтә булган. Күрәсең, ул тирәдә инде рус солдатлары булган. Бер татар солдаты (сугышчысы) бу матур төрек кызын ошатып, үзе белән Рәсәйгә алып кайта, тик нишләптер, озакламый үлә. Фәридә

әби йөри-йөри безнең якларга килеп чыга һәм Ильяс бабай Фарукшинга кияүгә чыга. Фәридә әбинең туган ягында бик күп туганнары калган була.

Ул безгә сепаратка йөрегәндә, аларның исемнәре белән атап, сагынып сөйли торган иде. Ә Ильяс бабай белән матур гына тормыш корып, балалар үстереп, шактый яшәделәр. Язучы Хәсән Сарьяннар бездә, Балыклыда чакта Фәридә әбигә барганнар иде. Араларыннан берсе төрекчә сөйләшә белгән. Фәридә әби дә төрекчә сүз башлагач, елмаеп кына торган икән шул язучы. Авыл клубында аларга матур гына авыл халкы белән очрашу да уздырган идек. Аннан соң Камал апалар өендә озак кына "Бер ананың биш улы" дигән китап буенча әңгәмә алып барган идеек. Фәридә әбине, Россия гражданлыгы юк дип, сайлауларга да катнаштырмадылар.

Революция алдыннан Балыклыда манаралы өч мәчет була. Берсе хәзерге клуб - СДК янында иде, икенчесе - Таллы урамда, Латышлар очына борылган җирдә, өченчесе - Олы урамда, Даутов Баһаветдин бабай йорты каршында (Ваһаҗев Әхәт, Хәмит абыйлар...)

Бу мәчетне сүтмәгәннәр, ул янгын вакытында янган. Ә хәзерге мәчетне 1993нче елда, совет хезмәткәрләре яңа төзелгән бинага күчкәч, иске бинасы сельсовет балансыннан бушка, мәчеткә яраштерер өчен бирелә һәм аны авыл осталары Хасанов Нәзах, Каюмов Әхәт, Шәрәфетдинов Борһан яхшы, матур манара ясап, эчке бүлмәләрен үзгәртеп корып, мәчет итеп эшләп бетерделәр. Барча авыл халкыннан аларга зур рәхмәт!

Революция чоры, аннан соңгы вакытларда без белгән Балыклының указлы муллалары: Шиһабетдин Мигманов-Иске Ярмәк авылыннан Балыклыга килгән. Ул кысырык урамда яшәде, бик яхшы бабай иде. Икенчесе Таллы урамда яшәгән Зәки мулла Мостафин, аннан соң Саяр мулла улы Кәшиф мулла-мөэзин. Болардан тыш мулла булып Зәки Шагиев, Нәгыйм Мусин йөрделәр.

# Перестройка чоры

Перестройка дигән бик буталчык заманда, безнең колхозда да тырышып эшләү, күтәренкелек кими башлады. Аракы белән мавыгу да комачаулык иткәндер инде. Горбачевның билгеле карарыннан соң партҗыелышларда, аннан авыл халкы җыенында киңәшләшеп, Балыклыда аракыны сатмаска, саттырмаска карар кылдык. Ләкин күрше диярлек чуваш авылы Стюхинода саталар һәм бездән анда төрле техника агыла башлады. Ирләр, хатын-кызлар чираты йөзәрләгән метрга урамнарында сузылды. Кибетләрдә одеколоннар калмады. Дистәләп еллар халыкны бер чикләүсез, тыюсыз эчәргә өйрәткәч, Горбачевның карары белән генә, тиз генә аны эчүдән биздерү нияте утопия булып чыкты. Өстәвенә ул карар илнең экономикасына күпме зыян китерде, бердән хөкүмәт казнасына акча керү нык кими. Аракы, вино җитештерүне киметү, ул тармакта хезмәт иткән халыкны эшсез калдыра, авылларда, шәһәрләрдә халык эшеннән китеп, аракы эзләп йөрүдән хезмәт җитештерүчәнлеге түбәнәя, сәгатьләп аракы чиратында торып, авыруы тотып, йә кысылып, гауга кубып үлүчеләр, үтерешләр булды һ. б.

Аның каравы, хәзер яңадан аракы “диңгезендә” йөзәбез. Ельцин үзе аны яраткач, иркенлек ул яктан. Нинди генә исемлесе юк! Шәт барысын да бер ләгәннән, бер мичкәдән шешәләргә тутырып, төрле марка этикеткаларын ябыштырып саталардыр.

Ул гынамы, күп үрчегән төрле мошенниклар, жуликлар, эчәргә ярамаган, агулы спирт катнашкан, сыекчаларны аракы дип саталар, һәлак булучылар саны арта бара.

Егор Гайдарның “шоковая терапиясеннән” соң кибетләрдә, базарларда җаның теләгән нәрсә бар (күпчелеге чит илдән китерелгән), ашамлыкмы, кием-салыммы, тик акчасы гына, авыл кешесенең юк, анысы җитми. Чөнки крестьянның җитештергән продукциясе бик арзан, очсыз.

Ә шулай да, М.А. Сәгыйров беренче кат колхозда рәис булып эшли башлагач (1985ел) “перестройканың” башланып, “яңа мышление” куерып барган чагында, авылда байтак кына файдалы эшләр башкарылды. Медпункт, амбарлар янына яңа склад, токта асфальт җәелеп бете. Бу эшләр М.А. Каюмов эшләгән чорда башланган иде: кирпеч өйләр, фермада телятник, родильный бүлек белән төзелде.

Р.В. Фардеев вакытында Ярмәк урамында кирпеч өй, токта тагын бер яңа склад төзелде.

М.А. Сагиров яңа мехмастерскойны төзеп бетерә язды, аның чорында ук авылга Камышлы ГРСыннан газүткәргеч һәм ГРП төзелде. Мин ул вакытта парторг вазифасында идем. Татарстаннан (Әлмәт, Лениногорскидан) күпме трубалар, шәрәләрен дә, заводтан, ташып, Тольяттида изоляцияләттек. Свечной трубаларны склад башларына да түшәделәр, Степные Выселкадагы кардаларны шулар белән тоттылар, урамдагы газүткәргечләрнең терәкләренә шулар куелды.

Башта аларның метры 1 сум иде, ә аннары дүрткә менде. Итләр ягы кысырык чакта, сыерлар да акча булып китте, труба өчен, карабодай ярмалары да киткәләде. Ә акчасын, әйберен төгәл бирәләр иде.

Механизаторларга, ферма эшчеләренә, эшенең нәтиҗәсенә карата тиешле ашлыкны йорт саен тонналап, автомашина белән илтеп бушаттылар. Чәчкән печән гектарлап бүленде.

Чөнки хөкүмәт план тутырырга таләп итми башлады, план дигән төшенчә үзе бетте.

Ә Союзда КПСС җитәкчелегендә яшәгәндә болай түгел иде. Анда 2-4 центнер ашлык бирү булды. Ә хәзер үстергән ашлыкны алучы юк, диярлек, алса да, арзан бәягә.

Авыл халкына хәзер үз йортында чикләүсез мал тотарга мөмкин, күпмегә көчең җитә, анысы яхшы. Ә менә колхозда эш хакы илдәгегә, шәһәрләргә караганда күпкә түбән калды. Туксанынчы еллар башыннан, СССР ны таратканнан соң, Ельцин-Гайдар командасы барлык халыкны инде әйтелгәнчә ШОК-хәлендә, ягъни өнсез хәлдә калдырдылар. Имеш менә хәзер иркен сулыш алдык, шулай ук экономикада да иркен хәрәкәт итәчәкбез диделәр. Ә авылда акчасызлык хөкем сөрә, ул хәлдә ничек иркен хәрәкәт итеп була?

Минемчә ул иркенлек крестьян-колхозчы өчен түгел. Менә ике дистә артык еллар колхозлар диңгездәге рулен югалткан кораб кебек, нинди якларга экономик дулкын илтеп терәрен белми чайкалалар. Тик “Банкрот ярлары” һаман якыная төсле. Чөнки крестьянның җитештергән продукциясенең бәһасы бик арзан, ә техника, ягулык кыйммәтләнә тора, сарыфланган чыгымнарны да каплап булмый. Чагыштырыр өчен-1 тонна бензин 5-6 мең, ә бер тонна бодай-1,5 мең сум торалар.

Иркенәерсең болай!!! Колхозлар шулай бетеп баралар инде.

Дөрес аларны башка төрле хуҗалык итү формаларына күчерергә рөхсәт бар, телисез икән колхоз, СПК, фермерлык (КФК), ООО, йә үз хуҗалыгыңда гына яшәргә була. Тик теләсә нәрсә чәчегез, теләсә ничек эшләгез, бер нинди юнәлеш күрсәтү, бер нинди кызыксыну бер тарафтан да юк. Кысыр кайгыртучанлык. Хөррият! Акчасызлыкка. Менә шундый безнең яңа чор.

Әлбәттә, үзгәртеп кору-перестройка кирәктер иде. Торгынлык билгеләре бар иде авыл хуҗалыгында да, башка тармакларда да. Тик бездәгечә, азагын алдан аек зиһен белән уйламыйча, пырдымсыз рәвештә дәүләтне таратып, авыр сугыштан соң, ничәмә еллар титаник көч куеп төзекләндерелгән ил хуҗалыгын пыран-заран китереп түгел. Тик бездән, халыктан, бигерәк тә авыл халкыннан, мәрәсез амбицияле, тәкәббер, власть сөючән, сәнәктән көрәк булган адәмгә ияргән төрле ялагай түрәләр, илне кайсы кыйблага юнәлтергә дип сорап тормадылар.

Нәтиҗәсен күреп яшибез. Безнең колхозда җирләр һәр кешегә пайга (кәгазьдә) 10 нар гектар бүленеп бирелде. Шулардан 7 гектардан артыгырак сөрелә торган җир. Тик бу чын мәгънәсендә фикция булып чыкты, беркем бернәрсә эшли алмый ул җир белән, ничек крестьян, аны биләп, ялгызы, техниканы, ягулыкны, башка инвентарьларны сатып үзенә алсын?!

Ә ул пайны үз исеменә рәсмиләштереп алган хәлдә, эшкәртә аламы, берәр керем алаламы юкмы, хөкүмәт налог, салым түләтә башлый. Шуңа күпчелек пайщиклар җирләрен (кәгазьдә үзләренекен) йә колхозга, йә башка төр хуҗалык итүче эшкуарларга арендага бирергә, кайберәүләр буш хакка сатарга мәҗбүрләр. Аның каравы, хәзер, спекуляция, тунеядство дигән төшенчәләр бетте. Аның беренчесе бизнес, предпринимательство, икенчесе-ирекле яшәү.

Без яшәгән чорның, XX нче гасырның 50-60 еллары дәвамында гына да, авыл хуҗалыгында, Балыклының тормышында алгарыш, күтәрелеш тә, төшенкелек тә кичергән чаклары булды. Моның мисаллары авыл урамнарында күренеп тора. Яңа, кирпечтән салынган өйләр урамнарда күренә башлады, элеккеге салам башлы, бер беренә елышып торган өйләр бетте. Күшеккән бәбкә кебек, түбәнәеп калган өйләр бар әле, аларның хуҗалары күбесе үлеп бетте, яшьләре - шәһәрдә.

Кырларда, начар дисәләр дә, эшләргә техника, тракторлар,

үзйөрешле комбайннар бар. Борчакны, хәтта печәнне, авылыбыз белән өмәләп, чалгы белән чабуны егерме еллар артыгы белән техника көченә тапшырдык. Фермаларда да, үзенә күрә, эшләрне механикалаштыру бар. Тик телевизордан күрсәткән тапшыруларда күренгән читтәге технологияләр югарырак дәрәҗәдә, без алардан калышабыз. Димәк, чит илдә чыккан техниканы үзебезгә җайлаштырып, тагы да яхшырак сыйфатлы эшләү мөмкинлекләре белән эшләп чыгарырга кирәк.

Хәзерге тормышның уңай күренешләреннән шул бар, авыл халкы инде мотоциклларда түгел, ә җиңел машиналарга күчә башладылар, үз йортында мал үрчетеп, сатып акча юнәтеп яшиләр. Өйләрдә, һәммәсенең диярлек, телевизор, тапшыруларны спутник аша тота торган, видеомагнитофоннар, компьютерлар, интернет һәм башка заманча җиһазлар.

Тискәре, бүгенге заман таләпләренә туры килми торган күренешләр шулай ук авылыбызда саклана әле, кызганычка. Язын- көзен аякларыбыздан резин итек төшми, Балыклы урамнарыннан авыр танклар колоннасы шул изрәгән урамнардан узган төсле, тирән чокырлар.

Урамның бер ягыннан икенче ягына чыгу кыен, без еллар буена андыйга күнеккән булсак та.

Яшьләргә клубта уздырыла торган дискотекаларда, сыраны шешә бугазыннан, тартынмыйча күрсәтеп, масаеп чөмергән килеш, танцы дигән булып, гәүдәләрен бөккәләп, оятсыз хәрәкәтләр ясау, аларны ни физик яктан, ни рухи яктан баета алмый, тиешле, әдәпле тәрбия үрнәкләре бирми.

Ә спорт белән тиешле дәрәҗәдә шөгыльләнергә шартлар җитешми, сәнгать, мәдәният өлкәсенә кызыксыну уятып, аларны шул сукмакка юнәлтергә, профессиональ белгечләр юк. Шушы проблемаларны күтәреп, барча хакимият ишекләрен кагып, яныпкөеп яши торган, яшьләрдә дәрт уятып, оештыручы, артыннан ияртеп, үрнәк күрсәтеп, яхшылыкка әйди торган, элеккеге комсомол кебек көч, идея юк. Әлегә.

Шулай да, ни генә булмасын, канәгатьсезлек уята торган кимчелекләр, җитешсезлекләр булмасын, безнең авыл кешесе, гомумән татар, аеруча мишәр, тирә мохитендә нинди генә кискен үзгәрешләр тумасын, ул бик тиз ориентир алып, яңа яшәү шартларына җайлаша белә, югалып, төшенкелеккә бирелми, яшәү дәрте кимеми.

Бернигә дә карамый, авылдашларыбызның бүгенгә тамагы тук, өсте бөтен!

# Безнең турыда чит авторлар

Самара Җәмиг мәчетенең “Ислам Нур” гаҗитенең мөхәррире Фәрит Шириязданов язганча (“Бердәмлек” 1 янв. 2010 ел ):

“Балыклы авылы халкы үзенең асыл сыйфатлары, эшчәнлеге һәм күңел байлыклары белән мактана ала. Биредә шаян холыклы, үткен телле, җырга һәм моңга бай халык яши. Балыклыда гәҗәпләнерлек нәрсәләр күп. Биредә әле узган гасырның урталарында борынгы төрки бабаларыбыз Тәңрегә табынган чорлардан бирле сакланып калган “Келәү догасы” уку гадәте бар иде. Шул чакта, әби-бабайлар изге тауга (Әсәкәй тавы, Изгеләр чишмәсе. Р.Б.) барып, Аллаһы Тәгаләдән яңгыр сорап, намаз, догалар укыганнар. Чишмәләрне, урманнарны, җир-суларны олылау, һәм таулар култыгына, алар ышыгына сыенып урнашу - ул татар-болгар бабаларыбызның матур бер гадәте. Балыклы урнашкан җирләрдә без моны ачык күрәбез. Күрәсең, авыл тарихы бай булганга, аның халкы да хисләргә, моңнарга бай. Шул вакытта алар чыдамлы, түземле һәм төшенкелеккә бирелми торган халык. Балыклыдан чыккан талантлы шагыйрь, гаҗәп көчле һәм батыр кеше Минабетдин Шарәфетдиновны гына алыйк. Ул ике күзе дә күрмәскә әйләнеп, тулысынча сукырайган булса да, оптимистик рухлы шигырьләр яза. Аның энесе Рафик Шарәфетдинов оста җырчыларның берсе. Без яшәгән хәзерге заман җитди сынаулар чоры ул. Төптән фикер йөреткәндә, Балыклы авылының бүгенге уңышлары да, югалтулары да аның җитәкчеләренә бәйләнгән” - дип яза Фәрит Шириязданов.

Без бит Балыклы тарихы эзләреннән генә барырга тырышып маташабыз. Ә соң Балыклы мишәрләре тормышы турында тагын башка авторлар ни сөйли?

Менә бусы Балыклы халкы турында монда укытучы булып эшләгән, Иске Ярмәк- Чулпан кешесе Әсхәт абый Шәрәфиевнең: “Без Чулпан кешеләре” дигән китабыннан бер өзек китерәм:

....Мишәр халкы, Ярмәк типтәрләре белән чагыштырганда ачыгырак күңелле халык. Алар гәҗәеп эчкерсезләр, яшереп, батырып, яки боргаланып сөйләшми. Сине кимсетермен дип тормый, уйлаганын туры әйтә дә бәрә. Миңа бу ошый. Пышылдап, артыңнан гайбәтеңне сатуга караганда, бусы аруырак инде аның. Ачык җанлы кеше белән аралашу күңеллерәк, дуслашу ансатрак.

Балыклыда өч ел эшләдем. Бу педагогик эштә ясаган беренче адымнарым иде. Икенче яктан бу эштә үземнең кем икәнемне күрергә, кешеләргә күрсәтергә дә җитәрлек вакыт. Кайсы авылда

кешеләрнең төрлесе бар. Балыклыда күбесе мәктәп эше, баласының ничек укуы, үзен тотуы, гомумән тәртип һәм тәрбия дәресләре турында ләззәт табып сөйләшеп утырырдай гаиләләр белән күберәк очырашырга туры килде.

Минем күзәтү буенча, Балыклы хатын кызлары буйга-сынга сылулар, биткә төскә чибәрләр, сокланып карардыйлары да бар. Балыклы кешесе үзенең эчкерсезлеге белән башкалардан аерыла. Эчендә сер саклап, усаллык җыеп йөреми.

Моны авылга килеп керү белән үк сизәсең. Әз генә таныш булган берәр кеше очырый икән, ул сиңа таба ике кулын сузар, уң кулы белән тирән итеп тотып, биргән кулыңны кысар, сулы белән терсәгеңнән эләктереп алып, үзенә таба якынайтыр. Киң елмаеп, синең ничек килеп чыгуың турында сорашып та тормыйча, үзе турында, авыл турында сөйли башлар.

Мәсәлән, менә шундый яңалык саналган хәбәрне син ишеттеңме әле? Безнең олы абзый бәләкәйдән бәләкәй өч баласын калдырып, яңа хатынга барып йортка кергән, теге чая "К" га. Без братым белән икәү яртыны алып бардык та, өенә кайтсын дип үгетләмәкче идек, якын да килми. Бераз бәргәләдек тә, үзен, алып кайтып каравтка яткырып бәйләп куйдык.

Хатынына чишмә "С" дидек. Икрасы калыккандыр бер атна ятсын, ипи белән судан башка берни бирмә, дидек. Икенче көнне карасак, абзый яңадан яңа хатыныннан чыгып килә. Киттек иске йортына.

Нигә чиштең "С" дидек. Ә ул җәлләдем дә, чиштем инде ди.

(Андый мисаллар авылда булды, сугыштан соң, мин белгәне 6-7 ир-ат "карт" хатынын "яшерәккә" алмаштырды. Р.Б.)

Китаплар арасыннан XX нче гасыр башында, 1909 нчы елны басылып чыккан, авторлары Тулупов һәм Шестаков, "Наша Родина" дигән, географический китапта (Москва, 1909 тип. Им. Сытина) , 305 нче битендә, без татарлар турында менә ничек язганнар: "...Татары должны быть признаны самыми красивыми из всех здешних инородцев; сложены они хорошо, рост средний, широкие плечи, высокая грудь и толстая шея обнаруживают силу, здоровье, крепость.

Пища у татар несравненно лучше, чем у русских. У последних в массе населения мясо появляется по большим праздникам, тогда, как за татарским столом не редкость встретить баранину и козлятину, реже конину. Свиное мясо запрещәнный плод. Воздержание от вина благоприятно отзывается на народном благосостоянии, хотя татары далеко не безукоризненно выполняяют эту статью своего закона. Благодаря магометанской религии у татар есть письменность, вследствие чего татары стали по- своему развитию выше прочих

инородцев. Далее татары производят благоприятное впечатление своим развитием, трезвостью, честностью и другими хорошими качествами". Мин бераз кыскартып китердем, анда тагын татарлар турында яхшы сүзләр байтак.

Бу китап чыкканга йөз елдан артык үткән. Без татарларның, ата-бабаларыбыз турында бит бу язулар. Бер гасыр эчендә безнең тән төзелешебездә, гәүдәләребездә, чырайларыбыз сөйкемлегендә зур үзгәрешләр юктыр төсле. Ул китапта әйтелгән татарлар бит, шулай ук борынгы болгар-татар бабаларыннан ул гүзәл сыйфатларны нәселләп, саклаганнар, бездә дә сакланган һәм сакланачак.

Тамакка ашавыбыз да ким-хур түгел. Хәзер һәр йорт диярлек, йә үзенә генә, йә кушылып, кышка бер сыер малы, каз-үрдәкләр суеп ашыйбыз. Ә җәй йә сарыклар, йә кушылып эре мал, йә бройлерлар итен суыткычтан гына алып пешерәбез. Бер период Америкадан китерелгән "Ножки Буша", ягъни окорочкалар бик модага кереп киткән иде, чөнки ул чагыштырмача арзан тавык ите. Базарда да атна саен, яңа суйган итне эшкуарлар китереп саталар (акчаң гына булсын).

Сирәк кенә ат та асырый башладылар авылдашлар. Дуңгызны асырамыйбыз диярлек, ысланган салосын, гөнаһ булса да, туры килсә, читкә куймыйбыз.

Гомумән, аягың тупылдаса, авызың шапылдар, диләр бугай. Алма пеш, авызыма төш дип, эшләмичә ятсаң, болар берсе дә булмый.

Вино запрещенный плод, дип язганнар. Вот бусы белән без Балыклы халкы, күрше тирә-як халыклардан уздырмасак та, кызганычка каршы, бер дә калышмыйбыз. 1950-60 нчы елларда чөгендер үстергәндә, халык бераз көмешкә, самогон ясап маташканнар иде, хәзер дә аны (шикәрдән перегон) кайнату бөтенләй юк түгел.

Аракы, каһәр, безнең Балыклы халкына (безгә генә дә түгел) татар, мөселман булсак та, бик күп зыян китерде, бик күп яшь кешеләр башына җитте. Элек татар ир-атына үзендә начар сыйфатларны (тәмәке тарту, аракы эчәү һ.б.) булдырмау үзенчәлеге булган, аны рус язучылары да күргән, билгеләп үткән, ә хәзер Балыклы мишәре (бу минем фикеремчә) руслардан берни белән дә аерылып тормый диярлек. Хатын-кызларның ирләреннән аерылып китүдә төп сәбәпләр арасында беренче урында эчүчелек, аннан гына акча эшләү, аны гаиләгә кайтару тора дияр идем. Болар барысы да безнең чор. XX нче гасыр азагы, яңа XX1нче гасыр башының күренешләре. Үзебез нинди "изм" да яшәсәктә, яхшылыкка өмет өзмибез.

# АВЫЛ АКТИВИСТЛАРЫ



*1959 ел. Камышлыда.*

Ничек диләр әле, кешенең тормышы чиккән сөлгегә, йә чиккән ашъяулыкка ошаган диләр, бугай. Безнең чорда, бигерәк тә яшь чакта кызлар чиккән яулыклар, сөлгеләр, стеналарда "дорожкалар" күп иде. Хәзер алар музейда гына, йә иске сандык төбендә ятадыр. Кеше чиккән сөлгенең уң ягын гомеренең беренче яртысына, ә тискәре ягын - гомеренең икенче яртысына ошата диләр иде. Дөрес чиккән сөлгене, гомумән әйберне кулыңа алсаң, күренә шул, арт ягы яхшылап әллә ни матур да түгел, ә шулай да күңел күзе белән карасаң ул уйланырга мөмкинлек бирә, анда чигүченең эшенең, аның чиккәндә ничек җепләрне йөрткәнен күреп була. Безнең "сөлгенең" уң ягы да язарлык ап-ак матур түгел иде. Атларны колхозга алгач, авылыбыз белән "темпы" - уф-алла көчәнеп тартып, ачлы-туклы, пәлге ашап көн итүне язып та тормыймын. Трактор бригадаларында да вика оныннан да аш пешерделәр, барысы да булды. Безнең тормыш, Балыклы халкы, үзебезнең төрле исемнәр йөреткән колхозыбыз, анда яшәүче, эшләүче коммунистларыбызга нык бәйле иде. Соңгы вакытларда парторг (секретарь парторганизции колхоза) итеп үземне берничә мәртәбә сайладылар. Соңгы сайлау җыелышында минем кандидатура өчен 49 кеше булды, өч кеше каршы иде. Өстәвенә мәктәптә, колхозда да үзенә цеховой партоешмалар бар иде, секретарьлары: Хамзин Р. М., Ваһаҗев А. В., Ронь С.В., Кривогуз Я. Г.



Бу замандагы "сөлгебезнең" тискәре ягынарак тиңләргә бер сәбәп. Чөнки безнең эш партиянең, райкомның илдә, районда чыгарылган карарларын, авылда уздырыла торган чараларны үтәүне, тормышка ашыруны урында оештыру, әйдәү иде. Райкомның күрсәтмәләрен халыкка җиткерүче һәм аларны төгәл үтәүне таләп итүче идек. Аларга карышу, яисә ниндидер мөстәкыйльлек күрсәтү катгый тыелды, бу партия линиясенә буйсынмау дип санала һәм тиешле җәзасы кулланыла иде, партиядән чыгарып, партбилетыңны алуга кадәр. Парторг ул взнос җыючы гына түгел, ул оештыручы да, тәрбияче дә, партбюроларны, партҗыелышларны алып баручы, авыл хуҗалыгы белгече дә булырга тиеш иде. Политзанятиеләрдә кайвакытта укытучы булырга да, лектор булырга да туры килә иде, димәк халык алдында мавыктыргыч, үтемле итеп сөйләп, чыгыш ясар өчен кирәк кадәр эрудиция, күпкырлы тирән белем дә таләп ителгәндер. Төрлесе булды, яхшы ягы да, җитешсезлекләребез дә юк түгел иде. Ә ул партия хакимлеге заманында, социалистик системада парторг тормыш профессиясе иде.

Безгә кадәр дә коммунистлар, авыл интеллигенциясе, Зифа апа Хасиятуллина (Абсаттарова), Фатих абый Мусиннар, башка актив депутатлар Билалов Фаттах, Шамсетдинов Шәйхетдин бабайлар, мәктәп укытучылары агитаторлар да, заемга яздыручылар да, сугыш вакытында фронт өчен бәрәңге хәстәрләү, җылы кием җыю чараларында һәм башка бик күп төрле җәмгыять эшләрендә алдан йөреп, үрнәк күрсәтеп, дәртле энтузиазм белән йөрүчеләр күбесе коммунистлар, авыл советы депутатлары булган. Сугышка китеп, ил өчен башларын куйган авылдашларның да күбесе партия әгъзалары, коммунистлар иде. Соңгы вакытта фермаларда, механизаторлар һәм авыл халкы арасында алар ук агитаторлар эшен, партия сьездларының, ?зәк Комитет пленумнарының карарларын җиткереп, аңлатучылар иделәр. Парторг ул тормыштан артта калырга тиеш түгел, бүгенгене һәм иртәгәсене дә күздә тотып, киңерәк һәм тирәнерәк

фикер йөртеп, халык арасында, алтмышлап партия әгъзалары һәм авыл интеллигенциясе белән бергә алдан әйдәп баручы иде. Артта калдыңмы, төссезләнәсең, яисә бөтенләй күгәрүең бар. Ай саен партия җыелышы, башка җыелышлар, ел саен халык алдында отчет бирәсең, имтихан тотасың. Еш кына райкомда да, "коверга" бастырылып, - нигә колхозда сыерлардан сөт аз савасыз, нигә урып-җыюны һаман бетермәдегез!?- һәм башка күп, урынлымы, урынсызмы кырыс сөальләргә басып, җавап биреп торасың. Кыскасы, алдан әйтелгән чиккән сөлгенең җепләре, бизәкләре безнең тормышта тигез, матур чыккан җире дә, алама урыннары, кимчелекләре дә җитәрлек булды.

Без авылыбыз тарихы эзләреннән, әкеренләп кармаланып атлап маташабыз. Минем язмаларым, уйларым, хисләрем белән документализм бер-беренә тәңгәл булырга тиеш дип уйлыйм, бер-берсен тулыландырырга, хаталы җирләрен төзәтергә тиештер. Аларын инде киләчәктә кирәксенеп, ары да эзләнүчеләр, архивлардан яңа хәбәрләр табып, чагыштырып бәяләрләр.

Хәзер элекеге КПССны бетереп, "демократлар" дәүләт рулен кулларына алдылар, яңача, хөрлектә яшәү вәгъдәләп. Ә колхозда хезмәт дәрте нык сүрелде, чөнки эшләгән кешегә тырыш хезмәт җимеше өчен лаеклы түләү бетте. Хезмәт хакы, шәһәрләргә караганда, бик түбәнәйде, анысын да айлап түләмиләр. Кешеләр арасында табигый аралашу, ярдәмләшү, зур күләмле эшләрне җыйнау, өмәләп эшләшү нык кимеде, барысы да акчага бәйле.

Фермаларда ике меңләп артык баш эре мөгезле мал сыя торган коровниклар, телятниклар бушап калды, алар салмак кына ишеләләр. Списать ителмичә баланста торса, хөкүмәт шул буш абзарлар өчен салым сала, налог түләтә.

СССР таралып, КПССны таратып бетерсәләр дә, ул вакыттагы шул партия җитәкчелегндә авылыбызда, колхозыбызда дистәләп еллар буена коммунистлар, комсомоллар хезмәт алдынгылары булдылар. Һәркайсы үз вазыйфаларын чын энтузиазм, патриотик рәвештә, армый-талмый башкардылар һәм алар Балыклы авылы тарихында, аның "чиккән ак сөлге-ашъяулыкларында" якты, матур эз калдырдылар, дияр идем.

Менә алар, соңырак вакытларда авыл тормышында актив катнашып, аның үсешенә, яулаган уңышларына үзләренең

фидакарь хезмәтләре белән өлеш керткән партия әгъзалары:

Абдрафиков Абдулхак, Латыпова Анастасия, Ангалышев Абделхәй, Марданов Тәлгат, Абсаттаров Абугали, Манжукова Фәнүзә, Абсаттаров Ринат, Минебаев Әксән, Абсаттаров Сарим, Мусин Фатих, Ахметов Газиз, Нигмәтуллин Хәбиб, Ахметшин Мәрданша, Нигмәтуллина Әминә, Аглиуллин Фәрит, Рәхмәтуллин Эдуард, Билалов Рәшит, Сиразетдинов Гайфи, Ваһаҗев Әхәт, Сөләйманов Исмәгыйл, Ваһаҗева Мөкәтдимә, Сөләйманов Мотыйгулла, Ваһаҗев Хәмит, Салахова Гамбәр, Ваһаҗев Халик, Сәгыйров Минәксән, Вахитов Вәли, Хөсәинов Мингазый, Вахитов Раил, Хөсәинов Мирхази, Акмаева Фәния, Хәсиятуллина Зифа, Галимов Әхәт, Хамзин Минәхмәт, Гафуров Наил, Хамзин Рафкат, Гафурова Гульфия, Хамзин Әнәс, Гилязев Гата, Фардеева Халидә, Ганниев Нурсахи, Фардеев Рәшит, Галялиев Низам, Фәтхетдинов Сираз, Галлямов Кәрим, Фарукшин Хәбиб, Закиров Әхәт, Фарукшин Наил, Зәйнәгетдинов Зөфар, Вәлиахмәтов Наҗип, Кәримов Нурый, Усманов Мөхәммәт, Коняев Ильяс, Усманова Шәмсемөнир, Каюмов Минахтәм, Усманова Нурлыбанат, Латыпов Нәбиулла, Йосыпов Хәмит, Абсаттаров Минахтәм, Йосыпова Венера, Абсаттарова Тавхидә, Шәкуров Заһит, Шәмсетдинов Нәдер, Шәмсетдинов Наил, Шангаряев Минәксән, Шәрәфетдинов Рафыйк, Шагиев Зәки, Шәйдуллин Хабиб.

Ишеткәннәремнән һәм саклanган документлардан ачыкланган, төрле периодларда партоешма секретарьләре итеп сайланып эшләүчеләр (гомүм колхозныкы һәм соңырак участковый цеховойлар:

Мусин Фатих, Ахметов Газиз, Хасиятуллина Зифа, Шарафиев Асхәт, Шайдуллин Хабиб, Ахметшин Марданша, Абдрафиков Абдулхак, Вагазов Әхәт, Билалов Рәшит, Вагазов Халик, Ангалышев Абделхәй, Галялиев Низам, Хамзин Рафкат, Шарапова Әминә, Каюмов Минәхтәм, Ронь Сергей, Криовогуз Яков.

Бәлки бу исемлектә барысы да түгелдер.

Менә шушы партоешма җитәкчеләре, алар бар да авыл халкы күз алдында намуслы, тырыш хезмәт алдынгылары иде, чөнки начарны сайламыйлар да, алар әле күп вакытта бу йөкләмәне үзенең төп эшеннән азат ителми, параллель рәвештә шул вазыйфаны үтәп килделәр.

# МӘКТӘП



*Ватан сугышына кадәр һәм сугыш елларындагы Балыклы мәктәбе укытучылары.*

Мәктәп, балалар турында алдарак бераз сүз булып алган иде. Хәзер, белгәннәрдән әзерәк тулырак итеп язарга теләк.

Безнең татар халкы ислам дине аркасында һәр авылда мәчет янында мәдрәсәләр булдырганнар. Аларда башлыча мулла һәм аның хатыны- остабикә балаларга белем биргәннәр. Мәсәлән, Балыклыда, Уфа мөфтияте архивыннан алынган документларда имам - хатыйп мөгаллим итеп 1841 нче елның 4 нче октябрендә Идрис Исхаков билгеләнгән.

1885 нче елның 30 нчы октябрендә мөгаллимлеккә (укытучылыкка) Әхмәтшәкүр Абдуллин раслана. Димәк, Балыклыда революциягә кадәр дә (дини булса да) укыту булган.

Совет власте чорында беренче мәктәп фәкать 1923 нче елда салынган һәм эшли башлаган. Ул гади крестьян өе булган, бер бүлмәдән һәм кечкенә генә ишек алдыннан гыйбарәт булган. Башы салам белән ябылган була. Анда беренче укытучысы да, директоры да Камышлы авылыннан Гали Ягудин булган. Мәктәптә 18-20 бала, малайлар гына 1-2-3-4 нче сыйныфларда укыганнар. Бөтен фәннәрне дә татарча, ана телендә укытканнар.



*Беренче тапкыр мәктәпкә. 1971 ел*



*Музей ачу тантанасы. 1984 ел*



*Балыклы урта мәктәбе укучылары экскурсиядә. Мәскәү. 1971 ел*




*Львов. 1981 ел*



Ульяновск. 1982 ел



Ульяновск. 1988 ел



*Мәктәп. 1957 ел*

*Колхоз көче белән төзелгән мәктәп. 1974 ел*





Хезмәт дәресләре









*Балалар бакчасы эшчеләре. 1982 ел*



*9 май 1980 ел*














1928 нче елда авыл яшьләре ярдәме белән иске мәктәп зурайтылган. Ул мәктәп бинасы дүрт бүлмәдән һәм кечерәк кенә бер залдан торган. Бу мәктәптә инде 180-200 бала, кыз балалар да, ир балалар да укыган.

1928 нче елда мәктәптә 12 пионер укучы булып, аларның саны арта барган. 1928-1929 нчы елларда авылның дини "кара" кешеләре яңа мәктәп салырга каршы киләләр, читтән авылга укытучыларны кертмәгәннәр. Яңа мәктәп булса, авылда дин бетә, урыслар килә дип, каршы чыкканнар. Муллалар һәм картлар авылда культура үсешен дә хупламаганнар, беренче укытучыларны, спектакльләр куючыларны каргаганнар. Аларны авылга бәла-каза китерүчеләр дип атаганнар. Шундый кыенлыкларга, каршылыкларга кармастан, алдынгы авыл яшьләре Кәримов Нури, Әхмәтшин Мәрдәнша, Билалов Фәттах, Музафаров Садретдин, Хабибуллин Йосып, Мусин Фатих, Шәмсетдинов Ризатдин җыелып, мәктәптә кичке уку оештырганнар.

Ярлы кешеләрнең ул - кызлары, батраклар кичке укуга йөреп белем алганнар. Мәсәлән, минем инәй, Мәрьям Вахитова- Мин ликбезга укырга йөредем, дип сөйләде. Ул гәрәпчә дә, латин графикасында язганнарны да укый белә иде. Ә кириллицаны безне, балаларын укыта-укыта, үзе дә өйрәнде.

1929 нчы елда авыл яшьләреннән беренче комсомол оешмасы төзелгән. Бу оешмага алдынгы яшьләр кергән. Комсомолларга эш алып бару ифрат кыен була. Алардан көлгәннәр, төрлечә мыскыллаганнар, хәтта канлы һөҗүмнәр оештырганнар. Мәсәлән, авыл комсомол секретаре Әхмәтшин Мәрдәншага байлар, төнлә сагалап торып, һөҗүм иткәннәр һәм пычак белән кадаганнар. Ул больницада ятып, дәваланып чыккан. Ләкин алдынгы яшьләр теләсә нинди кыенлыкларны да җиңеп чыга алганнар. Мәктәп эшендә дә, культураны үстерүдә дә ныклы ярдәм иткәннәр.

Тора-бара авылда тыныч хезмәт, күңелле тормыш башланган. Авыл мәктәбе гөрләп эшләвен дәвам иткән, барлык балалар да укырга йөргәннәр. Мәктәпне тәмамлаучылар, зур уку йортларында укып, хуҗалыкның төрле тармакларында эшләгәннәр.

1941нче елның 22нче июнендә Бөек Ватан сугышы башланган. Тыныч, матур тормыш беткән. Ирләр фронтка киткәннәр. Алар хезмәтен хатын-кызлар алмаштырган. Шулай да мәктәп үз эшен туктатмаган, туктатмады, чөнки мин үзем сугыш чорында шул 7 сыйныфлы мәктәптә укып йөргән кеше.

1937-1939 нчы елларда мәктәпнең директоры булып Кудряков Әхмәт Ибрагим улы эшли.

Ул үзе математикадан укыта. Кудряковның биографиясе кызыклы. Ул 1939 нчы елның октябрь аенда Кызыл Армия сафларына алына. 1941 нче елның июнь аенда Витебск өлкәсендә, Полоцк районында майор Шлапак җитәкчелегендә чолганышта калып, аягына ранение алып, патизаннарга эләгә һәм Белоруссиянең 16нчы партизаннар бригадасында 43 отрядләре белән җитәкчелек иткән. 1944 нче елның 6 нчы маенда бер бәрелештә батырларча һәләк була.

Әхмәт Кудряков үз эше вакытында Балыклы авылы мәктәбе тарихында бик яхшы эз калдыра. Аны якыннан белүче бергә эшләгән укытучылар Усманова Шәмсемөнир, Вәлиәхмәтова З. С. Кудряков турында җылы, мактау сүзләре белән генә искә алып сөйли иделәр.

Белоруссиядә, Смоленск китап нәшрияте бастырып чыгарган Казаковның "Когда гнев обжигает сердца" дигән китабында да Кудряков турында сүз бара. И. Кудряковны армиягә алгач, аның урынына мәктәпнең директоры һәм авыл советы председателе дә булып, аның хатыны укытучы Ибраһимова Рафика Зариповна кала.

Ул Камышлы райбашкарма комитеты әгъзасы да, Куйбышев өлкә советы депутаты булып та сайлана. Соңгы вакытта Ашхабадта эшләгән...

Немец-фашист илбасарлары тар-мар ителгәч, яңадан тыныч тормыш башланган. 1947-1948 нче елларда авылда яңа мәктәп салына, башы шифер белән ябыла. Бу мәктәп, тулы булмаган урта белем бирүче, җидееллык мәктәп иде.

Сугыш елларында һәм аннан соңгы авыр елларда мәктәп директоры булып Зифа апа Хәсиятуллина эшләгән. Ул 1947 нче елда төзелгән мәктәпнең беренче нигез ташын салучы булган.

Авылда җидееллык, соңыннан сигезеллык мәктәп булдыруда ул күп көч куйган. Зифа апа шул мәктәптә 20 елдан артык ана теле, үзебезнең милли телебезне укыта. Казан кызы Зифа апа бик кешелекле, актив коммунист, халык алдында зур абруйлы укытучыбыз, авылдашыбыз.

1923 нче елдан алып 1961 нче елга кадәр эшләү дәверендә Балыклы мәктәбен тәмамлаучылардан:

Укытучылар - 51 кеше;

Агрономнар - 11 кеше;

Зоотехниклар - 8 кеше;

Мед.работниклар - 4 кеше;
Инженерлар - 3 кеше;
Очучылар - 2 кеше;
Механиклар, башка төрле профессияләрдә булганнар - 43 кеше.

1961 нче елда Балыклы сигезеллык мәктәбе каршында яңадан комсомол оешмасы торгызыла.

1967 нче елдан бирле унеллык урта мәктәп эшли.

1974 нче елны колхоз үз акчасына яңа, ике катлы кирпеч мәктәп төзеп бирде. Ә колхозчылар тырыш хезмәтләре белән мәктәп төзергә акча ясады. Ялгышмасам, 280 ләп бала укып йөреде. Карамалдан ел да җитмешләп бала килеп, Балыклы мәктәбендә белем алдылар. Тагын Степные Выселкадан, М. Ганькинодан, Степановкадан балалар йөреп укыды.

Хәзер мәктәптә күпчелек укытучылар махсус югары белемлеләр. Бу яңа мәктәпнең нигезен салганда мәктәп директоры Әхәт Валиевич Ваһаҗев иде, аннан соң эшне Мингазый Харисович Хөсәинов дәвам итте. Ә төп җитәкләп йөрүче, колхозның рәисе Хәбиб Гайзуллович Нигмәтуллин булды.

Төрле периодларда мәктәп директорлары булып эшлүчеләр:
1923 ел Ягудин Гали;
1937-1939 Кудряков Әхмәт Ибраһимович;
1939-1941 Ибраһимова Рафика Зарифовна;
1941-1951 Хәсиятуллина Зифа Хаеровна;
1951-1952 Шамов Әнвәр Сахабиевич;
1952-Шарипов
1958-Шәфигуллина Фәния Шәйхуловна;
1958-1972 Ваһаҗев Әхәт Валиевич;
1972-1975 Хөсәинов Мингазый Харисович;
1975-1978 Ганниев Нурсәхи Мингалимович;
1978-1985 Марданов Тәлгат Закирович;
1985-2002 Манжукова Фәнүзә Исхаковна;
2002- Абсаттарова Таухидә Назаховна.

Хәзер, кызганычка, мәктәптә укучы балалар әзәйде, 9 сыйныф кына калды.

Укулар турында язганда шуны да теркәп китәргәдер. Кыш көннәрендә тагын бер төр уку- укытулар бар иде. Ул да булса политукулар. Комсомоллар да коммунистлар да кайбер елларда КПСС тарихын өйрәнгәндә поп Гапоннан ары үзләштереп китә алмадык (1905 ел).

Ә культура революциясе вакытында авылда Ликбез (ликвидация безграмотности мәктәпләре) эшләгән.

Кыш көннәрендә колхозда Агрозоотех укуларын авыл специалистлары, механизаторлар, терлекчеләр белән уздыра идек. Файдасы да булды, яхшы укучыга, билгеле инде эшенең нәтиҗәсенә карап, классностьләр бирелә иде, 1 нче, 2 нче класс, ә ул аңа эш хакына өтәмә, 10-20 процент алырга хокук бирде. Әлбәттә, теориядән күберәк үзебезнең кулланыла торган технология һәм экономика турында сүз барды.

***Төрле елларда мәктәптә эшләгән укытучылар***

Ягудин Гали
Кудряков Әхмәт
Ибраһимова Рафыйка
Мусин Фатыйх
Хәсиятуллина Зифа
Шәрәфиев Әсхәт
Маннапова Назыймә
Шамов Әнвәр
Шәфигуллина Фәния
Шәрипов
Әхмәтова Мөнәвәрә
Әхмәтова Әминә
Фәртдинов Гариф
Баһауова Динә
Шутова Валентина
Ваһаҗев Әхәт
Шәнгәряева Әминә
Вәлиәхмәтова Зәкия
Ваһаҗева Мөкәтдимә
Ваһаҗева Мөхтәрәмә
Йосыпова Гөлсинә
Ганниев Нурсәхи
Хөсәинов Мингазый
Манжукова Фәнүзә
Мәрдәнов Тәлгат
Мәрдәнова Рәйсә
Салахова Гамбәр
Йосыпов Фәнил
Фардеева Илсөяр
Закирова Светлана
Акмаева Фәния
Абсаттарова Таухидә
Әмирова Ильмира
Усманова Мәдинә
Гадельшина Фәһимә
Халимова Гөлмиҗиян
Гафурова Гөлфия
Гыйззәтуллина Земфира
Вахитова Мәдинә
Хәбирова Венера
Нигъмәтуллина Әминә
Усманова Нурлыбанат
Галялиева Зәйнәп
Вергазова Хәдичә
Гайни
Ангалышев Габделхәй
Фәтхетдинов Касыйм
Фәтхетдинов Гамил
Әһлиуллин Асыл
Усманова Шәмсемөнир
Ангалышева Әлфия
Мусина Гөлсем
Дочкина Зәйнәп
Минебаева Җиһан
Кәлимуллина Динә
Баһаветдинов Мәхмүт

# Китапханә




1953 нче елда Балыклыда беренче мәртәбә китапханә ачыла, аңа кадәр кечкенә генә китапханә мәктәптә бар иде. Баштан китапханә мөдире булып Камышлыдан Зарипова Җәүһәр исемле кыз эшләде. Аннары озак еллар Вәлиәхмәтова Равия Кыямовна хезмәт итте.

1965 нче елны, яңа клуб - СДК (Авыл Мәдәният Йорты) ачылганчы китапханә өч мәртәбә урынын алыштырырга мәҗбүр булды.

Ә хәзер ул СДК бинасында яхшы, иркен бүлмәдә урнашып, эшен дәвам итә. Анда Галимова Рузалия Нурсәхиевна мөдир вазыйфасын үти. Библиотека чагыштырмача бай, анда төрле темага китаплар табып, алып була. Әгәрдә, кирәк китап булмаса, мөдиргә заявка биреп, районнан кайтартырга була.

# Шифаханә

Балыклыда элек больница Урта Кырда иде. Елганы, “Кротков” чокырын чыгып, тигезлектә, чирәмдә урнашкан иде. Күрәсең, аны Балыклыда МТС ачылгач төзегән булганнардыр. Берничә агач өй тезелеп тора иде. 1956 нчы елда 10 койкалы стационар ясаганнар. МТС таралгач, аның конторасы булган бинада 25 койкалык стационар ачыла, 1973 нче елда ФАП кына булып кала.

Врачлардан, беренчеләрен ишетеп кенә беләм: Сундуков, Зөһрә, Олимпиада һәм аннары соңга кадәр Суркова Валентина Андреевна эшләде (Семенкино кызы).

Фельдшерлардан озак еллар Монахова Александра Павловна (Закирова) эшләде, аннан Даньшина Любовь Алексеевна, Галялиева Рамиля Рашитовна, акушерка Вафина Әнисә Минәхмәтовна, Кәфия апа булдылар. Соңгы вакытта фельдшерлар алмашынгалады, ә хәзер Шарапова Эльмира эшли.

Бер период медицина хезмәткәрләре булып Ваһаҗева Флера, Ваһаҗева Венера, Камалиева Зөхрә, Галиева Сәкинә эшләп алдылар. Фельдшерлар арасыннан Балыклы халкы өчен күп тә, яхшы да Монахова Александра Павловна эшләде. Аңарга бөтен Балыклы, Карамал, хәтта Степановка халыклары исеменнән зур рәхмәт.

Больница чагында автомашиналары да, атлары да бар иде.

# ЦСО

## (халыкка социаль ярдәм күрсәтү үзәге)



*Фәһимә Йосыпова һәм Динә Шәрәфетдинова*

Олы яшьтәге кешеләргә еш кына төрле авырлыклар кичерергә туры килә. Алар гомере барышында да читенлекләрне байтак очыртып, аларны җиңәргә чыныккан булалар һәм олыгайгач та, яшь буынга гыйбрәтле үрнәк булып, бирешмәскә тырышалар. Ләкин вакыт үзенекен итә, исәнлекләре нык какшый. Гомер буе хезмәт итеп, азмы-күпме "үлемтеккә - кара-көнгә" дип җыйган акчаларын Гайдарның шоклы терапиясе бер мизгелдә яндырды, юкка чыгарды. Шунда инде хөкүмәт олы кешеләргә, ветераннарга ярдәм итәргә уйлый. Россия федерациясе хөкүмәте 1991 нче елны "Олыларга һәм инвалидларга социаль ярдәм күрсәтү" үзәген оештыра.

Ә андый шөгыль дәүләт күләмендә кузгалганчы, 1989 нчы елны Клявле координацион үзәк аша безнең социаль хезмәткәребез Шарапова Рәшидә Исхак кызы ун ятим, олы яшьтәге кешеләргә ярдәм күрсәтә башлый.

Менә алар:

Латыпова Сәхибкамал, Вәлиева Бәдәр, Вәлиева Бәдрия, Билалова Зарига, Хисмәтова Бәдрия, Усманова Гаширә, Төхвәтуллин Гатият, Абсаттарова Фәхригаләм, Төхвәтуллина Минехаят.

1991 нче елдан социаль хезмәкәрләр итеп әлеге кешеләр билгеләнде:

Степановкадан - Щербакова Вера;

Чулпан поселогыннан - Сәфиуллина Миңсылу;

Балыклыдан - Фәйзуллина Зөлфия, Шәмсетдинова Гөлсинә, ә 1992 нче елдан - Шәрәфетдинова Динә, Хәсәнова Алсу эшли башладылар.

Социаль хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр саны 27 кешегә җитә.

1996 нчы елны Балыклыда инде территориаль халыкка социаль күрсәтү үзәгенең көндезге ял итү бүлеге ачыла. Ә аларга эшләр өчен бина кирәк иде. Бу мәсьәләне хәл итүдә ветераннар Нигмәтуллин Х. Г., Ганниев Н. М., Камышлы ЦСО директоры Галимова Г.Х., колхоз рәисе Фардеев Р. В., авыл үзидарә башлыгы Ваһаҗев Х., авыл старостасы Йосыпов Х. Н. актив катнашучылар. Колхоз идарәсе ул службага бүләк рәвешендә ашханә бинасында бүлмә бирде.

Балыклының ЦСО җитәкчесе булып Йосыпова Венера эшли башлый, ОДП да, ягъни көндезге бүлектә медицина хезмәткәре булып Ваһаҗева Гөлнара Минәксәновна, хезмәткәрләр Йосыпова Г., Әхмәтҗанова, Усманова, хезмәт инструкторы Әбделвәлиева Зилә эшли.

1998 нче елны колхоз биргән вагончикта “Милосердие” кибете эшли башлый. Шул ук елны ул вагончикка янкорма төзелде. Хәзер ЦСО да 15 социаль хезмәткәр эшли.

ОДП да электрофорез, Чижевский люстрасы, ут белән дәвалау җайланмасы, массаж, тренажерлар бар. Ял итәргә 10 көнгә ун кеше чакырып дәвалану курслары үтәләр.

Шулай ук үзләренең автомашиналары бар, ерактарак яшәгәннәрне аның белән алып киләләр.

# Авыл Советы, ягъни авыл үзидарәсе



Элек Балыклыда җирле идарә эшләрен авылның старостасы алып барган. Бездә билгеле утыз еллар чамасы староста вазыйфасын Шәмсетдинов Садыршәет башкарган. Күрәсең, аларда үзләренә күрә һәр мәхәлләдә активлары һәм берәр язу эшләрен алып баручы-делопроизводитель булгандыр.

1917нче елның Октябрь инкыйлабыннан соң билгеле хакимият органнары башкача формаларда оештырыла. Табигый ки, революция илдә Совет власте урнаштыргач, шәһәрләрдә шәһәр, районнарда - район, авылларда - авыл Советлары булдырыла.

Нәрсә соң ул безнең авыл советы, кайчан туган, нинди эшләр башкарган?

Баштан 1918 нче елда Комитет бедноты ясалган була, аннан соң ул сайланылган авыл кешеләреннән, хәзергечә депутатлардан тора. Советлар өстенә үз территориясендә барлык хуҗалык эшләрен оештыру һәм башкару йөкләтелә. Аларның тәүге эшли башлаган чорларында нинди эшләр башкару мисалларын түбәндәге Богырыслан архивында сакланган документлардан күренә:

**Протокол**

**1919 год август 6 дня дер. Балыклинск.**
**Сель. Обществ. Байтугановской волости,**
**Бугурусланского уезда**

Пред. Кашаф Хусаинов. О выборе сельской комиссии уборки полей Кр. Армии, где между собой обсудили вопрос избрать сельской комиссии из трех человек, где избрали председателя и двух членов.

Пред. Залимзян Ангалышев, Сафиулла Бикбов, Миназит Насыров, что удостоверяет сельсовет

Пред. Хусаинов

Секретарь Мухутдин Илингин.

**Протокол.**

Балыклинского сельсовета, что 1919 год уборку хлебов Красно Армейцев силами сельчан закончили. Уборку озимых закончили.

Расписался председатель Ангалышев

1919 год сентября 2 го дня.

Совет ул хөкүмәтнең нигезе була. Халык тарафыннан сайланган, ул ел саен шул халык каршында, җыенда (сходта) эшләгән эшләре турында хисап бирә. Совет үз хуҗалыгы белән җитәкчелек итә, үзенең учреждениеләре һәм организацияләрен тикшереп, алып бара. Совет үзләренең бюджетының үтәлешен карый, җирле салымнарны, самообложение диелгән түләүне дә җыя торган иде.

Совет авылдагы чишмә, коеларны чистарттыра, үзләрендәге күперләрне карый, төзәттерә, урамнарны йөрерлек хәлдә тота, авыл йортларында янгын сүндерә торган инвентарьләрен булдырыруны таләп итә, пожарный пост оештырып, аны тиешле янгын сүндерү кораллары һәм янгын сүндерүче кешеләр белән комплектлый.

Гомумән авылда туып торган һәрбер хуҗалык итү мәсьәләләрен хәл итү, үзләре кабул иткән карарларны һәм район Советыннан килгән күрсәтмәләрне тормышка ашыра.

Сугыш вакытында һәм сугыштан соң совет депутатлары авыл халкын заемга яздырдылар һәм аларны халыктан җыйдылар. Шул ук заманнарда сельсовет халыктан сөт, май, йон җыюны оештыра һәм ул эшнең үтәлеше турында райбашкарма каршында җавап бирә. Совет, илдә Югары Совет, хөкүмәт чыгарган законнарның үтәлешен оештыра һәм күзәтә, мәктәп, больница, кибетләр, мәдәният - культура учакларының эшен оештыруда катнаша һәм даими күз үзәгендә тота. Авылда, урамнарда, төрле җәмгыятъ оешмаларында тәртипне ныгыту өчен ирекле халык дружиналары оештыра, аларның эшен тикшерә.

Сельсовет ЗАГС эшен дә, нотариаль хезмәт күрсәтүне дә алып барды.

Вакытында, (сугыштан соң) авыл кешеләреннән Сельсоветта чиратлап, телефонда дежурный-исполнитель тәүлек буена тота иделәр. Мин малай, шунда инәй урынына йомышка йөредем. Шул чакта Камышлыдан налог җыючы, суд- исполнитель ахырысы, бер кеше килгән иде. Барын да белмим, тик сүз буенча налогын түләмәгән кешенең өеннән ялтырап торган җиз самоварын алып, урам буйлап сельсоветка төштеләр. Күрәсең, ул бахырның бар байлыгы шул җиз самовар булгандыр.

Балыклы сельсоветы рәсми рәвештә 1919 нчы елны ясала. Аның беренче председателе Салимҗан Ангалышев, сәркәтип итеп Седяководан рус кызы Зояны билгелиләр, тик ул озак эшләмәгән бугай, чөнки 1919 нчы елның августында сәркәтип булып протоколларда Мөхетдин Илингин имзасы тора.

1928 нче елның 16 нчы июлендәге ЦИК ның карары буенча Средневожский өлкәсенең

Бугуруслан округында Байтуган районы төзелә, ә ул 1939 нчы елның 7 апреленнән Камышлыга күчерелә.

1954 нче елны Балыклы сельсоветына Седяково, Чекмаловка, поселок Чулпан, Яңа Балыклы керәләр.

1959 нче елның февраленнән Балыклы сельсоветына Степановка сельсоветы кушыла.

1965 нче елның 3 февраленнән Балыклы с/советы Похвистнево районына кертелә.

1965 нче елны Балыклы сельсоветына 3 колхоз, к-з “Заря”, Степановка, Михайловка, Конновка һәм Мәзгүт авыллары белән кертеләләр.

1970 нче елны Балыклы сельсоветына Ст. Выселки һәм пос. Поникла күчерелә.

Колхоз “Восток” үзәге Чулпанда, анда: Чулпан, Седяково, Чекмаловка, Н. Балыкла;

Колхоз имени XX11 Партсъезда - үзәге Ст. Балыкла.

Совет территориясендә эшлиләр: бер урта мәктәп, бер сигезеллык мәктәп, һәм 6 башлангыч мәктәпләр, 5 медпункт, бер участковая больница, 3 клуб һәм башка учреждениеләр.

1994 нче елның 21 июнендә Балыклы сельсоветы - волость дип теркәтелә.

Балыклы волостына керәләр: Ст. Балыкла, Яңа Балыклы, п. Чулпан, д. Степановка и д. Ст. Выселки. Өч колхоз, бер урта мәктәп Балыклыда, 9 еллык мәктәп- Степановкада, Чулпанда, 3 СДК, 3 библиотека, 3 ФАП, һәм балалар бакчасы.

2005 нче елның январеннән поселок Чулпан Иске Ярмәк сельсоветына күчә.

2003 нче елның Рәсәй Федерациясенең № 131 номерлы законы буенча волостьны Сельское поселение ясадылар (Муниципаль авыл җирлеге). Анда керә: Ст. Балыклы - үзәк, д. Степановка, п. Н. Балыкла, Ст. Выселки-яшәүчесез.

Муниципаль авыл җирлегенең беренче депутатлары:

Баһаветдинов Гаиль, Гиззатуллина Зимфира, Нигмәтуллин Рафаэль, Сәгдеева Сәмәрия, Фролов Анатолий, Шәрәфетдинов Раиль, Шәрәфетдинов Рафыйк.

Авыл җирлегенең башлыгы итеп Шәрәфетдинов Раиль Равилевич сайлана.

Төрле вакытта, төрле срокта эшләгән авыл Советы председательләре:

Шәмсетдинов Садыршәет- староста, Ангалышев Сәлимҗан, Шагиев З, Хөсәинов Кашаф, Абсаттаров Әбугали, Шәмсетдинов Шәйхетдин, Әхмәтшин Мәрданша, Латыпов Газиз, Вахитов Вәли, Билалов Кыям, Галялиев Низам, Ибраһимова Рафика, Каюмов Минәхтәм, Хисамиев Сахаб, Нигмәтуллин Хәбиб, Кәримов Нури, Вахитов Раил, Галлямов Кәрим,  Ваһаҗев Халик, Фәтхетдинов Сираҗ, Сөләйманов Исмәгыйл, Шәрәфетдинов Раил- волость башлыгы. Йосыпов Рәсил - поселение башлыгы.

Беренче оештырылган Комитет беднотаның әгъзалары:

Музаффаров Садри, Билалов Фаттах.

Кем артыннан кем эшләгәне, бәлки бу исемлектә бик дөрес китерелмәгәндер.

## Лишить избирательных прав

Күршебез, иптәшебез Ангалышев Абделхәй ничектер сүздән сүз киткәч, миндә дә Самара архивының справкасы бар бит диде. Мин аңардан алып, монда язып китәргә булдым.

Государственный Архив Самарской области

Архивная справка

От 18.12.2002 №07-36/136А

Ангалышову Абделхаю Абделбаровичу, ул. Безводовка,16,

села Балыкла, Камышлинский район, Самарской обл. 446975

В документах архивного фонда Байтуганского райисполкома Средневолжского края, в деле с материалами на лишение избирательных прав гр. Села Балыкла Ангалышева Абдулбара, в социально- экономической характеристики указана год рождения 1887г. Кулак, торговец. Лишен избирательных прав 9 июня 1932г. За эксплуатацию наемного труда и торговлю. Подвергался 1 раз по ст.61 в 1932 г. За невыполнение государственных заданий.

Была изъята корова, амбар, средства производства. Семья 5 человек. Имущественное положение на 1917 г. Земли под обработкой 20 дес. Домов( подчеркнуто слово домов-складов)- 4, хоз.построек-4, 2х поставная мельница,1 плуг, 1 сеялка, 1 веялка, конная молотилка, (8 и конная), 3 лошади, 3 коровы, 1 бык, 50 овец, 2 козы, домаш.птица-35.

До 1917 года и до 1929 года держал 1 годового и двух сезонных работников.

В выписке из протокола №19 заседания президиума Байтуганского РИК от 9 июня 1932 года значится: Слушали материал на гр. С. Балыклы Ангалышева Абдулбара на лишение его избирательных прав по признакам: эксплуататор наемного труда в течении 4-х лет 27-30годы годовых до одного, и сезонных до 5 человек. При наличии 8-и конной молотилки. Занимался торговлей сельхоз продуктами в 1929 г. За что был штрафован на 55 руб.

Постановили: В виду наличия достаточных данных для лишения избирательных прав Гр Ангалышева лишить избирательных прав.

В списке подлежащих выселению согласно Постановления общего собрания колхозников от 25 марта 1933 года значатся Ангалышев Абдулбара - 45 лет. Члены семьи: Бисал - 40 лет - жена, Зайнаб - 17лет - дочь, Самига - 12 лет - дочь, Габдулхай-2 года - сын.

В тех же документах, а так же в документах Средневолжского крайисполкома, Самарского окрисполкома других сведений о семье Ангалышева А. за 30 годы в Госархив на хранение не поступали.

Основание Ф. р 1675 оп.1 Д-38 Ф р 779,Ф р 341

Имена так указаны в документах.

Директор Н.Н.Санникова.
Зам.нач.отдела Н.С. Расказова

## АРХИВНАЯ СПРАВКА

Госархив Самарской области (копия) 443099
Г. Самара, ул. Молодогвардейская, 35 тел. 33-62-72
От 28 03. 2001 г.

О наличии сведений.

Сообщаем, что документы в госархиве хранятся только со времени образования Самарской губернии в 1851 году в связи с чем, дать какие либо сведения о дате образования с. Старая Балыкла в 1650-1660 г. не предоставляется возможным. В печатных материалах, списках населенных мест Самарской губернии за 1851, 1889, 1900, 1910 и 1928 годы Старая Балыкла входила в Бугурусланский уезд, в 2 й стан. Назывались деревня Давыдкино, второе название Балыкла. Деревня была казенной, находилась на реке Балыклы.

Проживало в ней татары в количестве 1000 человек, имелось у них 143 двора, одна магометанская мечеть. В 1889 году деревня имела одно название - Балыкла.

При волостном делении Бугурусланского уезда деревня вошла в Байтугановскую волость. В деревне имелись 259 дворов, в которых проживало 1548 человек. В деревне находилась мечеть, 1 магометанская школа, 1 мельница. Был развит рогожный промысел.

К 1910 году количество дворов увеличилось до 397 с населением 1894 человека. Открылась еще одна школа. Деревне принадлежала 5300 десятин земли. Была построена еще одна мечеть.

В 1928 году дворов было 434 в ней прожиало 2272 чел.

Для написания более подробной истории села по документам хранящихся в ГАСО приглашаем Вас в читальный зал для работы т. к. работа написания истории села требует много времени и труда, которого сотрудники ГАСО не располагают.

Основание: Списки населенных мест губернии за 1859,1889,1900, 1910 и 1928 г.

**Директор А.Н. Трегубов.**
**Зав. Отделом А.Т. Удинцев**

**Главе сельского поселения Балыкла ЮСУПОВУ Р.М.**

**Российский Госархив древних актов.**

Б. Пироговская ул. Д- 17, Москва, 119435 от 10.05. 2012 №314

Сообщаем, что наиболее ранние сведения о д. Давыдкино-Балыкла тож, “владения ясашных и служилых татар” обнаружено в экономических примечаниях к планам Генерального межевания Бугурусланского уезда ( конец XV111 нач. X1X в.) где приводятся сведения на момент 5-й ревизии (середина 1790 г.г.)

В это время в д. Давыдкино было 48 ясашных и 23 служилых двора. В первых проживали 158 мужчин и 156 женщина, а остальных 28 мужчин и 32 женщина (ф.1355 оп 1 Д 1876 Л-201-203 )

Согласно спискам населенных мест Российской империи (Вып.36 Самарской губернии СП (б) 1864г. с.44) в середине X!X в. В казенной деревне Давыдкино (Балыкла) при речке Телегазе (Бугурусланский уезд, 2-й стан) было 143 двора, в которых проживали 470 муж. 501 жен., а так же имелась мечеть.

При просмотре материалов 2-й (1748) и 3-й (1792) ревизий Казанской дороги Уфимского уезда (ф.350 оп. 2 Д 3791, 3779, 3801-3803), куда в середине XV11 в. входила интересующая Вас часть Бугурусланского уезда, населенный пункт с названием Шарламабаш-Давыдкино-Балыкла не обнаружена.

**Российский Государственный исторический архив**

Россия, 190000, Санкт-Петербург

Английская набережная, дом 4 тел. (812) 117-09-26.

21.03.05 № 395

Р.Р. Шарафутдинову Главе адм. Балыклинской волости

с. Ст. Балыкла Камышлинский район Самарской области 446975

О селе Балыкла.

Уважаемый г. Шарафутдинов, наш архив хранит документы X1X нач. XX века, посему возможен поиск материалов об истории села этого периода, т.к. село было казенным, сведения о нем возможно искать среди документов министерства гос. имуществ, это будет сведения общего характера. Из печатных источников известно следующее:

Списки населенных мест росс. Империи т. XXXV1 Самарской губернии СП(б) 1864:

Давыдкино (Балыкла) деревня казенная Бугурусланского уезда 2 го стана. По правую сторону проселочного тракта из Сергеевских вод в Бугульму при реке Телегасе 143 двора жителей 473 м. п. и 501 ж. п., мечеть.

Волости и важнейшие селения России вып. 1V губернии Нижневожской области СП (б)1883 Балыкла (Давыдкино ) при р ч Терегале дворов 177 жителей 1098, мечеть, 2 водяные мельницы.

Если Вас интересует более ранняя история села следует обратиться в Росс. Гос Архив Древних актов по адресу: 117393 Москва, Профсоюзная ул. 80

Наш архив выполняет запросы на платной основе, просим оплатить прилагаемый счет-аванс

Приложение - договорное письмо и счет-аванс № 236 на 2 л.

**Директор Р. Г. и А. Л.Р.Соколов**
**Нач. отдела Л. И. Синицына**
**Исп. Лупанова В.М. 385-55-42**

**Национальный архив республики Татарстан**

42.01.11 Казань, ул. Кремлевская 2/6

тел (8432) 38-59-48 01.03.2005 36т

На № 16 от 01.02.2005

Главе администрации Балыклинской волости, Камышлинского района, Самарской области С.Ст. Балыкла 446975

В списке населенных мест Самарской губернии по сведениям на 1859год (СПб 1864) во 2ом стане Бугурусланского уезда значиться д. Давыткино (Балыкла) (название так по тексту) при речке Телегас по правую сторону проселочного тракта с. Сергиевские в г. Бугульму, имелась магометанская мечеть, проживало 473 муж. И 501 жен. Количество дворов составляло 143.

Более ранним справочными по Самарской губернии архив не распологает. Метрических книг д. Давыдкино (Балыкла), Старая Балыкла, Давыдкино Шарламабаш Бугурусланского уезда Самарской губернии в архиве не имеется.

**Директор Л.В.Горгхова**
**Нач. отдела Л.О.Кузнецова**

**Р.Ф. Администрация Клявлинского района Самарской бласти**

446960 Ст. Клявлино ул. Октярбрьская 60 тел. 2-15 58

25.06.2006 № 147 Н

Нигматуллину Хабибулле Гайзулловичу с. Ст. Балыкла, Камышлинский район Самарской области

**Архивная справка**

Показатели для определения стабильности социально-экономического развития сельскохозяйственной организации Сельхоз артель им. XX11 Партсьезда Балыклинского сельсовета Клявлинского района Куйбышевской области

| Наименование показателя | Единица измерения | Годы | |
|---|---|---|---|
| | | 1968 | 1969 |
| Объем реализации продукции в физическом выражении | | | |
| Зерновые | Цент | 31724 | 32377 |
| Мясо | Цент | 421 | 808 |
| Молоко | Цент | 787 | 3059 |
| В стоимостном выражении | Тыс.руб | 592,8 | 609,7 |
| Рентабельность производства | % | 121,1 | 52,9 |
| Минимальная Зарплата | Руб. | 24,70 | 24,61 |
| Среднемесячная зарплата по организации | Руб. | 48,21 | 59,37 |
| Чистая прибыль | Тыс.руб | 324,7 | 210,9 |
| Наличие и размер просроченной задолженности по платежам (в бюджет) по 3/плате, данные об отсрочках и рассрочках этих платежей | Тыс.руб | ---- | ---- |

Основание: Упр. с/х-ва. Оп/ед.хр 114, 135

**Зав. архивным отделом Н. А. Федотова**

**Руководитель отдела администрации района В. И. Куликов**

# Безнең нәсел тамырларыбыз

***(Төзүчеләр Р. Билалов, Н. Вахитов)***

Әниебез Мәрьям ягыннан дәү бабабыз Вахитның әтисе - Абдул.
Дәү бабабыз - Вахит Абдул улы 1847-1933 елларда. 86 яшь.
Дәү әбиебез - Фаһизә (Файза) Исмәгыйл кызы, Камышлыдан, янгында һаләк була.
Аларның балалары:
Хәтирә- Абзалетдин, Сәгидә,
Гиззафа- улы Шәһит, Урта Азия, Бекабад.
Закир-Җәүһәр, Мәрьям, М-Вәли, Гариф- 1870-1922 ел.
Минсрур- Нурулла, Зәки, Кәмилә, Харис, Ярулла. Карамал.
Хадичә- кызы Фәһимә, (ире Шәһит), Н. Мансуркино-Сосновка.
Минәхмәт- уллары-Хәмит, Нәҗип Дальний Востокта вафат.

Бабабыз - Закир Вахит улы 1870-1922 ел. эч кастасыннан (аппендикс) вафат.
Әбиебез - Гәзизә Ганни кызы 1884-22.05.1949ел.
Балалары:
Гариф Закир улы 1904-1930ел, Үзбәкстанда вафат.
Җәүһәр Закир кызы 1906-1982 ноябрь. Богырыслан.
Мәрьям Закир кызы 1911-12.04.1989ел.
М, Вәли Закир улы 4.10.1913-11.10.1998ел.

Гәзизә әби ягыннан
Дәү бабай - Гәбделгәнни
Дәү әби - Гәфифә
Балалары:
Минегали
Минехәер (улы Шәһит, Үзбәкстан, Бекабад).
Зиннур (улы Сәлимҗан, кызлары Вәлия, Вәсилә,Минҗиян, Минехаят)
Газизә.
Хәдичә (ире Шәһит) уллары Гариф, Кыям, Минетдин, Хөлләтелҗинан.

Закир кызы Мәрьямнең һәм Билалов Кыям Шарап улының балалары:
Рәшит Кыям улы Билалов - 13.02.1935е. (хатыны Мөкәтдимә- Дания, Лилия, Марсель).

Равия Кыям кызы Вәл иәхмәтова 11.05.1937ел.(ире Нәҗип; - Венера, Илдар, Радик).

Рөстәм Кыям улы Билалов - 1939-2011 (хатыны Нажия-Лада, Алисә).

М. Вәли Закир улы Вахитовның һәм Фатыйма Барый кызының балалары:

Наил Вәли улы Вахитов- 28.02.1939ел.

Раил Вәли улы Вахитов- 5.12.1942е.

Тәлгат Вәли улы Вахитов- 10.08.1946- 31.03.1986ел.

Назимә Вәли кызы Фәрхетдинова- 28.12.1948 ел.

Булат Вәли улы Вахитов- 27.09.1953ел.

Җәүһәр Закир кызы һәм Таһиров Шәйгаттар балалары:

Нурхәтим Шәйгаттар улы Таһиров

Нурфатыйх Шәйгаттар улы Таһиров

Нурмөхәмәт Шәйгаттар улы Таһиров

Камил Шәйгаттар улы Таһиров

Мәдинә Шәйгаттар кызы Таһирова- Богырыслан

Әтиебез Билалов Кыям Шарап улы ягыннан шәҗәрәбез.

Дәү бабабыз - Билал (Шырлык )

Дәү әбиебез

Балалары- Фаттах Билал улы Билалов

Мифтах Билал улы Билалов

Шарап Билал улы Билалов

Бабабыз - Шарап Билал улы Билалов сугышта һәлак булган.

Әбиебез - Кәфия Төйхвәтуллина

Балалары: Кашаф Шарап улы Билалов 1906-1943ел, сугышта һәлак була, Тула янында. Кыям Шарап улы Билалов 1909-19.09.43ел, һәлак була Украинада. Фатыйма Шарап кызы Рахимова Иске Ярмәк, ире Әхмәтгали.

Билалов Кашаф һәм Зарига Даутованың балалары: Гомәр Кашаф улы Билалов- Динә, Дилә, Дания, Сафия.

Кыям Шарап улы һәм Мәрьям Закир кызының балалары: Рәшит+ Мөкәтдимә=Дания, Лилия, Марсель. Равия+ Нәҗип = Венера, Ильдар, Радик. Рөстәм+ Нажия = Лада, Алисә.

Фатыйма Шарап кызы Билалова һәм

Ахмәтгали Рахимовның баллары: Әбүзәр+ Тутыя, Зөфәр+ Әминә, Сәлимә+Әсхәт, Таһир+Сафия, Мөхтәр, Солтан.

Авылыбыз тарихы белән кызыксыну, аны тагын да тирәнерәк тикшерергә омтылу сине тагын да ерагырак чорларга, төрки кыпчаклар дәверенә, алар яу тоткан далаларга ук алып китәргә маташа. Бу язмаларым колачлаган чорда, минем бабамнар әлбәттә, морза, тархан, кенәз булуларын раслап булмый, чөнки моңа дәлилләр юк.

Ә бит кайбер тамыр җепләребездән кыпчак-мишәрләребез, Алтын Урда заманында, ярсу аргамагын иярләп, җәя алып, кылыч тотып, иксез-чиксез далалрны гизеп, яу йөргәндер, йә исә мал асырап, җир сукалап, ашлык үстергәндер. Чөнки нәсел, токым сыйфатлары, генә дигән сихри күзәнәктә гасырлар, меңъеллыклар аша сакланып, ничәмә- ничә буыннарда шыта, шулар буй-сыныбызда, чыраебызда, табигатебездә калка, югалмый.

Бер бабаларым, ишетеп белгәнемчә, умартачылык белән шөгыльләнгән, хатыным ягыннан бабайлар сәүдәдә йөргәннәр, ихтимал берәр бабам зур елга буендагы, чын Балыклы авылында, кармак йә ау белән балык тотып, гаиләсен туендыргандыр.

Аларны инде, киләчәктә берәр эзләнүче, тикшерүче булса, ачыклар. Алдарак китерелгән шәҗәрәбезгә карап, күңелем шатлана: без бакыйлыкка киткәч тә, бөтенләй онытылып, юкка чыкмаячакбыз, минем яшәвем балаларда,

оныкларда, туганнарда дәвам итә һәм итәчәк, чырай- төсебез, кыяфәтебез, холкыбыз киләсе буыннарда, билгеле вакытка кадәр сакланачак, барысы да бик идеаль булмаса да.

Нишлисең, ни булганы шунда инде. Мишәрдән мишәрләр барыбыз да.

# Авылыбызның нумизматы

Мин ишетеп белә идем, безнең авылдаш Гыйззәтуллин Рәшит төрле иске акчалар белән кызыксынып, эзләп, күп кенә борынгы тәңкәләрне, вак акчаларны, бизәнү әйберләрен, “безделушкалар”ның коллекция итеп җыйганын. Адаш Рәшит белән бер очрашкач мин бу турыда аңардан сорадым. Ул үзендә авыл территориясендә табылган иске акчалар, башка әйберләр барлыгы турында сөйләде. Минем үтенечемә каршы килмичә, озак та үтми, шәт берничә килолап коллекциясен күтәреп, минем янга үзе килде һәм өстәлгә аларны таратып салды. Гомумән анда төрле зурлыкта, төрле еллар белән даталанган, төрле авырлыкта, төрле материалдан эшләнгән акчалар да, башка төр предметлар да күп иде. Мәсәлән, җиз тәнкә № 1-диаметры 2 см. чамасы, уртасында квадрат формалы тишеге бар. Ул аларны 2 данә Кысырык Урам башыннан таптым, ди. Компьютердан карап белешкән, бу акчалар 1644 нче елгы Кытай акчасы - Цянь булырга тиеш, ди.

Тагын Алтын Урда акчасы да бар, көмештән, табылу урыны- Себер Урамы, аңлаешсыз хәрефләрдән торган язуы бар ди. Компьютердән белешкән, ул Алтын Урда акчасы, көмештән.

1731, 1738 нче елгы акчалар Кизләү чишмәсе яныннан табылган. 1753 нче елгы акча Сагдеев Минехәер бабай йортыннан табыла. 1757 нче елгы акча-Тымай чишмәсе яныннан табылган. 1766-1767 нче елгы акчаларны Гыйззәтуллин Әдһәм һәм Фәнүзәләр бакчасыннан, 1786 нчы елгы акча-Шарапов Марат бакчасыннан табыла.

1812 нче елгы 2ике тиенлек, 1841 нче елгы 1тиенлек көмеш акчалар Сагдеев Минехәер бабай йортыннан тапкан. 1894 нче елгы акчаны Урта кырдан таптым ди. 1911 нче елгы медальон патша Николай 2неке?

“Царская” бляха 2 башлы бөркет сүрәте белән Таллы урамнан табыла. Латуньнан эшләнгән өч асма бизәклр һәм лампа башлары Себер очы башында, Ачыга табарак табылган. Асма бизәкләр миндә саклана алар, миңа биреп китте. Кизләү чишмәсе янында элекеге тимерче миче, горна төбенә таба, тимерчелек булганга ошый ди, Рәшит. Чөнки эрегән металл калдыклары табылган.

Кайбер акчалар янгыннан калгандыр ахырысы, яртылаш эрегән.

Тагын 1938 нче елгы бакыр сәдәф бар, кораб якоре төшерелгән, төрле формада балталар, башка йорт кораллары табылган.

Кыскасы, Рәшиттә нумизматик материаллар байтак икән, без бу өлкәдә белгечләр түгел, тик чын белгечләргә, өйрәнүчеләргә аның коллекциясе затлы табыш булыр иде.

Күргәнегезчә, безнең авылдашлар тик ятмаган. Йөргәннәр, сәүдә иткәннәр, чөнки Кытай, Алтын Урда акчалары безгә Шарламабаш-Давыдкино-Балыклыга бер дә юкка, үзләре очып килмәгәндер.

# Йомгаклау сүзе

Мин инде яшем белән шактый олгайсам да, үземдә инфаркт булып, инсульттан байтак авырып, гомер иткән тормыш иптәшем, балаларыбызның аналары, оныкларыбызның әбиләре Мөкәтдимәне һәм кайнишем Халикны, братым Рөстәмне соңгы юлга, бакыйлыкка авылыбыз белән озатсак та, күңелем белән әле һаман чын карт кебек тик утырасым килми. Эч пошканда шушы язмаларны кәгазьгә тасвирлап та, кучергәләп тә, (стенокардия эләктергәнче) утырган булам. Машина белән урманнарга гөмбә җыярга барып йөрегәндә урман шаулавы, кайчак яңгыр иренеп кенә сибәләве арасында үзебезнең борынгы бабаларыбызның: Улым, сез без яшәп киткән Балыклыны, безнең зиратны, кабер урыннарын онытмадыгызмы?*-дигән тавышларын ишетәм кебек булам. Алдагы гомердәниләр күрәчәкне Аллаһы Тәгалә үзе генә белә диләр, аларны, дөрес, кеше туган чакта ук маңгаена язылган була дисәләр дә, аны беребез дә укый алмыйбыз, бусы, минемчә, яхшы да әле. Шушы гаиләбездә югалтулар өстенә, Чулпаннан киявебез Шамилнең көтмәгәндә, яшьли вафатын әйтеп китәргәдер, маңгаенда бу турыда язылганын белмичә китте. Авыру әбисенә бу турыда әйтмәдек тә.

Ә мин экс-колхозчы, пенсионер, узган тормышыбыз, яшәгән чорны, бергә эшләгән, заманыбызга туры килгән система казанында бергә кайнаган авылдашларны искә алам. Бүгенге көндә авылыбыз халкы, әле һаман эңгер-меңгер кочагыннан ерып чыгып бетә алмавын күзәтәм дә, алдагы киләчәген күзалларга тырышам.

Без, авылның үткәненә, бүгенге хәленә, киләчәгенә битараф булмаган, актив иптәшләр белән, (Хәбибулла Нигмәтуллин, Раил Вахитов, Раил Шәрәфетдинов, Рифкат Хамзин) бу язмаларны типографиядә бастырып чыгарырга теләгән идек, тик нәрсәдер, татарча язылган дип, алынмадылар.

Русча да, ары-бире язгалап маташкан идем, нәтиҗәсе ничек булыр... Кайбер материалларны районга, өлкәгә дә алганнар иде. Ә бу язганнар, белмәссең, бәлки яңа буыннарга, тарихыбыз белән кызыксынучы булса, язма истәлек булыр, авылыбызның дүрт гасырга якын үткән юлында ачыкланмаган, караңгы урыннарын эзләнеп тикшерергә теләүче табылса, эшен башлар өчен бер таяныч нокта булыр. Ихтимал, алар безнең ата-

бабаларыбыз башкачарак яшәгән икән дигән нәтиҗә ясарлар.

Ә син дә, хөрмәтле авылдашым, авыл тарихы сәхнәсендә онытылмаслык роль уйнап, яхшы эз калдырмыйча, гомереңне бушка уздырып, китеп барма.

Хәзер авылда киртә ихата белән тотылган йортлар түгел, тактасы да калмады дип була, барысында да тимер рәшәткәләр, тимер-калай капкалар.

Менә Гыйззәтуллин Рәшит тапкан, 1644 нче елгы Кытай акчасы- Цян- һәм Алтын Урданың көмеш акчалары эзләре монда, Балыклыга килмәгәннәр, акча ул товар белән янәшә йөри, димәк безнең халкыбыз эшләгән, йөрегән, сәүдә иткән. Менә шул акчалар, алар калдырган, истәлекле эзләре, борынгы бабаларыбызның яшәү рәвешенең өнсез шаһитлары.

2006 нчы елгы җәйнең бик матур бер көнендә, Сабан туена туры китереп, Балыклының 300 еллык юбилее дип, зур тантана ясап бәйрәм итеп уздырдылар.

Рәхмәт, безне дә дәшкәннәр иде. Ләкин, исәнлек булмау сәбәпле бара алмадык.

Үзем булмасам да, үз фикеремне язмыйча, төртеп куймыйча булдыра алмыйм.

Бәйрәм итү ул яхшы. Ләкин 300 еллыгымы, ул дата хакыйкәткә туры киләме?

Безнең Шарламабаш-Давыдкино- Балыклының чал тарихы бу дата белән килешә аламы? Нигә дисәң, алдан язган идем бит инде, Иске Ярмәк авылы тарихын язганда ЦГАДА СССР дан алынган рәсми документларда язылганча Балыклы нигезләнә башлый 1650-1660 нчы елларда диелгән. Менә авыл инде 50 елга олыгая. Ичмасам, кимендә 350 ел дип билгеләргә иде.

П. И.Рычков әйтүе буенча Алтын Урда морзасы Минкан Касап улы Дауд (Давид) Балыклыны Тиләгәзедә нигезли, (Давыдкино-Балыклы). Ул, күрәсең монда беренче рәсми килүче була. Дөрес, монда зур сорау туа, чөнки Алтын Урда 1436 нчы елда ук таркала. Башка ысул белән санап карыйк әле.

Заря тавы итәгендәге зиратның биләгән мәйданы уртача 7.0 гектар чамасы диләр, үзем үлчәмәдем. Бәлки әзерәктер. 1985 нче елда, тимер белән ихаталаганда, аның периметрын үлчәп тә чыкканнар иде, тик... Ярый, 7.0 гектар ул бит 70000 квадратлы метр. Һәр кабергә уртача 4.0 кв. метрдан исәпләгәндә 70000 : 4.0 =17500 кеше кабере урынысы чыга. Шушы 17500 не 300

елга бүлсәк, 17000 : 300 = 58 кеше ел саен күмелгән буып чыга, ә бездә хәзер иң күбе 20 ләп кеше үлә.

Икенче төрле хисаплап карыйбыз. Бер кешене күмәр өчен кабер урынын 6.0 кв. метрдан санасак 70000 : 6.0 кв. м.=11666 кабер урыны. Бу санны да хәзерге уртача 20 кабер урынына бүлсәк, 11666: 20= 583 ел килеп чыга! Бу инде Явыз Иваның Казанны яулап алгач, Мухутдинов язганча, 1553 елларда татарны ирексез чукындыра башлагач бу якка күченүләреннән дә алгарак китә түгелме? Хәер, ул чорларда төрле йогышлы авырулар эпидемияләреннән, ачлыклардан әлбәттә кеше күп үлгән, әмма бу урынга кешеләр килеп утыра башлаганда халык та аз була.

Бусы инде менә сиңа хөрмәтле укучы авылдашым уйларга, баш ватарга, эзләнергә сәбәп.

Ә берәр иренмәүчән энтузиаст бәлки зиратның әйләнәсен үлчәп чыгар, моңа фәкать ярты сәгать вакыт кирәк.

Бәлки берәр теләге һәм мөмкинлеге булган авылдаш Уфа архивында, Мөфтияттә генә түгел, Җөмһүрият архивында да, Богырыслан уезды, Бөгелмә ведомостенә катнашкан архив материалларында да эзләнер.

Гавриил Давыдрв, Йосып Ангалышевның тарихи юллары белән танышу да мөһим, чөнки бит Ангалышевның төп штабы Клявле авылында (Калярино) урнашкан булган.

Миңа калса, Ырымбур архивы хезмәткәрләре бик үк тырышлык, вөжданлык белән эшләмәгәннәр, чөнки бар булган материалларны да юк диделәр.

Мәскәүнең архивларында, МВД линиясе буенча, милек буенча мөнәсәбәтләр (имущественные отношения) архивларында казынып карау, минемчә уңышлы булыр иде.

Элек бөтен юллаучылар зурырак шәһәрләрдән башка шәһәрләргә елгалар буйлап, мәсәлән Сок һәм Кинәле елгалары буйлап, авылдан-авылга тоташкан юллар белән йөргәннәр, анда яшәүче халыклар турында язганнар да, ә Давыдкино-Балыклы зур сулардан читтә урнашкан булганга, безгә бик кермәгәннәр.

Шулай, хөрмәтле укучым, Балыклы тарихы дигән материалларны аннан-моннан чүпләп җыйган фактларны үзең теләгәнчә бер җиргә өеп куюдан, бигрәктә аларны үзеңә, үз карашыңа җайлыларны гына сайлап алып, шулардан чыгып, уй-фикер йөретмик.

Мин язганнарның иң әһәмиятле кирәк җирләрен генә алып, берничә кеше булса да язып, тулыландырыйк. Авылдашларның

язган, күргән белгәннәрен, фоторәсемнәрен җыйныйк.

Кемнәрнеңдер шүрлегендә, сандык төпләрендә авылдашларга кагылышлы саргаеп беткән кәгазьләрдә, дәфтәрләрдә борынгы риваятьләр, истәлекле вакыйгалар саклана торгандыр, алар барысы да безнең тарихыбыз. Аларны да җыеп, тарихыбыз мәҗмугасына кертү зарур.

Көн туа да, төн туа, ә вакыт уза бара. Уйлап карагыз әле, күпме онытылмаслык, язып калдырырлык эпизодлар, вакыйгалар, фотолар сакламыйча, мәңгелеккә сеңеп югалдылар.

Менә шушы юлларны язып утырам, тәрәзәдән тышка карыйм да Балыклыбыз тирән карга күмелгәнен күрәм, кышкы көннәрдә урамнарда аеруча тынлык урнашса да, байтак өйләр яшәүчесез бушап калса да, җәй җиткәч авылыбыз гадәттәгечә җанланыр, ямьләнер дип уйлыйм.

Мин, Рәшит Билалов, үскән чордашларым белән бергә безне социализм, коммунизм идеаллары нигезендә тәрбияләндем, тик зур, СССР дип аталган ил хәзер юк инде. Минем яшәү кануннарым, фикерләрем, илдәге тәртипкә, системага карашым, мөнәсәбәтем шул Совет чорында формалашкан, сеңгән, шуңа бездән шул заман законнары белән сорарга да кирәктер, дип уйлыйм. Инде XX1 нче гасырга кереп яшәүче, кыргый базар, кризислар, секвестрланган бюджет шартларында авылыбыз хуҗалыгы көймәсен ничек төпкә үк батырмаска тырышучы җитәкчеләр, мин пенсионер бабагыздан да, хәзерге чор кешеләреннән дә, артыгын сорамагыз да инде.

Бу язмаларны үземчә төгәлләгәч, үз акчама булса да типографиядә, йә, исә компьютерда бастырырга ниятем бар иде, мөмкинлек чыкмады. Социализм төзү чорында күмәк көч белән җыйган ил милкен, байлыгын үзләрен "демократлар" диюче олигарх-миллиардерлар кебек эләктереп калырга өлгермәдем, тик намуслы, тырыш хезмәтем белән тапкан малым, уртача тормышым белән, шундый ук авылым халкы белән авылда калдым. Яңа заман байларыча уңга-сулга акча сибеп яшәрлек капчыклап сәмән җыя алмадым, хөкүмәтебезнең тыйнак кына пенсиясенә яшәп ятам, шуңа да рәхмәт.

Хакимияттән шул шөгыльгә бераз матди өлеш бирергә вәгъдәләгән иделәр, ничек булыр, әле хәбәр ишетелми.

Ә социаль хезмәткәрләр клубта концерт куеп, алты мең акча җыеп, шул "копилкага" тапшырдылар, әлбәттә ул суммага китап чыгарып булмаса да, беренче алынуларына зур рәхмәт!

# Уйланулар...

Ватан сугышында Җиңүнең 69 еллыгына багышланган митинг вакытында, сугышта һәлак булган авылдашларга куелган һәйкәл янында утырганда, ничектер үзеннән-үзе уйланып, хисләнеп, сугыш елларында узган бала чагым күз алдымнан бер кино кебек үтеп китте. Сугыш башланганда миңа 6 яшь булган. Сугыш ул фронта гына түгел, бөтен илне баскан дәһшәт, шуңа без барыбыз да солдат кебек идек. Фронта солдат шинель киеп, кулына корал тотып дошманга каршы тора, ә без монда, тапкан иске-москы киемне өскә киеп, ә аякка инде барыбызда чабата киеп, ярым ачлыкка, көннең-көнендә фронттан өметсез хәбәр килү куркынычына каршы торып үскән сугыш балалары.

Дөрес, снарядлар, бомбалар шартлавын, пулялар сызгырганын монда ишетмәдек. Әмма, Балыклы урамнарында да канлы сугышның авыр сулышы даими сизелеп торды.

Сугыш вакытында бик көтелгән дә Кеше, шул ук вакытта шомлы, куркыныч хәбәрче дә-ул почтальон иде. Зарыгып көтелгән, фронттан язылган хатны ул елмаеп бирә, ә куркынычлы хатны почтальон, синең йөзеңә карамаска тырышып, кулын калтыратып сиңа "похоронка" - "кара печать" суза. Сугыш ул елау, бәгырьдән саркып торган сагыш, тагын елау. Балыклыга гына 136 "кара печать" язуы килгән. Кешеләр сугыш кырында гына үлми, ә монда, "морально" яртылаш үләләр.

1945 нче елны 9 май көнне мин, 10 яшьлек малай беренче мәртәбә ныгытып тойдым, минем әтәй юклыгын, ул фронта үлгән, аның кара печәте килде, ул кайтмаячак. Курскның "утлы дугасыннан" язылган соңгы хатында-бүген немецларның 19 нчы атакаларын кире кактык, мин бүген исән әле, дип язган иде. Ә аннан исән чыгып, Украинада ятып кала.

Малайлар кычкыра: - Мир булды, хатыннарга ир булды!-дип. Ә минем инәйгә ир, әбигә-улы, ә безгә, балаларына- әтәй юк иде.

Митингта утырганда күрәм, янымда фәкать сугышта катнашучы ветераннар ике-өч кеше бар, калганнары - "сугыш балалары" һәм яшьләр.

Искеләрне уйлап, ихтыярсыз чагыштырасың безнең яшьлекне хәзерге тормыш белән. Әйе, без вакытыннан элек олыгайганбыз. Балалык урамга уйнарга чакыра, ә авыр тормыш бездән эш сорады. Ашарга балтырган, төплекәй җыйдык. Бәләкәй арба "темпы" белән урманга утынга йөредек. Әбигә ияреп кырга утауга бара идек, белмим утавын эшли алганбыздырмы? Ул

вакытларда көнбагышны да, үсә башлаган бөртекле ашлык басуларында да кул белән чүп үләннәрен утаталар иде.

Тормышта бит бер әйбер дә эзсез югалмый, кешеләр яхшылык эшләгәнне, ничәмә еллардан соң булса да искә алалар, син үзең ул турыда инде күптән оныткан булсаң да.

Митингта әйтеп киттеләр, "сугыш балалары" әзерәк үскәч, үзебезнең колхозда тырышып эшләделәр, берничәсе хөкүмәт тарафыннан орден, медальләр белән бүләкләделәр. Төрле хәлләр баштан үтте. Яңадан андый сугыш вакытындагы тормыш, андый яшьлек кенә киләчәк буыннарга насыйп булмасын иде.

# Кулъязмалар

Элегерәк язганнарда безнең авыл тормшына кагылган иске язмалар бәлки кайбер авылдашларда сакланып ята торгандыр әле дигән өмет белдергән идек. Ул булган да, бар да икән, әллә ни ерак та булмаган, ләкин хәзер ул язмалар бик тә ерагайган.

Иске Ярмәк авылы мулласы Габдулла Мөхәммәткәрим, Казанга, Татарстан милли китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенә, бездә иске язган язулар бар дип, хат яза.

Казаннан белгечләр киләләр. Бу турыда 2014нче елгы Татар мөселман календарендә языла. 247-254 битләр.

Анда Яңа Усман авылы мәчетеннән алынган кулъязмалар арасында дәфтәр рәвешендәге берсе аеруча игътибарны җәлеп итә. Тулы бер дәфтәрдә хат язылган.

Иркутск шәһәреннән Балыклы авылындагы туганнарына Шәйхетдин исемле кеше юллаган ул хатны. Хаттан укып хатыны Бибимәсрүрә, уллары Гатаэтдин икәнен дә беләбез. Үзендә төгәл датасы булмаса да (куелмаса да) хатның 1904 елда язылганын билгеләргә мөмкин. Чөнки хатта Япон сугышы турында да сүзләр бар. Эчтәлегеннән аңлашылганча әле сугышның башы гына булырга кирәк. Хат авторның ни сәбәпле сөрелүе икәнлеге дә аңлашыла. Хатта исә туган якка кайтырга рөхсәт алуын һәм зарыгып көтүен бәйнә-бәйнә язган ул.

Хат туган төбәккә мәхәббәт хисләре белән сугарылган, урыны-урыны белән шигырьләп тә язылган.

Күрәсең, бу хатны Балыклыдан берәр туганнары Усманга алып баргандыр һәм анда, нинди дә булса сәбәп белән мәчетләренә эләгеп, анда сакланган.

Ә бит ул безнең авылдаш, Балыклы кешесе, йөз ел элек Себергә ни өчендер сөрелгән булган, бәлки әле бүген дә авылыбызда аның туганнары яши торгандыр.

# Авылның хәзерге хәле

Авыл турында язганда, иң элек үзең күргән-белгәннәрне яза башлыйсың, чөнки мин гомеремнең байтагын шушында яшәдем, күпне күрдем, алар барысы да авыл тарихының бер кисәге.

Һәр буын үткән тормышына үзенчә бәя бирә. Ни булса да, перестройкага кадәрге периодтагы авыл тормышында бар да начар иде димәс идем. Дөрес, ул вакытта халыкның акчасы булса да, кием-салым да бертөрлерәк иде, җиңел машина алырга бик читен иде, гомумән "дефицит" дигән нәләт яшәүгә артык ямь өстәми иде. Легковой машина авылда бер УАЗ ик колхозда, председательдә генә бар иде. Күпчелек халкыбыз, чәчүләр бетеп, печән, урып-җыю вакыты җиткәнче, үзебезнең колхоздан башка, читкә китеп, "шабашкада" көннән-төнгә кадәр эшләделәр. Анда инде бригадир эшкә дәшкәнне көтмиләр, бигерәк тә читтә, башка колхозларда, йә шәхси хуҗалыкларда балта һәм төзү эшләрендә. Ялланып, телдән төзелгән килешү нигезендә төзиләр, ремонтлыйлар һ. б. Таш, кирпеч эшләрен күберәк әрмәннәр килеп, ялланып эшләделәр. Алар бездәге имән агачын бик яратмыйлар, чөнки ул каты да, авыр да.

Яхшы, уңган "шабашник" күп йоклап ятмый, алар арасында яхшы, тәҗрибәле оста һөнәрмәндләр дә, аларга иярүчеләр дә булды. Һичшиксез алдан йөреп, эшне табып, заказчы белән эшнең күләмен, срогын, иң мөһиме акчасын уңышлы итеп килешә белүче кеше иң зарур шартларның берсе.

Мондый эшләрдә, мәсәлән, авылда Әсхәт абый Мөхтәсәров хатын-кызлардан бригада оештырып, читтәге колхозларда зур күләмле корылмалар, фермалар, складлар сылау, агарту- бурлау кебек эшләрне байтак башкарды. Ул үзе шигырьләр дә язгалый иде, бугай.

Мондый эшләрдә эшләүчеләр хәзер дә бар, табышлы эшне белешеп торалар.

Авылда өч эшкуар кибет тота, саталар. Ике ага-брат Шараповлар, Азат һәм Марат тимер стройматериаллары китереп саталар. Ә Мөниров Рамил читтән яшь чебешләр, тавыклар алып кайтып авылда һәм тирә-якта сата. Кайберләре пилорамнар алдылар. Бар җәй көне җиләк-җимеш, яшелчә белән шөгыльләнүчеләр.

Барыбер төп эш- авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү. Перестройка башлангач, биш аренда бригадасына, үз җире, техникасы белән комплектлап, шулай ук тиешенчә килешү төзеп, яңа формада, мөстәкыйль рәвештә эшләргә мөмкинлек бирелгән иде. Тик шулар арасыннан бер Хамзин Рәфкәт үзе, энесе һәм малае белән фермер юлыннан уңышлы гына эшләп китте. Башта

колхоздан алган техника белән эшләде, ә аннан 2012 нче елда, конкурста катнашып хөкүмәттән грант отып "Беларусь" тракторы алырга мөмкинлек булды. Иске дуңгыз фермасында үзенә база оештырды. Тик ул да, үстергән малны яхшы сатып, файда алып булмый дип зарлана.

ЛПХларда, шәхси хуҗалыкларда да эшләүчеләр бар. Кудрявцевлар, Сафиуллина Ольга, Фарукшиннар һ.б. үз хуҗалыкларында үгезләр үстерәләр, итләтә дә, башлата да саталар.

Кайбер гаиләләр каз-үрдәк белән шөгыльләнә, гомумән авылдашлар эшли, тик тормый, колхоз белән беррәттән.

Мин, гади генә әйткәндә, Балыклыда күпчелек халыктан бер ягым белән дә аерылып тормаучы, илебездә дин тыелган, дәһрилек заманында туып- үскән, мәктәптә, югары уку йортларында фәнни коммунизмның нигезләрен өйрәнеп, шул ук төстә авылда, колхозыбызда агроном булып икмәк үстерү белән бергә, парторг, тәрбия эшләре алып барган кеше идем.

Хәзер, замана алышынгач, тормышта кайбер әйберләргә, соңгарыбырак булса да, яшерен түгел, караш башкачага әйләнде, бәлки болай яхшырактыр да. Тик мин "шабашник" була алмадым, бер дә алайга бушамадым. Менә хәзер, пенсиядә, шунда ары-бире авыл тарихы эзләреннән атлаганда, кызыклырак, әһәмиятлерәк фактларны кәгазьгә теркәргә тырышам.

Бәлки кемгә дә булса файдалы җире булыр, үткән тормышыбыз турында кызыксынып укыганда бер төрле уйланырга сәбәп булыр, шәт, кемгәдер элегерәк яшәп киткән туганнары, әти-әниләре, әби-бабалары турында язылганны табып укыгач, кызыксынып алар турында keберәк беләсе теләге туар, эзли башлар.

Тарихны онытыр өчен бернинди көчәнү кирәкми, гамьсезлек, битарафлык җитә, ә гомер уза тора, бүген булып узган хәлләр иртәгә тарихка әйләнә. Тарихыбызны истә тотып, аны саклау-мактауга лаек хезмәт.

Авылдашларга, авылыбыз үткән юлын искә алыр өчен, бу язмалар тарихи материал булып хезмәт итәр.

Балыклы авылы тарихы эзләрен барлауга, авылның башлап нигезләнүе, каян һәм кемнәр беренче күченеп килүчеләр турында һәм авылга кагылган тарихи истәлекләрне җыйнап, бер төрле системага салып язарга беренче этәргеч ясаучы, колхозның баш инженеры, авыл Советы рәисе Халик Минвәли улы Ваһаҗев бу дөньяда хәзер юк инде. Минем дә бу язганнар аның үтенечен, булдыралганым кадәр, җавап һәм авылыбызның бай, күпьеллык, мавыктаргыч тарихын ачыклау эшендә үземнең дә тыйнак кына өлешем, эзем булыр, дим.

# Авылдашлар - мөһаҗирлар



*Табиб Галиев (уңда) операция вакытында*

Ничектер бездән, авылдан читкә китеп яшәгән, танылган авылдашларыбыз турында бер дә эзләнмәдем дә, шуңа язмадым да. Бу хатамны бераз булса да, белгән кадәр, төзәтергә кирәктер. Ишетеп беләбез, бездә туып - үскән авылдашлардан хәрби хезмәттә полковник дәрәҗәсенә ирешкәннәр булганын һәм хәзер дә бар, авылда ук. Ганниев Рәфкәт Минегалим улы, Украинада хезмәт итеп, майор званиесендә лаеклы ялга чыгып, авылга кайтып яши. Милиция подполковнигы Дәүләтшина Сания Мөхтәбәр кызы Камышлыда гомер итә.

Шулай ук башка зур урыннарда, дәрәҗәле вазыйфалар үтәп эшләүчеләр, белгечләр булды. Әхмәтшин Мәрданша абый Мөхәммәтша улы авылда комсомол оештырып, аның беренче секретаре, авылда күмәк хуҗалык-колхоз оештыручыларның берсе, су- гыш вакытында - капитан, аннан МТС та политотдел башлыгы, МТС ның директоры, сельсовет, колхоз рәисе һ. б., олыгаеп, пенсиягә чыккач, хатыны, озак еллар авыл мәктәбендә укытучы булып эшләгән Вергазова Хәдичә апа белән Похвистнево шәһәрендә яшәп, бакыйлыкка күчтеләр.



*Бораучы ярдәмчесе Рөстәм Билалов буровой вышкасына флаг куйды. Чукотка. 1967 ел*

Менә өлкә татар гаҗите “Бердәмлек”нең 20.12. 14 ел санында чыккан “Күзкәйләрең ничек күрә?” дигән мәкаләндә Самара өлкәсенең Ерошевский исемендәге күз дәвалау клиникасында эшләгән күз табибы, профессор Сәгыйт Сәлих улы Галиев турында сүз бара. Балыклыдан 4-5 чакырым арада, урман эчендә, Чирмеш дигән поселокта, безнең авылдашлар, колхозлаштыру вакытында, 5 гаилә күченеп яшәделәр. Сәгыйт абый шунда үскән, Исаково авылына йөреп белем алган, аннан институтта табиблыкка укыган. Үзе озак эшләгән, күзләр дәвалау хастаханәсендә килгән татарлар белән коридорда ук чын Балыклы мишәләречә сөйләшеп йөри иде. Сәгыйт абый “Сәламәтлек саклау отличнигы”, профессор, хатыны Нәсимә апа теш табибы. Мин аны бер генә мәртәбә күрдем, фатирларында да булдым, бик матур яшиләр. Менә шундый югары квалификацияле һөнәрмәнд, белгечләр чыккан авылыбыздан, мишәрләрдән! Туганнары Гәлиевлар Балыклыда да, Карамалда да әле яшиләр.

Әйе, кеше туа, яши, җирдә, токымнарында, авыл хәтерендә эзе кала. Нинди эз калдыру фәкать аның үзеннән генә тормаса да, тәкъдир дә бар бит, тик шулай да бик күбесе кешенең үзеннән тора. Тырышлык белән уңышлы эшләр башкарып яшәгәндә генә җирдә якты, матур, истәлекле эз калдырып була. Ә Сәгыйт абый андый эз калдырды.

Алда Ангалышевлар турында сүз булганда, аларның ничек хезмәт иткәннәрен язмаган идем, языйм әле. 1870 нче елда туган Ангалышев Гәбәйдиннур бабай беренче Бөтендөнья сугышында полк командиры була, медальләр белән бүләкләнә, аннан соң,

25 ел волость писере булып эшли. Балыклыдан аерылып Карамалга күченеп утыруны алдан ул оештырып йөри. Колхозга беренче булып керә, тагын әле Дагыстанда, Хасавюрт тирәсендә 4 колхоз төзүдә катнаша...

Кыска гомерле булса да Закиров Шәүкәт малае очучы Маратны (әнисе шәфкать туташы Монахова Александра Павловна), искә алырга кирәк. Очучы Мустакимов Рафкат Фәсәхетдин улы, "Яврәй" Шәйхетбин бабайлар төбе, шулай ук Чирмештән, Исаковода укыган, укытучылары сугыш вакытында Ленинградтан эвакуировать ителгән мөгаллимәләр булган.

Авылдашыбыз Әхмәтов Дарвин Гәзиз улы Новосибирск шәһәрендә, академгородокта эшли, яши, "техник фәннәр кандидаты" икәне билгеле, бәлки инде "доктор"дыр да.

Әхмәтов Тельман Газиз улы шулай ук гражданнар авациясе очучысы иде, Курумоч аэропортында, озак, пенсиягә чыкканчы эшләде.

Богырысланда, безгә якын туганнар Хәдичә әбинең (Шәет) бер уллары Кыямның ике улы да Айрат һәм Азат летный училище тәмамлап, очучылар булдылар. Кыям абзый үзе озак еллар горкомда эшләде, ә олы малайлары Гариф сугыштан соң Мәскәүдә, эчке эшләр министрлыгы карамагында эшләп, майор званиесендә пенсиягә чыга. Кече бер малайлары, Минетдин Богырысланда гомере буе шофер булып эшләде. Ганниева Хәдичә әбиләр Богырысланда Широкая урамында гомер кичерделәр.

# Карамаллар

НЭП вакытында Балыклыда зур пожарлар була. Яшәргә кыенлаша. Ә монда йортлар, халык күп. Нишләргә? Бер төркем ир-ат: Ангалышев Сәлимҗан, Ангалышев Гөбәйдинур, Ангалышев Абделбар, Ангалышев Абдрахман, Фарукшин Нәдерша, Сәфиуллин Һади, Шайдуллин Шәйхулла, Шайдуллин Гатият һәм тагын берничә гаилә 1928 елны Балыклыдан аерылып чыгарга дип узара карар чыгаралар. Моның оештыручылары Ангалышев Сәлимҗан һәм Беренче Бөтендөнья сугышында полк командиры, волостной писарь Гөбәйдинур була. Монда Усмановлар, Галимуллиннар, Садыковлар, Галиевлар һ.б күченә. Язуларда авыл-поселок Яңа Балыклы, ә халык телендэ Карамал дип йөретелә.

Карамалда алдан да халык яшәгән булган. Мәсәлән, латышлар. Аларның зиратлары тау яклап чишмәдән өстәрәк булырга тиеш диләр. Ләкин алар кая киткән - аны белмибез. Балыклыда Ангалышев Абдулла - Идрисләр кала. Коллективизация вакытында колхозның беренче рәисе Ангалышев Сәлимҗан сайлана. Ләкин ул ярлы гаиләдән түгел дип, кулаклардан чистарту башлангач, Сәлимҗан тиз генә гаиләсе белән Урта Азиягә китә. Аннан соң Әбделбарны кулак дип эшләтмиләр, сайлау хокукларыннан төшерәләр. Бар эш коралларын, малларын алалар.

Тормыш яңача гөрли башлый. Колхоз да "Яңа юл" дип атала, МТС тракторлары эшли. Бригадир булып сугыштан соң Ангалышев Газнур абзый иде, ә мин аңарда 15 яшьлек малай-учетчик. Фарукшин Нәдерша бабай кузнец. Фарукшин Мостафа, Шәрәфетдинова -Ангалышева Мәрьям укытучылар. Чөнки Карамалда башлангыч (4 сыйныф) мәктәп, клуб бар иде.

Колхозда сыер, сарык, тавык фермалары, ашлык складлары, тегермәннәре бар иде. Йортлар саны 75кә җитте.

Әлеге Әбделбар Ангалышевны сугыштан соң Карамалда колхоз рәисе ясап куялар. Халык ач. Бу эшләгән эш көненә (трудоденьгә) райком рөхсәте буенча 100 әр грамм икмәк бирергә булалар.  Ә болар 200 грамм бирә. Шуның өчен 3,5 елга суд карары чыгаралар. Ләкин, кабат суд карарын караткач, алты айдан чыгаралар.

1950 елны колхозларны Седяково, Чекмаловка, Чулпан белән куштылар. Бу кушылган колхозда рәис булып Сәгыйть абый Кутузов калды. Халыкка эш булды, яхшылап фермаларын төзеделәр, зурайттылар. Трактор бригадасында мехмастерской салдылар.

Ләкин Горбачевның перестройкасыннан соң, колхоз таралды, мәктәп ябылды. Шулай ук кибетләре дә ябылды. Бәләкәй генә медпунктлары бар иде- ул да юкка чыкты.

Әйе, мин анда эшләп йөргәндә бар да бүтәнчә иде. 1950 елларда бер ир тимерче Фарукшин Нәдерша абзыйга теше сызлап килгән иде. Тимерче кләшчәсе белән тегенең тешен суырды да алды. Вәт кузнец-стоматолог!

Якшы гына рәис булып Әсхәт Салахов, Мәдехәт Кәримов эшләделәр.

Хәзерге вакытта күбесенчә картлар калды, үз хуҗалыклары белән эш итәләр. Авылларында электр уты, газ, урамнарында су коелары, поселокка кадәр асфальт юл бар.

Ил башлыкларының политикасыннан чыккан бүгенге банкротлыклар да, эшсезлекләр дә, колхозларны юкка чыгаруда да Карамал, Сидәкәү, Чекмалау, Чулпан халкының гаебе юк төсле. Ни генә булмасын эшләрне күмәгрәк башкарганда, бергә яшәгәндә, кыенлыклар килгәндә дә уртаклашып, булган мәсьәләләрне бергә җиңелерәк ерып чыга идек төсле түгелме?

# Камал әбигә 100 яшь




# Тормыш

Бусы авыл тарихына ныгытып кагылмасада, үземнең оныкларым бар, бәлки алар кызыксынып укырлар. Ерак- ерак инде калды сугыш елларында үткән балачагым, илебезгә хезмәт итеп зур ил буенча йөрегән елларым. Әйе, гадәттә кешеләр дөнья күрер өчен сәяхәткә акча түләп китәләр, ә мин яшем җиткәч тә, җиде сыйныф белемем белән, анысы да чамалы гына булса да, 5 ел эш стажлы малай “телячий”, ягъни товарняк вагоннарда Хабаровскийга, Амур флотилиясенә киттем. Анда белем алгач, Кореядагы сугыш тәмамлану белән, яңадан шундый ук вагоннарда берничә атналар дәвамында юлда барып хезмәтне дәвам итәргә туры килде. Юл уңаеннан Байкал күлендә су кереп чыгарга да насыйп булды әле. Дөресен әйткәндә, кайчан әле тагы монда килеп булыр дип, берничә матрос күлгә чумып чыктык. Суы искиткеч чиста, җылы иде. Амур елгасында да су яхшы, тик Байкалныкы яхшырак, суы төче, тәмле, Крым-Севостопольнең суы түгел инде. Безне Крымга, кара диңгез буена, ягъни Севастопольгә иттеләр. Аннан соң Керчның Камыш борнындагы суднолар төзү верфена җибәргәннәр иде, аннан Феодосиягә №79 мина тралщигына күчерделәр. Ул база оптовых

кораблей иде. Феодосия, Керчь, Новороссийск, Азовтан Жданов (хәзер Мариополь) шәһәрләренең форваторлары, Керчь проливында да бер җәйне тралить иттек.

Севастопольдә 1955 елның 28 нән 29 октябрендә төнлә икедән таңга кадәр Ленкор "Новороссийск" шартлап батканда без анда Южный бухтада тора идек. Җиде йөзләп морякның башына җиттеләр. Братская могила ясап күмделәр дигәннәр иде. Белмим, никадәр дөрес. "Сапун-гора"да өйләр салырга фундаментка дип таш та җыйдык. Анда инде күрәсең, бомбалардан калган воронкалар күп иде. Малахов-курган шәп-шәрә иде. Дөрес, Севастопольдә осколоклар, пулялар урыны бик күп иде. Херсонга "покупатель" булып попольнение артыннан бардык. Шулай ук озатып баручы да булып Семеизда, Ялтада бер атна булдым.

Дүрт елдан хезмәт итеп старшина 1-ой статьи булып өйгә кайттым. Әзерәк укыгач запастагы капитан-лейтенант корабельной службы ясадылар. Кара диңгез җиленең тозлы тәмен бүген дә искә алам.

Учетчик, фуражир, комсорог, парторог, агроном да булып эшләдем. Орден да, медаль дә, шелтәүләр дә бирделәр. Ә хәзер инде картлар, түбәтәйдән генә йөрибез. Алдаграк елларда, маллар асраганда, чират белән көтү көтәргә вакытың җитсә, иртәнге чык белән "Зур марча" "Заготскотка", йә Салкын чишмә, акбур таулары ягына китәргә булыр иде дип уйлап утырасың. Анда бит йомраннары, сыркалары арт аякларына басып сызгырышып сине көтүең белән каршы ала. Кояш чыккан чакларда, томан әле таралып бетмәгән чакларда, тау башынада чүгәләп малларыңа карап утырасың, ә үзең уйга каласың, төрле хисләргә батасың. Күпме авыл кешесенең гомере чыбыркы сөйрәп җәл үтә! Ә шулай да көн буена йөреп арысаңда, кырда йөрегәндә җаның ял итә. Өстәвенә әле июль-август айларында чиратың туры килсә, җиләккә, гөмбәгә дә шунда хутын табып күз саласың.

Бер уйласаң, тормыш диңгезенең төрле җилле-давыллы дулкыннарыда, тагын әле аракы "күлендә" бүгенгәчә эзсез батып югалмадык. Тамагыбыз тук, өстебез бөтен, ә авылыбыз Аллаһыга шөкер, тыныч дисәң дә була. Ә халкыбыз колхоздан башка, каян эш таба шунда тырышып-тормашып үзенә күрә эшләп йөри. Киләчәккә өметен югалтмаган әле ул.

Узган гомерне, тарихны кире кайтарып та, аны яңадан башкача язып та булмый. Язмышыбыз яхшымы, начармы, ул безнең мишәр бабайларның һәм инде безнең дә яшәгән гомер...

# Урманчылык



*Балыклы урман хуҗалыгы эшчеләре*

# Онытмабыз сезне, сугыш батырлары

*Окоплардан килгән хатларыңда*
*Әле һаман дары исе бар,*
*Уртак язмыш өчен иң газаплы*
*-Хуш, кадерлем, дигән сүзең бар.*

*Ә бер хатта кара хәреф белән*
*Ашыгып язган каләм эзе бар,*
*-Батырларча дустың һәлак булды,*
*Онытмагыз, дигән сүзе бар.*

*Хушлашуың соңгы ак кәгазьдә калды*
*Саклыйм аны, якын итәмен,*
*Якты өмет сүнми, сүрелми дә*
*Кайтмасаң да, сагынып көтәмен.*

*Еразлардан килә гомер авазлары*
*Әйтерсең дә яшьлек эндәшә,*
*Ә ул шулай таң җилләре аша*
*Сагыну моңы безгә өләшә.*

*Якын дустым минем иркен кырлар,*
*Яшел тугай, урман буйлары.*
*Ялгыз каен кызы сердәш булса,*
*Ә юлдашым шәфәкъ нурлары,*

*Онытмыйбыз сезне, сугыш батырлары,*
*Ут эченә алдан бардыгыз,*
*Киләчәкнең якты бәхете өчен*
*Сугыш кырларында калдыгыз.*

Мәрьям Шәрәфетдинова-Ангалышева.
7 нче феврвль 1978 ел.

## Авылымның исеме дөрес түгел!

*Авылымның исеме дөрес түгел*
*“Балыклы” дип зая аталган,*
*“Бишбармак” дип кушу кирәк иде*
*Бишбармаклы кулга ошаган.*

*Сул кулыңны җиргә каплап салса?*
*Нәкъ авылның була торышы,*
*Бармакларны берәм-берәм санап,*
*Урамнарның сузылып ятышы.*

*Баш бармагы - “Ярмәк очы”-урам,*
*Икенчесе данлы “Таллы урам”.*
*Имән бармак - “Кысырыкка” төби,*
*Исемсезе-иң зур, “Олы урам”.*

*Чәнти бармак та өлешсез түгел,*
*Аңарга да урам табылган:*
*Бармак кыска - урам шактый озын,*
*“Себер урамы” дип аталган.*

*Авылымның исеме дөрес түгел!*
*“Балыклы” дип зая аталган,*
*“Баткаклык” дип кирәк иде кушу,*
*Тирә-ягын сазлык каплаган.*

Халик Вагазов 2002 ел.
Шарламабаш-Балыклы

## Һәр эшнең, һәр күренешнең

*Була тәүге очы, башы,*
*Балыклы авылының исеменең*
*Шарлама була башы.*
*Шарлама үзе инеш башы,*
*Сазлыктан агып чыга.*
*Бормаланып, талгын агып,*
*Тоташа Балыклы-Суга.*
*Агымы түгел гел талгын*

*Вакыты белән ташый,*
*Агымы буена ярлардан*
*Кушыла чишмәләр шактый.*
*Шарламадан үскән Балыклы,*
*Кем яшәгән анда моңарчы?*
*Нинди милләт, күпме халыктыр*
*Аңа тарихта хәбәрләр юктыр.*
*Архивларда авыл турында*
*Хәбәр сай, тырнак чаклы,*
*Бар кайсында искә алынган*
*Шарламабаш-Давыткино-Балыклы.*
*Шарламабаш инде билгеле,*
*Давыткиносы кайдан?*
*Галимнәрнең эзләнүе*
*Бу хәлне ачыклаган:*
*Морза Касап улы Даут*
*Килеп Алтын Урдадан,*
*Исемен өстәп Шарламага*
*Нигезләнеп утырган.*
*Балыклы, дигәч, халыкта*
*Шундый уй килә башка:*
*Су, күлләре бу авылның*
*Бик бай, ахыры, балыкка.*
*Безнең авыл исеменә*
*Сәбәпче түгел балык,*
*Ул исемне ияртеп килгән*
*Монда күченгән халык.*
*Татар, бахыр, аугач Казан,*
*Кимсетелгән, изелгән,*
*Чиркәү диненнән яздырган,*
*Мәҗбүри чукындырган.*
*Татар саклап динен, телен,*
*Тарала, ташлап илен,*
*Алар күпчелек яши шуңа*
*Чәчелеп җир шарына.*
*Бер төркеме качакларның*
*Мишәр, Пенза ягыннан,*
*Йөри торгач, безнең якның*

*Табигатен күреп сокланган.*
*Булган шунда биш йортлы*
*Кечтеки генә бер авыл,*
*Яшәгән андагы халык*
*Кичерми һичбер давыл.*
*Килешеп җирле халык белән*
*Шушында урнашалар.*
*Исемнәре кала әлегә:*
*Шарламабаш-Даутлар.*
*Шактый гына еллар узган,*
*Янә мул көченү булган.*
*Казан, Арча якларыннан,*
*Авылы-Балыклыдан.*
*Өстәлә халык авылга*
*Биш йорт җитә бишйөзгә,*
*Өч катлыга әйләнә исеме:*
*Шарламабаш-Даутлы-Балыклыга.*
*Кушылма исем бик өнәлми:*
*Идарә өчен катлаулы,*
*Сайлый торгач байтак кына,*
*Кала өчтән тик Балыклы.*
*Шул исемдә бүген дә авыл*
*Яши, кичереп давыллар.*
*Инкыйлаб һәм өч сугышта,*
*Сыналган авылдашлар.*
*Төрле-измнар төзүне дә,*
*Перестройка бәласен дә,*
*Реформалар нәләтен дә,*
*Татый ул үз иңендә.*
*Биш йөз йорттан тик яртысы*
*Калып бара авылда,*
*Тәкъдир юраган юлыннан*
*Авылыбыз алга бара.*
*Эш сөючән, горур мишәр,*
*Туры әйтүчән, җор телле,*
*Җыр-биюгә чын сәләтле*
*Инанам, мең ел яшәр!*

## Зиратта

*Авылга кайткач зиратка кердем,*
*Җанга ошардай манзара күрдем.*
*Зират электән нык зурайган,*
*Тимердән яхшы ихаталанган.*
*Мәрхүм туганнар, әби-бабамнар,*
*Әтием-әнием шунда яталар.*
*Алар каберен зирәят кылдым,*
*Рухларына догамны кылдым*
*Энеләрем белән бергәләп*
*Артык куакларны кискәләп,*
*Кыйшайганны төзәткәләп,*
*Каберләрне киттек кадерләп.*
*Күз йөретеп каберлек мәйданын*
*Еракка юнәлде уйларым,*
*Хәзерге каберләр кадердә*
*Ә бармы ул борынгы кабергә?*
*Өч гасыр артык тарихы авылның*
*Куенында мәгърур Заря тавының,*
*Күпме һәм кемнәр ята гүрләрдә*
*Ул турыда бар хәбәр кемнәрдә?*
*Биредә электән мөэминнәр җирләнгән,*
*Булган мукшы, латыш зиратлары,*
*Очырый әле янтайган, ямшәйгән,*
*Исемсез, онытылган кабер ташлары.*
*Таштагы язулар юылган, югалган,*
*Кайсында уелган ярымай сакланган.*
*Болар ич безнең борынгы бабайлар,*
*Тәүге авыл нигезен алар салганнар.*
*Телне, дине саклап калганнар,*
*Мишәрлекне мираслаганнар.*
*Уемча кирәк ул мәрхүмнәргә*
*Истәлекле билге куярга,*
*Кереп тарих шүрлекләренә*
*Кемлекләрен барларга,*
*Мемориал такта куеп*
*Исемнәрен уярга.*

Наил Вахитов, Балыклы-Самара
2015 ел

## Статистические таблицы Самарской губернии за 1870 год

| уезд | Волость | Наименование места | Всего | Национальный | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Русские | Мордва | Чуваши | Татары | Башкиры |
| | | Ниж. Ермаково | 581 | | | | 581 | |
| | | Ст. Ермаково | 617 | | | | | 617 |
| | | Нов. Ермаково | 487 | | | | | 487 |
| | | Камышла | 1287 | 23 | | | | 1264 |
| | Стюхино | Алькино | 800 | 4 | | | | 796 |
| | С.К. | Бакаево-Надырово-Акана | 1190 | | | | 793 | 397 |
| | Байтуган | Нов.Усманово-Емангил | 1128 | | | | 561 | 567 |
| | | Всего Ново Башкир (типтяры) обоего пола | | | | | | 4128 |
| | Байтуган | Байтуган (в. Ермаково) | 2593 | 657 | | 398 | 538 | |
| | | Балыклы (Давыдкино) | 1030 | 8 | | | 1022 | |
| | | Ст. Усманово | 362 | | | | 362 | |
| | | Всего Татар | | | | | 3857 | |
| | | Никиткино | 626 | | | 626 | | |
| | | Нов. Семейкино | 305 | | | 305 | | |
| | | Всего чуваш обоего поля | | | | 2061 | | |
| | | Всего русских | | 836 | | | | |
| | | Назаровка | 466 | | | | 466 | |
| | | Нов. Мансуркино | 1340 | 228 | | | 1112 | |
| | | Мочелеевка | 620 | | | | 620 | |
| | | Рысайкино(чуваш) | 952 | | | | | |
| | | В т.ч. идолопоклонники | 339 | | | | | |
| | | Ст. Ганькино | 1175 | | | | | |
| | | В т.ч. идолопоклонники | 399 | | | | | |
| | | Клявлино | 922 | | | | | |

# Хронология.
# Балыклы халкының йөреше (җыелуы).

| | Годы | Дворы | Жители (документально) | | | Примечание |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Всего | Из них | | |
| | | | | Муж | Жен | |
| | 1533 | | | | | |
| | 1650-1660 | | | | | Дауд-Давид |
| | 1694-1695 | | | | | Маминнар |
| | 1699 | 5 | | | | Ангалышевлар |
| | 1733 | +5 | +42 | +23 | +19 | Генер. межевание |
| | 1790 | 69 | 374 | 158+28=186 | 156+32=188 | |
| | 1795 | | +13 | | | |
| | 1796 | | +52 | 28 | 24 | |
| | 1841 | | 796 | | | |
| | 1847 | 295 человек прихожан ходит в мечеть | | | | |
| | 1859 | 143 | 938 | 437 | 501 | |
| | 1864 | 143 | 974 | 473 | 501 | |
| | 1883 | 177 | 1098 | | | |
| | 1889 | 259 | 1548 | | | |
| | 1910 | 397 | 1894 | | | |
| | 1920 | 442 | 2600 | | | |
| | 1928 | 434 | 2272 | | | |
| | 1970 | 231 | 903 | | | |
| | 2000 | 272 | 666 | | | |
| | 2012 | 283-71=212 | 597 | | | |

# Эчтәлек:

Кереш сүз ........ 3
Балыклы авылы тарихы турында
бүгенгә билгеле мәгълүматлар ........ 6
Авылның төзелеше һәм үткән тормышы ........ 21
Күршеләр ........ 25
Кем соң без, татар-мишәрләр? ........ 28
Уеннар һәм төрле фигыльләр, тормыш ич ........ 36
Топонимика ........ 53
Гражданнар сугышының
һәм ачлык елларының авылга кагылышы ........ 58
Колхоз ........ 61
МТС ........ 82
Ватан сугышы чоры ........ 88
Авылда төрле елларда булган хәлләр ........ 113
Гаиләләр кору ........ 120
Динебез ........ 126
Перестройка чоры ........ 134
Безнең турыда чит авторлар ........ 138
Авыл активистлары ........ 141
Мәктәп ........ 145
Китапханә ........ 160
Шифаханә ........ 161
ЦСО ........ 162
Авыл Советы, ягъни авыл үзидарәсе ........ 164
Безнең нәсел тамырларыбыз ........ 173
Авылыбызның нумизматы ........ 176
Йомгаклау сүзе ........ 177
Уйланулар ........ 181
Кулъязмалар ........ 182
Авылның хәзерге хәле ........ 183
Авылдашлар - мөһаҗирлар ........ 185
Карамаллар ........ 188
Тормыш ........ 190
Урманчылык ........ 192
Шигырьләр ........ 193
Статистическая таблица ........ 198
Хронология ........ 199

# БАЛЫКЛЫ
# АВЫЛЫ ТАРИХЫ ЭЗЛӘРЕННӘН…
## Самара өлкәсе, Камышлы районы, Балыклы авылы

Тарих катламнарын актаручы һәм Балыклы авылына кагылышлы эзләрне берәмтекләп чүпләп, шушы язмаларны төзүче **Билалов Рәшит Кыям улы**.

Мишәрчәрәк язылган урыннарын, булдыралган чаклы, бүген кулланудa булган әдәби телгә якынайтыбрак күчерүче **Вахитов Наил Вәли улы**.

Басарга кул куелды **.**.2016.
Форматы 60х90 1/16. Офсет кәгазе. Офсет басмасы.
Гарнитура Tat Antiqua. Күләме 10 басма бит.
Тираж **** экз. Заказ № ************

ООО “Медиа-Книга” типографиясендә басырылды.
443070, Самара шәһәре, Песчаная 1 урамы; тел. (846) 267-36-82